Безнен МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

01

гыйнвар 2018

ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ЗӨФӘР ФӘТТАХОВ. «КАЗАН УРАМЫ»

Әдәби ел йомгаклары

16 декабрьдә ТР Язучылар берлегенең Әдәби ел йомгакларынаба гышланган чара узды. Анда редакциябез хезмәткәрләре Рәдиф Сәгъди – әдәбияттагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Туфан Миңнуллин исемендәге премиясе, Фирдәвес Зариф – нәтиҗәле хезмәте һәм татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Мактау грамотасы, шулай ук журналның актив авторы Рүзәл Мөхәммәтшин – Муса Җәлилнең 110 еллыгы уңаеннан чыгарылган истәлек медале һәм Муса Җәлилнең кызы Чулпан Җәлилованың Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

Нәгыйм Шаһи фотолары

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

1 (289)

гыйнвар 2018

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

40

100 АЛИҺӘ

110 «РЕВОЛЮЦИЯ ДАВЫЛЫ: РОССИЯ ТАРИХЫНДА 1917 ЕЛ»

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Шиһабетдин Мәрҗани

ТАРИХИ МИРАС

4 Нурсолтан. *О.Иванова*
11 Әүлиялар ватаны — Күбәкәй
17 Чал тарихлы Кодашым: алып батырлардан «чабаталы аклар»га кадәр. *Ф.Газизова*
24 «Дога иттек Аллаһка...» *М.Хулуси Акчура*
28 Гасыр дәвамында үткән юл. *И.Шаһиев*
34 12 еллык татар җәнлек календаре язма һәм тел чыганакларында. *В.Әхмәтов*

ТАТАР ГАМЕ

40 Ил агасы. *Н.Акмал*

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

48 Тәңре, Дингир вә Умай... *А.Галимҗанов*
52 Бөек Тукай адашы (Абдулла Арипов)

ДИНИ МИРАС

54 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
59 Рәхмәт сүзе. *Ләбиб Лерон*
60 Хәлфә бабай. *Госман Гомәр*

ӘДӘБИ МИРАС

64 Каһарман Катыйл
68 Ышанычсыз юлга бер адым. *Г.Монасыйпов*
73 «Тукаевтан соң беренче шагыйремез...»
77 Язучы, танкист, укытучы. *Р.Мөбарәкшина*
78 Мирсәй Әмир һәм ЛОКАФ
80 «Калкыйм йолдыз булып күкләрдә...» *Р.Зәкиева*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

82 Галиҗәнап галим

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Ленар Гобәйдуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министр урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)
Лотфулла Шәфигуллин
(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррирләре
Марат Закиров
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-92)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

86 **Сукыр Сибгат һәм аның хисапчы улы Миңнегали.** *Г.Галиев*
90 **Хушлашу сүзе.** *Л.Зөлкарнәй*

СӘНГАТИ МИРАС

93 **Татар моңы әхрамы.** *З.Гыйльметдинова*
100 **Алиһә**
103 **Әлфия апа.** *Л.Лерон*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

104 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

106 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**
110 **«Революция давылы: Россия тарихында 1917 ел»**
114 **«Мәрҗани» чишмәсе**

116 **Безнең мирас хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Гыйнвар*

Заказ №А-3276. Тираж – 2150 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 26.12.2017
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Казан урамы» ***З.Фәттахов.***
Киндер. майлы буяу. 2005 ел.

ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ

(1818-1889)

***

Мөселманча белмичә русча укып калу гына ярый торган эш түгел.

***

Үз диненнән, милли тел һәм язуыннан хәбәре булмаган кешеләрнең русча укуыннан зур хәер көтелми.

***

Карчыкларның игътикады гыйльме кәлям вә фәлсәфә илә мәшгуль байтак адәмнәрнең игътикадларыннан яхшырак, аларның Аллаһыга иманнары куәтлерәк.

***

Ашыкмагыз, һаман уйлап эшләгез.

***

Тел бету – милләт һәм дин бетүдер.

***

Белем алуда тәртипнең юклыгы гыйлемнән мәхрүм булуыбызга сәбәп.

***

Сезләр матбугатта һәрнәрсәне карарга тырышыгыз, мәгънә шул матбугаттадыр.

***

Әгәр гыйлем ияләре кеше кызыгырлык сурәттә булсалар, мин дә шулар кебек булырмын, дип, белем алуны теләүчеләр күп булыр иде.

***

Галимнәрнең хезмәт хаклары түбән һәм хәлләре түбән булып, йорт-җире, хәрәкәт итү чараларының һәм башка тормыш әсбапларының бик түбән дәрәҗәдә булуы башкаларның гыйлем һәм мәгарифкә күз-колак салуларына киртә була.

***

Халкыбыз үз теле вә әдәбияты урынына башка телне катыштырырга үзләре әзер тора. Шулай булгач, әдәбият нигә югалмасын? Мәсәлән, арабызда, фәләнов-төгәнов, диеп русча әйтү бик таралган. Ни булды ки, «Габдулла Габдрахман углы» диеп язсалар, әлбәттә, һич зарар киләчәк түгел. Мин исә һәрвакыт әсәрләремдә яки гаризаларымда «Шиһабетдин Баһаветдин углы» диеп язам, максатым һич югалганы юк.

Текстны ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

НУРСОЛТАН

Ольга Иванова

Тәрҗемәчедән

Әлегәчә күпләргә билгесез булган Ольга ханым өч зур «бәби тапкан», имеш, ягъни өч китаптан торган «Казан ханбикәләре» дигән трилогия язган. Аның беренче томы Татарстан китап нәшриятында бик матур булып басылып чыкты. «Казанский альманах» басмасы әлеге өчтомлыктан иң кызыклы өлешләрен сайлап алып нәшер итә башлады. Бу томны тәкъдир итү кичәсендә аның авторы белән мине альманахның җаваплы редакторы – каләмдәшебез Әхәт Мушинский таныштырды. Ольга ханымның ни өчен безнең тарихка чумып әдәби әсәр язуына мин дә гаҗәпләнгән идем, бары тик шунда гына аның тамырларында татар каны агуын, әнисенең татар кызы булганлыгын белеп калдым... Әхәт дустыбыз романның өзекләрен татарчага тәрҗемәдә баш редакторы Ләбиб Лерон булган мөхтәрәм «Безнең мирас» журналында бастырырга көтеп торганлыкларын да әйтте. Мин, журналның мөмкинлекләрен искә алып, беренче романның «Казанский альманах»тагы өлешен дә яртылаш кыскартып тәрҗемә иттем.

Безнең гади укучыга, билгеле, күбрәк Сөембикә ханбикә исеме таныш. Ә «Нурсолтан» романының сезгә тәкъдим ителә торган өлешендә Нугай морзасының кызлары Нурсолтан белән Шаһназның Казанга килүе сурәтләнә. Кызларның икесе дә Казан ханы Мәхмүднең улларына булачак килен итеп сайлап алынган, әмма тормыш юлында аларны көтелмәгән борылышлар сагалап тора...

Мөдәррис Вәлиев

...Ул җәйге көнне табигать бертуктамый койган пыскак яңгыры белән каршылады. Солтаннарның булачак кәләшләрен каршыларга, күреп калырга дип урамга сибелгән Казан халкы манма суга чыланды. Казан байларын да яңгыр аяп тормады: көяз киемнәре каралып, чалмаларындагы купшы каурыйлар шиңеп-шәлперәеп төште. Мәхмүд хан шундый көнне япанга чыгып, улларына кәләш булырдай кызыкайларны ни зарыгып көткән иде дә, әмма аның өмете акланып җитмәде шул. Варисына хатын булыр дип көтелгән кыз бала юлда бик нык чирләп киткән, колчуралар, кашаудан, аны кулларына күтәреп кенә алып кертә алдылар.

Ачудан, гарьлектән ярсыган хан, коры киемнәрен киеп алгач, сабырсызланып, Шәптәк бәкнең үзенә килгәнен вә эшнең нидә икәнлеген аңлатканын көтә башлады. Шәптәк бәк тә әллә ни озаклап тормады. Мәхмүд хан аңа күз салып алу белән, тегесенең

үзен һич тә гаепле санамавын, киресенчә, кушылган эшне җиренә җиткереп башкарган кебек, тәкәллефсез генә басып торуын күрде. Хан кул ишарәсе белән аның сәламләү сүзләрен бүлде.

– Мин сезне көттем, бәк, сезгә ышанган идем. Соңгы хатыгыз күңелемә май булып ятты – сез бит, улыма-варисыма хатынлыкка нәкъ шундый – аның янәшәсендә мин күрергә теләгән кызны алып кайтам, дип язган идегез. Инде мин ни күрәм? Хәлил солтан яраткан хатынын җуйганга ярты ел да үтмәде, хәзер аңа тагын үлем сулышы кагылган бер кызны алып кайтасыз. Сез солтанның үзен җир йөзендәге иң бәхетсез кеше дип санавын телисез кебек. Кыскасы, варисымның рухы ныгысын өчен куйган бөтен тырышлыкларымның тамырына балта чабасыз. Мин җәза бирергә өлгергәнче, үзегезне аклап ни әйтә аласыз?

«Нурсолтан». Р.Шәмсетдинов рәсеме

– И безгә иркен-имин тормыш бирүче ханым-солтаным! – Шәптәк бәк, әле дә булса горурлыгын саклаган көе генә, хаким алдында билен бөккән булды. – Әгәр кушканыгызны үти алмаганмын дип саныйсыз икән, сезнең кулдан теләсә нинди җәзаны алырга әзермен. Тик Хәлил солтанга мин алып кайткан кызны гына ташламавыгызны үтенәм! Сез аның белән күрешеп, сөйләшеп алырга тиешсез. Күрерсез дә торырсыз: ул әле сезнең варисның иң яхшы хатыны булачак, ул аның өчен яратылган! Нурсолтанның юлда сырхаулап китүенә генә үземне гаепле саныйм. Морзабәкнең олысыннан чыкканда ук ул миңа агарынган һәм хәлсезләнгән кебек күренде. Әмма кызны карап-тәрбияләп торучы хатыннар, мине тынычландырып, бикә һәрвакыт искиткеч саулыгы белән аерылып торды, ул туган җиреннән аерылуга гына хәсрәтләнә, дип ышандырдылар.

Мәхмүд хан бәкне тыңлаган арада, үз уйларына чумып, бәкам агачыннан ясалган кечкенә тартманы кулларында әйләндерде. Аның эчендә Туктамыш хан хәзинәсеннән калган бәһасез алсу энҗе-мәрҗәннәр ята. Заманында ул энҗеләргә аның бөек атасы – Олуг Мөхәммәд хан ия булды. Инде, үз чиратында, Мәхмүд хан аларны варисының кәләшенә бүләк итәргә җыенган иде.

– Димәк ки, сез ул кыз гомерле булыр да улыма таза-сау балалар табар дип ышанасыз?

– Әйе, ханым-солтаным, – дип, нык тавыш белән җавап кайтарды Шәптәк бәк. – Моңа шикләнерлек бер сәбәп тә күрмим.

– Яхшы, бикәнең хәле яхшыра төшкәч, аның янына керермен. Тик сезнең белән улымның кәләше савыккач кына сөйләшәчәкмен. Шуңарчы күземә күренмәгез. Ачуым килгәндә, кайчак мин гадел булмыйм, шуңа күрә әлегә үзегезнең олыста ял итәргә киңәш бирәм...

Өч көн узды, ә Нурсолтанга саулыгы һаман әйләнеп кайтмады. Коры сөяккә калып ябыкты ул, якты дөньяда гаме булмаган хәлдә, хан сараеның үзенә бүленгән хөҗрәсендә ятуын белде, гомере өчен көрәшергә инде аны берни дә мәҗбүр итә алмас шикелле иде.

Шаһназ авыруның хәлен белергә кергәндә, көн кичкә таба авышкан иде. Нурсолтанның сеңлесе туйга әзерләнеп мәш килә, һәм шунлыктан аның хисләре тулып ташыган чак булды. Кызның дәртле-шат чыраен, янып торган кысык күзләрен күргәч, Нурсолтанның да йөзен хәлсез елмаю яктыртып җибәрде.

– Шаһназ, бәгырем, бу дөньяда әле минем күрәсем килгән бердәнбер кеше – син.

– Менә тагын! – дип пырхылдап куйды Шаһназ. – Шуңа ышандым дип уйлыйсыңмы?

Үләннәрдән шифалы чәй әзерләү белән мавыккан колчураларга күз кыры белән генә карап, Шаһназ кардәшенең битенә иелә төште.

– Хәзер синең дөньяда барысыннан да бигрәк кемне күрәсең килгәнен белмиммени? Безнең икебезгә дә билгеле бер егет кинәт кенә килеп керсә, син әле шигырь белән сөйләшә башлар идең.

Кыз, шукланып, башын артка чөйде дә, кулларын артына яшереп, кычкырып шигырь әйтә башлады:

Туктагыз, сау бул, дигәнче, миңа бер күз салыгыз!
Аерылу ачысын тойган җанымның өзелүен
Басар өчен, елмаерга да көчегез җитмәсә,
Йөрәгемне яндырганчы, яхшы – йөз кат үлүем.

– И Шаһназ! – Нурсолтанның ябык йөзендә инде гаять зур булып күренгән зәңгәр күзләреннән яшь бәреп чыкты. – Газаплама мине.

– Газапламаскамы? Анысын инде көтеп ала алмассың! Син, ахрысы, шул Мәңлегәрәең аркасында чынлап та үләргә җыенгансың. Йа Аллаһ, ә мин, ир-ат турында уйлап бу кадәр кайгырганчы, бармагымны чәйнәп өзәр идем. Үзләре минем аркада газап чиксеннәр!

– Шаһназ, тик мин берни эшли алмыйм, мин... мин аннан башка яши алмыйм, тугаенкаем. Сине яныма кертүләре әйбәт булган әле, соңгы үтенечемне җиткерергә җай чыкты хәзер...

– Соңгы үтенечеңне?! – Шаһназ, аптырап, бот чапты, шул тавышка гаҗәпсенгән хезмәтче хатыннар да борылып карамый булдыра алмады. – Аллаһ бүтән хәсрәт бирә күрмәсен! Мин сиңа үләргә юл куяр, дип уйлыйсыңмы?! Мин бу каланы табак кебек әйләндереп каплыйм, кирәк булса, бөтен дөньяны туздырам, әмма сиңа мине ташлап китәргә ирек бирмим!

Шул арада ул колчура хатыннарга борылып, усал караш ташлады:

– Нәрсә карап каттыгыз, тинтәк сыерлар, үз эшегезне белегез, югыйсә, мин сезне көтүгә куармын!

Шуннан соң гына Нурсолтанга кабат эндәште:

– Инде йомышыңны әйт, адәм баласының исәрлеген күрү рәхәтен күңелем булганчы кичерим әле.

– Бу бит акылсызлык түгел, Шаһназ. – Нурсолтан юрган астыннан нәзегәеп калган кулын чыгарды, калтырап торган салкын учы белән сеңлесенең беләгеннән тотты. – Ялварып сорыйммын, кәгазь белән каләм алып кил. Хат язармын, ә мин үлгәч, син аны Кырымга җибәрерсең...

– Кырымга хат... Әһә, имәндә икән чикләвек!

Бу сүзләрне әйткән уйчан ир-ат тавышы Нурсолтанны сискәнергә мәҗбүр итте, Шаһназ да урыныннан сикереп куйды. Кызлар алдында мәгърурана Мәхмүд хан басып тора иде.

Нурсолтанның, Шаһназдан аермалы буларак, үзен бирегә китерергә боерган Казан хакимен әле беренче тапкыр күрүе. Варисын Кырым ханы кызына өйләндерергә карар кылып, тормышын җимергән бу кешегә күңеленнән үпкәләгән-рәнҗегән булса да, инде аны үз каршында күргәч, Нурсолтан кинәт кенә тынычланып калды. Мәхмүд хан аның атасыннан күпкә өлкәнрәк, кечкенә генә күркәм сакалына чал кергән, аркасын никадәр генә төз тотарга тырышмасын, Нурсолтанның күзе чамалап алды: каршысында торган кеше тормыш ыгы-зыгысыннан һәм яшәү өчен көрәштән арыган-талчыккан булса кирәк. Маңгаендагы кайгылы җыерчыклар да, дөнья авырлыгы баскан җилкәсе дә, йончыган, сагыш белән мөлдерәмә күзләре дә шул турыда сөйли. Ләкин бу күзләрдә, алҗу һәм арудан тыш, кыз гап-гадәти кеше хәленә керү, мәрхәмәтлелек билгеләрен дә күрде. Зур давыл чыгасын көткәнлектән каушап калган Шаһназга карамыйча гына, хан кул ишарәсе белән аңлатты:

– Безнең икебезне генә калдырыгыз.

Шул мизгелдә үк колчура хатыннар да, Шаһназ да юкка чыкты. Ә хан авыруның ятагына якынрак китереп куелган кәнәфидә урын алды. Берничә минутка сүзсез калып, үз каршысында яткан кызны күздән кичерде...

– Менә син нинди икәнсең, Тимер кызы, – дип, үз-үзе белән сөйләшкәндәй, уйчан гына әйтеп куйды хан. – Мин синең яхшы чагыңа туры килмәсәм дә, танырга тиешмен: бу озын гомеремдә моннан да чибәррәк кыз күргәнем юк иде. Ә син гомерең белән хушлашырга һәм Кырымга хат язарга теләп ятасың. Әй, үз-үзеңә чамадан тыш ышанган яшьлек, син нинди матур һәм көлке!

– Тик, әфән... – дип башлаган Нурсолтан ханның зирәк, барысын да аңлый торган карашы астында ярты сүзен әйтә алмый тукталып калды.

– Дәшмә, кызым, барыбер бөтен хакыйкатьне ачып салмассың, ә миңа ялган кирәк түгел. Нәрсәдер әйтергә теләсәң дә, мин синең дөрес сүзең белән нишлим? Синең үләргә теләвең – Ходай Тәгалә биргән сынауларны алга таба күтәреп бармас өчен генә бит. Бөтен бәлаләрдән бер селтәнү белән котылу ничек җиңел, әйе, бу бик җиңел, балакай! Терек-сау калу, тормыш ничек кенә авырттырып кыйнаса да, аңа каршы күтәрелү күпкә авыррак. Күктәге хакимебез сиңа үз юлыңны күрсәткән инде, ул сине монда, куәтле Итил дәрьясы буйларына китергән, чөнки ул, зирәк Юлбашчыбыз, безгә – аның бик кечкенә колларына караганда ераграк, алданрак күрә. Безнең һәркайсыбызга бу дөньяга орлыгын чәчәргә, үзе рөхсәт иткән кадәр мөддәт яшәргә мөмкинлек бирә. Балакаем, сине хәзер авыру һәм сагыш биләп алган, син Аллаһ бакчаларына ашкынасың, анда күңелеңә тынычлык табарга телисең, әмма син ялгышасың, анда тынычлык булмаячак. Ходай Тәгалә сине бирегә үзеңне кирәк санаган кешегә ярдәм итәр өчен җибәргән. Моны эшләве җиңел булмас, әмма әлеге көрәштә синең авыртуың басылыр, син тормышның ямен күреп, тәмен татып яшәрсең, иншаллаһ. Минем сүзләрем турында уйла, кызыкай, үзеңнең куркуларың һәм бәлаләреңнең асылын аңла, сәбәбенә төшен. Якты дөньядан качып китәрлек дәрәҗәдә куркыныч вә зурмыни соң алар?

Нурсолтан гаҗәпләнеп, дәшми-тынмый Казан ханына карап ята. Ул әле аны нибары берничә минут кына белә, әмма янәшәсендәге берәү белән дә бу тикле нык, ышанычлы күңел тынычлыгы тапканы юк иде.

– Сез сөйләгән, янәсе, мине кирәксенгән кеше кем соң ул?

– Ул – минем улым Хәлил. Ул, Нурсолтан, синең булачак киявең.

Хан, каршы торуын туктатырга теләгән кебек, картларча бирчелгән, кабарынкы буынлы учы белән яшь бикәнең битенә җиңелчә генә кагылып алды.

– Ашыкма аны кире кагарга, аңардан баш тартырга ашыкма, балакай. Син әле Хәлилне күрергә, аның белән танышырга тиеш, менә шулчак мин сөйләгәннәрнең ба-

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

рысын да аңларсың. Син җитәрлек дәрәҗәдә акыллы, мин моны тоям, югыйсә, синең белән сөйләшеп тә тормаган булыр идем. Улымны кабул итәрлек көчең барлыгын сизү белән, миңа моны белдер, мин барысын да үзем җайлармын.

Хан, бизәкле-сырлы култыксаларга авыр гына таянып, урыныннан кузгалды.

– Шулай да үз карарыңны озакка сузма, кызым. Мин вакытым аз калып бара дип куркам, буыннарымның дәрманы бетеп килә. Җирдәге эшләремне төгәлләп өлгерми, теге дөньяга китеп баруым да ихтимал. «Тәкъдирдә язылган, вакыты билгеләнгән, һәр сулыш матәм касәсен эчәргә тиеш...» Әмма бу синең сүзләрең түгел, бу – инде юлының ахырына җитеп килүен күргән карт сүзләре. Савык, балакаем!

Хан саубуллашып башын какты да ишектән чыгып китте.

***

Мәңлегәрәй солтан инде икенче көн үзенең сугышчыларын туплаган кечкенә гаскәре белән иксез-чиксез даланы гизә иде. Вакыт-вакыт күзгә күренми торган канатлары Тимер олысына, Кырым солтанын көткән гүзәл Нурсолтан янына очыртып китә кебек тоела аңа. Мәңлегәрәй мондый чакларда үзен чиктән тыш бәхетле итеп саный. Аның тормышында әлегә барысы да уңай якка бара ич. Тимер морзабәк олысыннан өч көнлек юл ераклыгында Тын елгасындагы Зур Урда ханы Кече Мөхәммәд гаскәре белән Кырым ханы Хаҗигәрәй арасындагы сугыш кырымлыларның тулы җиңүен раслап, ифрат уңышлы төгәлләнде. Хаҗигәрәй хан бай табыш-мөлкәт алды, шуның өстенә, Кече Мөхәммәднең хәрәмендәге бөтен хатыннарга да ия булды.

Кырым ханының сугыш булган урында ук корылган тирмәсендә шау-гөр килгән мәҗлес вакытында Мәңлегәрәй атасына өйләнергә рөхсәт сорап мөрәҗәгать итте.

– Янә бер хатын алмакчы буласыңмыни? – Хаҗигәрәй хан йомшак кына елмаеп куйды. – Егетем, хатын-кыз затына артык күп көч түкмисеңме соң? Синең болай да ике хатының бар лабаса инде.

– Икесе дә, әнә, бәбиләргә тора, – дип, сүзне шаяртуга бормакчы булып, көлеп җибәрде солтан. – Ә миңа тагын хатын-кыз кирәк, ансыз тора алмыйм!

– Аның өчен өйләнү мәҗбүри түгел, – хан юмарт кулы белән бер читкә укмашкан хәрәм хатын-кызларына ишарә ясады. – Монда Кече Мөхәммәднең хатыннары һәм кәнизәкләре әнә күпме, үзеңә теләсә кайсысын ал! Бу яуда үзеңне чын сугышчы итеп күрсәттең, мин синнән канәгать, улым, ә сугышчы, җиңү тәмен чынлап татысын өчен, табыштан авыз итәргә тиеш. Дөрес әйтәмме?!

Тирә-якта, аның сүзләрен хуплап, мәҗлес шаукымыннан башлары әйләнә башлаган нойоннар һәм меңбашлары шаулашты:

– Мең яшә, бөек хан!

– Синең һәрбер сүзең – асылташ, ә боерыкларың күңелне иркәли, безнең кылычлар кыннарында бии башлый!

– Әмер бир, бөек хан, безнең белән хакимлек ит!

Хаҗигәрәй, ефәк мендәрләр түшәлгән киң яу тәхетеннән күтәрелде дә, өннәре алынган хатыннарга якынлашты. Сугышлар буенча аның тугры көрәштәшләре дә, күңел ачу вакыты якынлашканын сизеп, якынрак килделәр. Кырым ханы, кулыннан әләктереп, хатыннар төркеменнән нечкә билле бер кызны – ул әле куркудан күзләре зур булып ачылган бала гына иде булса кирәк – тартып чыгарды. Яшь җан иясе, алтын җепләр белән чигелгән япмага төренергә тырышып, җете киемнәре эчендә калтырана иде.

Хан, кызның очланып килгән ияген саллы балдаклар белән уралган нык бармаклары белән күтәрде дә:

– Исемең ничек? – дип сорады.

Кызның иреннәре калтырады, ул көчкә-көчкә генә үзен кулга алып:

– Зәлия буламын, хуҗам, – дия алды.

– Син элеккеге хуҗаң – куркак шакалның улы белән түшәк бүлештеңме?

Кызый ашыгып башын чайкады:

– Юк, тәкъсир, ханның хәрәменә күптән түгел генә килдем. Әле аның мине дәшеп алганы булмады.

– Мә, ал менә шуны! – дип, Хаҗигәрәй хан кызыкайны улына таба этеп җибәрде.

Аннары бармагы белән генә Мәңлегәрәйне чакырып китерде дә, колагына пышылдады:

– Ышан, улым, аларның барысы да бертөрле, хан кызы булды ни дә, гади кәнизәк булды ни. Сиңа хатын-кыз кирәк, дисәң, өйләнеп тору мәҗбүри түгел. Әгәр бусы ошамый икән, әнә ул чибәрләрнең башкасын сайлап ал. Берсе дә синдәй асыл егет ятагында төн чыгудан баш тартмас!

Шуннан соң, башкалар да ишетсен өчен, ул каты итеп кычкырды:

– И минем сугышларда чыныккан һәм бергәлектә көчле булган батыр яугирләрем! Җиңелгән дошманыбызның бөтен хатын-кызларын бүләк итәм сезгә! Сугышчыларым бу гүзәлләрдән үзләренә ял итү өчен түшәк ясасыннар дип телим!

Исерекләрчә көлү һәм җанлану шау-шуы хан табыны өстенә җылы төтен булып күтәрелде. Хаҗигәрәй исә улына таба борылды:

– Кыю солтан, син минем бүләгемнән канәгатьме инде?

– Мин сезгә бүләгегез өчен рәхмәт укыйм, әтием, тик миңа гади хатын-кыз гына кирәк түгел... – Мәңлегәрәй, үзенең мәхәббәтен нинди сүзләр сайлап аңлатырга белми, ирексездән уңайсызланып калды. – Минем өйләнеп яшәргә дәртем бар, әти... Мангыт Тимер морзабәкнең кызы Нурсолтанны хатынлыкка аласым килә.

– Менә ничек! – Атасы аңа аптырап карап куйды. – Безгә данлы сугышта ярдәм итәргә, хәтта җиңү шатлыгын бүлешергә дә теләмәгән кешенең кызынмы?

– Әмма ул, бөек хан, Кече Мөхәммәдкә дә булышмады бит!

– Һай, син аны ничек шулкадәр тырышып яклыйсың! – Хаҗигәрәй хан көтелмәгән рәхимлек белән көлеп җибәрде. – Димәк, сиңа өйләнергә кирәк, һәм бары тик Тимер морзабәкнең кызына? Хикмәт менә кайда икән!

Мәңлегәрәй, атасының күзләренә мәрхәмәт сорап карады да тынсыз-өнсез калды. Хан башын чайкап куйды:

– Мин бит шуннан курка идем, улым. Кайчан да булса синең гыйшкың хатын-кызга төшәр дип куркадыр идем. Тик хатын-кызга мәхәббәт сугышчыны көчсез итә, әмма монда инде берни дә эшләп булмавын күрәм. Күзләреңдәге бу утны сүндерү өчен иң ышанычлы чара – улымны сихерләгән кызга өйләндерү генә. Кабыргаңа якын, үзенең көндәшләреннән зарланып, мыгырдану-сукранудан туктый алмый торган хатын, гомер буе син хыялланып яшәгән, сынап карамаган хатын-кызга караганда, ир-ат йөрәгендәге мәхәббәтне тизрәк үтерә. Хет иртәгә үк морзабәк олысына юл тота аласың! Тик баерак, зиннәтлерәк бүләкләр җыеп бар! Зур Урданы җиңгән Кырым хакименең улы теләсә кайсы кызга яучы җибәрә ала!

Менә инде морзабәк олысына җитәргә бер көнлек юл калды. Нибары бер көн, аннары ул Нурсолтанны күрәчәк, аның онытылмас күзләренә карап: «Вәгъдә иткәнемчә, мин синең артыңнан килдем, Нурсолтан!» – диячәк. Күкрәгендә җылы дулкын булып җәелгән бу уйлардан тагын да күңеллерәк булып китте. Мәңлегәрәй чабышкыны камчысы белән куалады, үзенең нөкәрләрен әллә кайда артта калдырды. Алга, тик алга гына! Ул морзабәкнең җәйләвенә мөмкин кадәр тизрәк барып җитәргә тиеш, аның Нурсолтанны күрәсе килә, аерылып торуның һәр сәгате мәңгелектән дә озаграк булып тоела!

Тик, тукта әле, алда нәрсә соң бу? Мәңлегәрәй чабышкысын тыя төште. Җәйге кояш астында кипкән-яргаланган дала буйлап, тузан өермәсе күтәреп, аңа каршы нindiдер җайдаклар төркеме килә иде. Солтан артына борылып карады, аның сугышчылары шактый еракта калган, ә монда, далада, дусны очраткан кебек дошманга тап булуың да бар, ялгыз җайдак булганчы, яхшы коралланган гаскәр башында баруың хәерлерәк шул. Мәңлегәрәй атын туктатты...

Күбеккә баткан чаптарлардагы нөкәрләре, каршыга очып килүче төркемдә инде аерым җайдаклар күренә башлагач кына, аның белән тигезләнде. Тимер морзабәкнең олысына элегрәк барган сугышчыларның иң үткен күзлесе, өзәңгеләрдән күтәрелә төшеп, кычкырды:

– Хуҗам, мин Хөсәен морзаны күрәм, болар – аның олысы кешеләре...

Мәңлегәрәй инде үзе дә яу башында дусты Хөсәен морза – Нурсолтанның абыйсы килгәнен танып алды. Морза белән солтан, атларыннан төшеп, кочаклаштылар.

– Яшь әфәндегә сәлам вә дога! Сезне исән-имин күрүемә тәшәккермен, дустым! – Хөсәен морза Кырым солтанының җилкәсеннән какты. – Сезнең җиңүегез турында хәбәрләр безгә килеп җитте, мин сезнең уңышыгызга шикләнмәгән дә идем. Дустым үзе яуга чыкканда моңа шикләнеп буламыни?

– Син һәрвакыттагыча шаяртасың, Хөсәен! Әйдә, утырып алыйк, – дип елмаеп, солтан юлдашлары җәеп өлгергән киез өстенә кырын ятты. – Сөйләп җибәр әле: сезнең олыста нинди яңалыклар бар?

– Нинди яңалыклар булсын? Тиздән көз җитә! – Хөсәен морза офыккача җәелгән далага кулы белән ишарәләде. – Ат һәм сарык көтүләре бөтен азыкны диярлек ашап бетерделәр, әти мине ерак көтүлекләрне тикшерергә җибәрде, тиздән күчмәк башлана.

– Димәк, әле мин сезнең олысны элеккеге җирендә күрә алам.

– Билгеле, шулай, Мәңлегәрәй, әгәр син минем белән озаграк җәелеп утырсаң! – Хөсәен күңелле генә көлеп куйды. – Дөрес, олыста инде барысын да очрата алмассың.

– Анда син булмассың, – дип, сөйләшүнең шаян-шук агышына кушылып, Мәңлегәрәй дә көлеп җибәрде.

– Мин анда, әлбәттә, булмам, ә тагын гел көләсе килеп торган сеңелкәйләрем Шаһназ белән Нурсолтан да юк инде.

– Нурсолтан? – Кинәт муенына каты элмәк салынгандай, Мәңлегәрәйнең сулышы кысылды.

Авырлык белән генә сүзен дәвам итә алды ул:

– Ә Нурсолтан кайда? Аңа ни булды?

– Ул еракта, дустым. Сеңелкәшләр икенче ай инде Казанда. Беләсеңме, Нурсолтан Казан ханы варисының хатыны булды. Сеңлем Казан ханымы булачак, ул шундый дәрәҗәгә лаек!.. Син нишләдең, Мәңлегәрәй? Мәңлегәрәй!

Хөсәен, аптырап, Кырым солтанының кинәт тәненә сыймый башлаган кебек сулышын кыскан камзулына, агарынган бәхетсез чыраена текәлде. Мәңлегәрәйнең кесәләреннән кызыл якут белән бизәлгән алтын каптырмалар гади чуерташлар төсле киез өстенә коелды, куеныннан энҗеләр белән чигелгән бәрхет янчык килеп төште. Акылын җуйган кешедәй, ул Хөсәенгә карап катты. Тыңларга теләмәгән бармаклары белән янчыкның тасмасын чиште, аннан саргаеп баручы үлән өстенә зәңгәр якуттан эшләнгән гаҗәеп матур муенсаны алып ташлады.

– Мин боларны аңа дип алып килә идем... Зәңгәр якутларны аның күзләренә туры китереп сайладым. – Солтанның хырылдап сөйләвен аңлавы шактый читен, аның үзен дә танырлык түгел иде. – Ничек болай булды, Хөсәен дустым? Ничекләр генә шулай килеп чыкты соң?!

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

ӘҮЛИЯЛАР ВАТАНЫ – КҮБӘКӘЙ

*Узган ел редакциябезнең иҗат төркеме Курган өлкәсенә сәфәр кылды. Шунда Күбәкәй авылында булырга, аның имам-хатыйбы **Габдерәшит Баһаветдин** улы **Камалов** белән очрашып сөйләшү насыйп булды. Бу авылга килүебез очраклы түгел иде, чөнки Күбәкәй дөньяда 11 әүлияны биргән бердәнбер татар авылы, шуның өстенә аның янәшәсендә генә Россия күләмендә мәшһүр Коелтөп күле (Горькое) урнашкан. Әлеге авыл, әүлияләр һәм, әлбәттә, күл тарихы турында хәзрәт сөйләгәннәрне без зур кызыксыну белән тыңладык.*

БЕЗ – МИНЗӘЛӘ ТОКЫМНАРЫ

Авылыбызга халык 1736 елны Уфа ягыннан килеп урнашкан. Беренче авыл урман читендә булган, ул Бохар дип аталган. 1742 елга кадәр шул исемдә йөртелгән. Бу бәләкәй авыл янгач, халкы Әлмән ягына күчеп киткән. Хәзер дә анда Бохар авылы бар[1].

[1] Ризаэддин Фәхреддин Бәхар дип яза. Курган өлкәсенең Каргапольский районында тагын бер Бахарево авылы бар. Әлмән районындагы Бохар авылы дөнья картасында юк, ул юкка чыккан авыллар исемлегенә кертелгән.

1742 елны Минзәлә ягыннан килгән татарлар авылны яңадан торгызып җибәргән. Без үзебезне Минзәлә токымнары дип исәплибез. Шул елдан авыл Күбәкәй исеме белән атап йөртелә.

Бүген Күбәкәйдә Курорт, Камышлы күл буендагы Боровичи авыллары өчен уртак бер мәчет булса, заманында авылыбызның үзендә генә дә өч мәчет эшләгән. Күл артында – кечкенә, хәзергесе янында – олы мәчет, юл буенда Әхмәтҗан бабай мәчете булган. Авылда 1901 елда 165 хуҗалыкта – 924 кеше, 1926 елда 256 хуҗалыкта 1221 кеше яшәгән[2].

«КУ, БӘКӘЙ!»

Риваятьләргә караганда, авылыбызга беренче нигез салган кеше ерактан килгән юлчы булып, көннәрдән беркөнне ул ат эчерергә күл буена туктаган. Суга керү белән, юлчы гаҗәпкә калган: күл нинди зур, әмма шактый сай, атның тубыгыннан гына икән. Шуннан юлчы атына: «Ку, бәкәй!» – дигән. Юлчы биредә төпләнеп калган, өй салган, аның янына башкалар да килеп урнашкан. Шулай итеп, күл һәм авылның исеме Күбәкәй дип атала башлаган.

БАХАРЕВ ФАМИЛИЯЛЕ УРЫС

Авылдан ике чакрым ераклыкта Бахарев фамилияле урыс маллар тоткан, аның зур гына утары да булган. Безнекеләр дә шунда барып, эшкә ялланган. Шуннан авылыбызның исеме урысча Бахарево дип атала башлаган[3].

ЧТЗ КҮБӘКӘЙ КИРПЕЧЕННӘН ТӨЗЕЛГӘН

Авылда 1924 елда промартель оештырып, кирпеч заводы ачканнар. Халыкның яртысыннан артыгы шунда хезмәт куйган, көне-төне кызыл кирпеч җитештергән. Авыл халкының бер өлеше юл буенда, аяк белән яки атлар ярдәмендә таптап, балчык баскан. Әзер кирпечне, атларга төяп, Алакүл станциясенә ташыганнар. Атаклы Чиләбе трактор заводы күбәкәйлеләр ясаган кирпечтән төзелде. Кирпеч заводы 1952 елга кадәр уңышлы эшләде. Казылма күл буеннан бу елларда ясалган кирпеч калдыклары әле дә килеп чыга, алар шултикле нык, намус белән эшләнгән ки, суга да бирешми, ничә еллар ватылмый сакланган – чималы яхшы булган. Заманында авыл халкы чүплекләрдән шул ватык кирпеч калдыкларын җыеп, йортларга фундамент салды. Бу йортлар әле дә төзек килеш тора.

КОЕЛТӨП КҮЛЕ

Хәзерге Горькое исеме белән сез белгән күл урынында кайчандыр наратмы, чыршымы урманы була. Көннәрдән беркөнне ул уртасыннан корый башлый һәм җире комлы урын булу сәбәпле, «коелып» төшә. Хасил булган чокырда тозлы чишмә бәреп чыга.

Бу күл күп авырулардан дәва. 1982 елда аягымны сындыргач, мине Львов өлкәсендәге бер санаторийга җибәрделәр. Врачлар Горькое күле буендагы авылдан килгәнемне белгәч, кире кайтып, шундагы ләм һәм балчык белән дәваланырга кушты. Аяк сырхавы өчен, Львовтагы торф балчыгына караганда, Коелтөп күленең ләме, балчыгы күпкә шифалырак, хәтта Үле күлдән дә сихәтлерәк икән. Бөек Ватан сугышы чорында да күл буенда урнашкан хәрби госпитальдә дәваланып аякка баскан солдатларның саны бик күп булган.

[2] Статистик мәгълүмат безнең тарафтан төзәтелде.
[3] Бу вакыйга алдагы Бохар белән бәйлеме, әллә соңрак булганмы – без белмибез.

Коелтөп (Горькое) күле

УН ИР-АТ ҺӘМ БЕР ХАТЫН-КЫЗ ӘҮЛИЯ

Хәйретдин, Сәгъдеддин, мулла Хәсән углы Таҗетдин, Баһаветдин, Гайнетдин, Зыятдин, Зәйнәгетдин, Насретдин бабай – болар мин исемнәрен хәтерләгәннәре генә. Күбәкәйдән барлыгы ун ир-ат һәм Иннекамал Вилдан кызы исемле бер хатын-кыз әүлия чыккан. Насретдин бабай турында авылыбызда риваятьләр бик күп, әмма аның тарихы язылмаган. Ул халыкка бик ярдәмчел кеше булган.

Насретдин әүлия

Тайлар

Ат караучы Шәрип бабайның бер төнне тайлары чыгып качкан. Ул ун яшьлек улын Насретдин бабайга җибәргән: «Менә сиңа биш сум акча бирәм. Насретдин бабаеңа барып сора, безнең тайлар кайда йөргәнен белмиме икән?» – дигән.

Насретдин бабай малайны күрүгә:

– О-о, минем Мәрьям оныгымның булачак кияве кереп килә икән бит, – дип каршы алган.

Малай:

– Мине атаем җибәрде, – дигән.

Насредин бабай:

– Әйе, әйе, беләм. Тайларыгыз чыгып киткән икән... Әйдә, кер. Әбисе, чәй яса, – дип, аны табын янына чакырган.

Малай:

– Ю-у-к, атаем сүгә, мин эчмәем, – дигән.

Насретдин хәзрәт:

– Юк, балам, әйдә чәй эчәбез, алайса, атларың кайда икәнен әйтмим, – дип, сүзендә нык торган.

Болар табын янына утырганнар. Бер чынаякны эчкән, хәзрәт икенчене ясаттырган. Малай тагын карыша төшкәч, бабай:

– Юк, балам, менә монысын да эчсәң, атларың күл буена су эчәргә төшәрләр, – дигән.

Чәй эчим, дип тәлинкәне күтәргән малай ни күрә: атлар күл буенда су эчеп йөриләр икән. Еллар узгач, егет бабайның кияве дә булып куйган.

Инәең икеләнде

Бер әби улын сугышка озата икән. «Йә, балам, сау-сәламәт йөреп кайт!» – дип, изге теләкләрен теләгән. Эчтән генә болай уйлап куйган: «Исән-сау йөреп кайтса, Насретдин бабайга бер күлмәк биреп, дога кылдырам».

Улы сугыштан исән-имин кайткан, нык җәрәхәтләнмәгән. Әби күлмәкне алган да: «Малаема да ярап куяр иде анысы, ярар, нәзер әйткәч, илтим инде», – дигән. Иртән торгач, хәлне улына аңлаткан: «Менә шуны Насретдин бабаңа алып барып, дога кылдыр».

Насретдин бабай егетне шатланып каршы алган, чәй ясап, кунак иткән. Карт гаять кызыксынучан булган, аннан сугыш хәлләрен сораштырган. Чәй эчеп, дога кылгач, хәзрәт: «Аллаһу әкбәр!» – дип, күлмәк белән битен сыйпаган да: «Балам, син яшь кеше. Бу күлмәкне үзең генә киеп туздыр инде. Инәең әз генә икеләнде», – дигән. Улы, өйгә кайткач, ни булганын сөйләп биргән. Карчык та хәлнең нидә икәнлеген аңлап, бик уңайсызланган.

Елан чагу

Авылыбызга Абдулла исемле мәзин килеп төпләнгән. Шулай беркөнне Насретдин хәзрәт: «Абдулла, бүген мәчеткә барма. Елан күп, чагып куймасын», – дигән. Мәзин тәһарәт алып йөргәндә хатыны да:

– Абдулла, Насретдин сиңа әйтте. Син барма бүген мәчеткә. Алла сакласын, авыр еллар, – дип кисәткән.

Абдулла:

– Әй, ул Насретдин нәрсә белеп бетерә! – дип көлгән.

Мәчеткә барып: «Аллаһу әкбәр!» – дип әйтүе булган, мәзинне арестовать итеп, алып та киткәннәр. Шул китү белән авылга бүтән әйләнеп кайтмаган. «Елан чагу» менә шулай булган.

Сталин ни карый?

Соңрак Насретдин бабайны да: «Гитлер сугыш башларга маташа, Сталин ни карый икән?» – дип сөйләгәне өчен, халыкка коткы таратуда гаепләп, Сафакүлгә, Күбәкәйнең кирпеченнән эшләнгән төрмәгә алып китеп ябалар. Каравылчы иртән килеп караса, ни күрә: бабай төрмәнең тышында намаз укып утыра, ә төрмә йозакка бикләнгән. Бабай дога кыла да юк була. Бу хәл бер көн шулай кабатлана, икенче көн... Өченче көн милиция начальнигы:

– Бабай, ник син намазыңны тышта укыйсың? – дип сорый.

– Анда бит шайтан оясы, ә мин биш вакыт намазымны калдырмыйм, – ди икән бабай.

– Ә кайдан чыгасың соң син?

– Ишек ачыла да мин чыгам...

Насретдин хәзрәтнең таягы һәм тәсбихы – Кубәкәй авылы мәчетендә кадерле ядкәр

– Йозак тора бит?!

– Тора бирсен... Ул миңа комачауламый!

– Иртәгә син миңа могҗиза күрсәт әле. Әгәр дә башкара алсаң, мин сине өеңә кайтарам.

– Йә, балам, эшкә килүеңдә мин синең бүлмәңдә утырырмын, – ди бабай.

Иртән милиция начальнигы килсә, Насретдин бабай моның бүлмәсендә Коръән укып утыра икән. Бу хәлне күргән милиция начальнигы аны кайтарып җибәрергә мәҗбүр булган.

Үз җае белән кайткан

Насретдин хәзрәт Атҗитәр авылындагы дустына еш кына кунакка барган. Ул гел җәяү йөрергә яраткан. Шулай берзаман бабайны, Атҗитәрдән кайтышлый, атына утын төягән берәү куып җитә һәм уйлап куя: «Насретдин бабайны да утыртсам, атым бөтенләй арырмы икән инде, әүлия кешене утыртмасам да уңайсыз».

Картны куып җиткәч:

– Әссәләмегаләйкем, Насретдин бабай! Әйдә, утыр, ял итеп барырсың, – ди.

– Юк, балам, атың арган. Мин җайлап кына үзем кайтам, – дип җавап бирә карт.

Егет авыл урамына кереп килүгә ни күрә: Насретдин бабай капка төбендә утыра икән.

Кайтырлармы, юкмы?

Сугыш вакытында ирләре, балалары фронтта булганнар да Насретдин бабай янына еш килгән. Берзаман минем Мәнзифә һәм Бибикамал әбиләрем дә аның янына килеп, ирләре турында сораган. Насретдин бабай: «Бибикамал, Шәфик юк ул, көтмә аны. Ә синең Габделганиең сугышып йөри», – дигән. Икенче көнне Бибикамал әбигә Шәфик бабайның һәлак булуы турында «похоронка» килгән.

Шуны да әйтергә кирәк: Насретдин бабайның ике улы да Бөек Ватан сугышында катнаша. Галәветдин исемле улы II нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә, авылыбызга кайтып укытучы булып эшли. Ә Рәҗәп исемле улы яу кырында батырларча һәлак була.

Дога укучы – Күбәкәй авылы имамы Габдерәшид хәзрәт Камалов. 1952 елда вафат булган Насретдин әүлияның каберенә куелган таш

1838 елда вафат булган Таҗетдин мелла Хәсән углының кабер ташы

***

PS: Күбәкәй зиратында өч әүлия –1838 елда вафат булган Хәсән углы Таҗетдин, 1952 елда бакый дөньяга күчкән Насретдин бабай һәм Иннекамал Вилдан кызының каберләре билгеле, аларның беренче икесен без дә барып зиярәт кылдык. Һәр ел май аенда мөселманнарның бирегә җыелып дога кылуы, соңыннан, күлнең аргы ягында, бер әүлия йорты булган урында Коръән ашы уздыруы күркәм гадәткә әйләнгән. Кайбер елларда әлеге мәҗлескә 250ләп кеше җыела икән.

Насретдин бабайның тормыш юлын, аның нәсел-нәсәбен һәм башка әүлияларны да җентекләп өйрәнү сорала. Ризаэддин Фәхреддиннең атаклы «Асар» дигән хезмәтендә Чиләбе төбәге Бәхар авылына мөнәсәбәтле ике имам Габделбакый бине Габделлатыйф бине Гаедкол һәм Нигъмәтулла бине Ишбулад бине Ишгали бине Иргали бине Бәхарлар турында языла. Аның беренчесе – Габделбакый хәзрәт, Бәхарда имамлык итеп, 73 яшендә, 1889 елда вафат булган. Аның улы имам һәм ахун Әхмәдвәли бине Габделбакый бине Габделлатыйф булганлыгын күрәбез. Икенчесе – Нигъмәтулла хәзрәт, Габделәхәд бине Габденнасыйр әл-Әлмәни шәкертләреннән булып, Бәхар авылында имамлык һәм мөдәррислек кылган, гомерен гыйлем белән шөгыльләнеп, шәкертләр тәрбияләп уздырган, 1902 елда бакый дөньяга күчкән. Аның үзеннән соң Гыйниятулла, Гыйсмәтулла, Садретдин, Зыятдин, Фатыйма, Газизә, Лотфулла, Гатаулла, Һидиятулла, Гыйсметдин, Гайшә, Сафиулла, Габделһади, Хөснеҗиһан, Габделбари исемле балалары калган. Әлеге имамнар һәм аларның балалары алда телгә алынган әүлиялар белән нинди мөнәсәбәттә булган? Монысы – киләчәктә ачыклыйсы мәсьәлә.

Текстны басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Чал тарихлы Кодашым: алып батырлардан «чабаталы аклар»га кадәр

Фәһимә Газизова

«АЛЫПЛАР ӨСТЕ»НЕҢ СЕРЕ ЯКИ КЕМНӘР АЛАР «ОЗЫН КЕШЕЛӘР»?

Пермь крае Барда районында Кодаш авылы исеме белән бәйле 3 археологик һәйкәл бар. Алар 1989-2000 елларда Удмуртия дәүләт университеты археологы Ольга Казанцева җитәкчелегендәге экспедиция тарафыннан казып тикшерелгән. Шуларның иң борынгысы – тимер гасырның башлангыч чарына нисбәтле Кодаш шәһәрлеге. Ул Зур Әмҗе елгасы буенда, Бәкинтауда, авылыбыздан 1,7 чакрым ераклыкта урнашкан. Безнең халык аны «Шайтан каласы» дип тә йөртә. Шәһәрлек төньяктан – ике, көньяктан – дүрт, көнчыгыштан ике үр белән ныгытылган, ә көнбатыш өлеше текә яр белән чикләнгән. Тикшерү эшләре вакытында керамика кисәкләре, хайван сөякләре, эшкәртелгән чуерташлар табылган.

Археологлар өчен Кодаш авылыннан 50 метр гына ераклыкта урнашкан борынгы зур каберлек – «Алыплар өсте»н өйрәнү дә гаять кызыклы фәнни табыш бирде. Бу зур зират IV-V гасырларга, ягъни тимер гасырның иң соңгы чорына карый. Биредә О.Казанцева җитәкчелегендә бер курган һәм 50 кабер казып тикшерелде, аннан алынган материаллар тарихчыларның (О.Казанцева, Г.Ракушина) гына түгел, ә биология, антропология белгечләренең (О.Богаткина, Р.Юсупов) дә игътибарын җәлеп итте.

Гадәттә, борынгылар, мәетне җирләү йоласын үтәгәч, кабер тирәсенә биек итеп балчык өйгән. Аннан соң, төрле вакытларда искә алу йоласын үтәгәннәр булырга тиеш: казу эшләре вакытында нык кыздырылган хайван сөякләре, савыт-саба ватыклары табылу – шуңа дәлил. Белгечләр мал-туар сөякләренең корбан итеп чалынган ат, кәҗә, сарыкныкы икәнлеге турында язды. Каберләрдән тимер кылычлар, көбә киемнәр, шлемнар, ук очлары, балталар, бронза, көмеш һәм тимердән ясалган перәшкәләр табылу биредә хәрбиләр җирләнгәнлеге турында сөйли. Хатын-кызлар кабереннән исә муенсалар, бронзадан ясалган асма бизәкләр, сәйлән, беләзекләр, көнкүреш әйберләре һәм савыт-сабалар табылды.

Без кечкенә вакытта биредә «озын кешеләр күмелгән», дип сөйли торганнар иде. Шул каберләр турысыннан үткәндә әни: «Кызым, Әгузе-бисмилләңне укып уз алыплар өстен», – дип еш кисәтте. Элек-электән каберлеккә юк-бар сәбәп белән кереп йөрү катгый тыелып килә. Кодаш авылында шундый бер риваять тә бар. Имеш, берәү «озын кешеләр» кабереннән алтын башлык (шлем) казып алып, аны өенә алып кайтып киткән. Йокыга талгач, һәр төнне төшендә аннан теге сугышчылар башлыкны сорап йөдәтә икән. Шактый гына газаплы төшләрдән соң, ул бу башлыкны кире кайтарырга уйлый һәм каен агачы төбенә күмеп тә куя. Шунысы кызык: бу риваять реаль факт белән дә раслана. Дөрестән дә, казу эшләре алып барган курган өстендә каен үсә, каберлекнең элек талау максатыннан казылганлыгы билгеле, ә иң әһәмиятлесе – биредә хәрбинең шәхси әйберләре һәм, әлбәттә, теге башлык та табылды. Дөрес, ул алтыннан түгел, ә тимердән эшләнгән.

Каберлеккә җирләнгән 20-25 яшьлек сугышчы баһадирлар, кайчандыр җирле чибәркәйләргә өйләнеп, аларның уртак балалары да тугандыр. Күчеп килгән борынгы яугирләр һәм безнең борынгы бабаларыбыз арасында туганлык җепләре дә булуы ихтимал. Кодаш каберлеге зур мәйданны били, кызганыч, аның бер өлеше сукаланган һәм «кара археологлар» тарафыннан таланган.

Өченче археологик һәйкәл – борынгы авыл урыны Кодаштан 45 метр көньяк-көнбатышта урнашкан. Монысы исә ил тыныч вакытта ял итү, авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнү, ә канкойгыч сугышлар вакытында хатын-кыз, бала-чага һәм карт-коры өчен яшеренү урыны булып торгандыр.

«КОДА АШЫ»МЫ ЯКИ «КУ ДАШЬ»МЫ?

Кодаш тарихына бәйле тагын берничә риваять бар. Аның беренчесе болайрак: *«Казан ягыннан бирегә Керлем, Морат, Шәмси дигән өч татар беренче килгән...»* Хәзерге вакытта авылыбызда бу шәхесләр исеме белән аталган өч чишмә бар. Шунысы да игътибарга лаек: әлеге чишмәләр археологик һәйкәл дип саналган калкулыкларның итәгеннән челтерәп ага.

Авылның исеме турында болайрак сөйләүчеләр булган: *«Удиктән начар ният белән килүчеләрне биредә «кода ашы» белән сыйлаганнар. Шуннан авылга «Кодаш» исеме бирелгән»; «Ике рус кешесе очрашкан, ди. Берсе икенчесеннән: «Бу авыл ничек атала?» – дип сораган. Икенчесе – ут чыгарырга чакматаш тотканы әйтеп куйган: «Ку дашь?» (Ку – агачта үскән коры гөмбә.) Шуннан бу авыл «Кудаш» дип аталып калган, ди».*

Татарстан Республикасының Питрәч, Бөгелмә һәм Әгерҗе районнарында, Башкортстан Республикасында һәм хәтта Тула өлкәсендә дә Кодаш исемле авыллар бар. Ә бәлки бирегә кайчандыр Кодаш исемле морза күчеп килгәндер дә, аның балалары, таралып, торган җирләрен ата-бабалары хөрмәтенә Кодаш дип атагандыр...

ДОКУМЕНТЛАР НИ СӨЙЛИ?

Кодаш авылы язма чыганакта беренче мәртәбә 1712 елда теркәлгән. Бирегә Түбәнавылдан Рахмангуловлар – Мурат, Садыйк, Хәмит гаиләләре килеп урнашкан. Соңрак Түбәнавылдан Барсаев Ачкан бабай, Рангулов Сабир һәм Мурзыев Сәгади гаиләләре күченгән. Тауавылдан Тугумов Акиш бабай гаиләсе дә килеп төпләнгән. Н.М.Кулбахтинның хезмәтендә: «1775 елда Кудаш авылында 48 ир-ат татар яши», – дип язылган. 1773-1775 еллардагы Пугачев ставкасында теркәлгән 22 авыл исемлегендә Кодаш та бар.

КОМГАН ДА КАЕН ТУЗЫННАН

Кодаш барлыкка килгән чорда аның тирә-ягы калын урман белән уратып алынган. Йорт урыннары һәм урам юллары түзлек* арасында була. Бу вакытта әле керосин лампалары булмый, кешеләр кичен чыра яндырып кына яшәгән. Хәтта комганнар да каен тузыннан эшләнгән.

Гата Нияз улы Барсаев сөйләвенә караганда, Кодаш кешеләренең иң әүвәлге һәм борынгы кәсебе урман эше, агач әзерләү һәм аучылык булган. Гасырлар узу белән, агач әзерләү эше тагын да киңрәк колач ала. Мәсәлән, 1890-1900 елларда Кодаш авылында Оса байларының агач кабул итү пристане оештырыла. Крестьяннарның күбесе кышын агач кисеп, аны урман эченнән чыгарып, язын исә Әмҗе суы буйлап калын бүрәнәләрне агызу белән шөгыльләнгән. Аучылар, кап сугу, мунчала ясау, паласка вак юкә төшереп сату белән дә кәсеп итүчеләр күп булган.

1901-1910 елларда Вотяково (Безымянная) ягыннан янгын чыгып, шактый гына мәйданда урман яна. Олы елга, Усаклыбаш, Көмешле авылларының халкы, янгыннан файдаланып, урманнарның калган өлешен дә яндырып, җир эшкәртә һәм иген игә башлый. Бу чорда крестьяннар төрле участокларда күрше-тирә авыл кешеләре белән бергә эшләгән, кустарьчылык та сакланган.

ОЛУГ ЗАТЛАР

Кодаш авылы халкы элек-электән абруйлы, укымышлы муллаларның тәрбиясен тоеп яшәгән. Гәрәй, Ягафарсадыйк муллалар авылдашларыма һәрьяклап үрнәк булган. Мәсәлән, Рангулов Ягафарсадыйк мулла, үзенең биш баласы өстенә, туганнары Ишмановларның ике улын – Мирхаҗ һәм Габдулланы да алып тәрбияли. Алар егет булып үсеп җиткәч, муллага иген игәргә яхшы ярдәмче булган. Ягафарсадыйкның Вәриз яктагы җирләрендә печән дә әзерләгәннәр, молотилка белән иген дә сукканнар. Соңрак хәзрәт Габдулла абыйга йорт салып, молотилка да биреп, аны башка чыгарган. Ягафарсадыйк мулланың ишле, тату гаиләсенә ачлык елда Минзәлә ягыннан килгән сеңлесе белән Сандугач әби дә сыенган. Соңрак Сандугач әби җиде ел чамасы авырып, урын өстендә яткан.

Ягафарсадыйк мулла мәчет янына агачтан алтыпочмаклы мәдрәсә салдырган,

---

* Түзлек – агач төбе.

төзелеш чыгымын да үзе күтәргән. Хәзрәтнең бакчасындагы беркатлы мәдрәсәне авылыбыз аксакалы Ишманов Барый абый яхшы хәтерли. Ягафарсадыйк хәзрәт мәдрәсә белән җитәкчелек тә иткән, авылга һәркөн матур, моңлы азан тавышын да яңгыраткан. Биредә укучы шәкертләр, дини белем алу белән бергә, дөньяви фәннәрне дә өйрәнгән.

Барсаев Гәрәй мулла – Ягафарсадыйк мулланың әнисенең энесе. Шуңа да алар һәрвакыт бер-берсенә ярдәмләшеп яшәгән. Гәрәй мулла, балаларга белем бирү белән бергә, авыр елларда шәкертләргә бушлай төшке аш та ашаткан, мохтаҗларга кием-салым да тараткан. Мулланың үз кибете дә булып, аннан алган керем төзелешкә һәм хәер-сәдакага тотылган.

Дин әһелләре хөкүмәткә даими салым да түләп барган, ә укыткан өчен аларга дәүләт тарафыннан бер тиен дә бирелмәгән. Шуңа да карамастан, мөхтәрәм затлар динебезне, телебезне саклап калган, туган халкы өчен игелекле эшләр башкарган.

ИҢ ЗУР МӨЛКӘТ - ҖИР

1911-1912 елларда җирләр патша хөкүмәте тарафыннан авылларга бүлеп бирелә. Закон нигезендә ул биләмәләрне «душевой», «свободный» дип йөрткәннәр. Кодаш крәстиәннәре өлешенә хәзерге Олы Уса районының Кашкалак авылы биләмәсендә йөзләрчә гектар җир тәгаенләнә. Җир күләме һәр ир затына 7,5 гектар тигән.

Әмма комсыз түрәләрдән җирне алай тиз генә алырмын, димә! Авыл һәм волость башлыклары Олы Усадагы җирләрне һәр елны Кашкалактагы урыс крәстиәннәренә саткан. Шунлыктан, кодашлылар бу биләмәләрдән тулысынча файдалана алмаган. Аңлашыла ки, сатылган җирләрнең акчасы авылыбыз кешеләре файдасына бик аз микъдарда гына «тамган», аның шактые түрә-кара кесәсен генә калынайткан.

1913-1915 елларда авыл байлары, хәлле муллалар җирләрнең иң яхшы урыннарын ярлылардан сатып ала башлый, бу хәл, Беренче Бөтендөнья сугышы башлангач, тагын да көчәя. Барсаев Гәрәй мулла утызлап хуҗалыкның җиренә хуҗа була. Рангулов Ягафарсадыйк мулла Керпелебаш басуын, Барсаев Фаяз Керпеле басуын, Машаев Закир Куш чишмәдән Урта чишмәгә кадәр мәйданны һәм Озын елга башындагы игенлек җирне үзләштерә.

Хәлле крәстиәннәр үзләреннән арткан икмәкне Оса шәһәре сәүдәгәрләренә поты 40-50 тиеннән саткан. Кайбер мәнсез крәстиәннәр икмәк саткан акчаны хәмер эчеп, кәеф-сафа коруга исраф иткән. Шул сәбәпле, алар гаиләләрен кышын байга эшләп, бурычка икмәк алып туйдырган. Мондый гаиләнең әгъзалары йә ялангач калган, яисә бөтен киемнәре киндердән тукылган. Тукыма өчен сүсне, чүбәкне Олы Уса тирәсендәге авыллардан, Оса өязе урысларыннан сатып алганнар. Житен чәчү һәм эшкәртү эше Кодашта 1921-1922 еллардагы ачлыктан соң гына башлана.

«БОЛЬШЕВИК БУЛМАМ, МУЛЛАЛАРГА КАРЫШМАМ!..»

Авылда социаль киеренкелек көчәя. Көннәрдән беркөнне Кодаш авылы крәстиәне Рахмангулов Арыслан, муллаларга ачу һәм нәфрәтен белдереп: «Чалмагызны бәреп төшереп, аякка чорнар вакыт килеп җитәр әле», – дип ычкындыра. Бу сүз авыл мулласы Барсаев Гәрәйгә ишетелә. Кызган халык Арысланны җәзалап үтерергә җыена. Өеннән алып чыкканда, ул ике яшьлек кызы Рәйхананы күтәреп ала. Баласын аңардан никадәр алырга теләсәләр дә, ул кызын беркемгә дә бирми. Шулай итеп, Арыслан үлемнән кызы аркасында гына котыла. Шунда Арысланнан: «Большевик булмам, большевикларны якламам, муллаларга карышмам!..» – дип ант иттерәләр.

Икенче вакыйга. Тапаев Миңнәхмәт – империалистик сугыштан яраланып кайт-

кан солдат. Ул сугышта большевикларның халык яклы булуын аңлап, илдә тормышны гадел итеп төзергә кирәклегенә чын күңелдән ышана. Авылдашларына: «Авылда тормыш яңартып, гадел итеп төзеләчәк, бай-ярлы, изүче-изелүче бумаячак», – ди. Миңнәхмәтнең бу сүзләрен ишетеп, байлар аны да җәзаларга уйлый. Зирәк егет моны сизеп ала һәм Әмҗе елгасы буйлап, боз өстеннән Байавылга таба чыгып шыла. Тик ерак китә алмый, «кулаклар агенты» Хөсәен Сарманов атка атланып аның артыннан юырта һәм Кызылъярда Миңнәхмәтне куып җитә, аны ат артына бәйләп, Кодашка алып кайта. Аңсыз халык, байлар фәрманы белән, Миңнәхмәтне җиргә салып камчы белән кыйный һәм Арысланны ант иттергән кебек, аны да ант иттерәләр.

«ЧАБАТАЛЫ АКЛАР» СУГЫШЫ

Тол буенда Совет хакимиятен урнаштыруга Үдик авылы крәстиәннәре беренчеләрдән тотына. Герман фронтыннан большевик исемен алып кайткан утызлап фронтовик, Хәлфәт Абдалов җитәкчелегендә, коралллы дружина һәм оештыру комитеты төзи. Аңа 21 авылдан 32 делегат сайлана. Кодаш авылыннан советларга беренче депутат булып империалистик сугышта катнашып, яраланып кайткан солдат Хаяс Рамзин тәгаенләнә.

Яңа гына урнашып килгән совет кануннары авыл кешесенең хокукын кыса. Мәсәлән, элек авыл муллалары никах укып, гаилә хәле актларын метрикәгә теркәп барган. Соңрак каядыр барып язылышу мәҗбүри булгач, мондый хәл Коръәнне аяк астына салып таптау, дип уйлаганнар һәм бу тәртип халыкның коммунистларга ачуын кабарткан. Икенчедән, халыкка продразверстка дип тынгылык бирмәгәннәр. Элек хәлле кешеләр ярлыларга ашлыкны эш хакы өчен дә, бурычка да биргән. Хәрби коммунизм чорында исә продотряд вәкилләре булган икмәкне кырып-себереп алып чыгып китә башлагач, тырыш, хәлле кешеләр дә мохтаҗга әйләнгән. Өченчедән, коммунистлар, аларның аеруча әхлаксызлары, элекке ярлы-ябагай дилбегәне үз кулына алгач, авылдашларын куркытып, халыкны талау юлына баскан, кешеләрдән ришвәт алырга да шомарган. Болар барысы да авыл халкында коммунистларга каршы нәфрәт уяткан. Шул сәбәпле, һәр авылда диярлек ярлы-ябагай баш күтәргән. Татарстанда аларны «сәнәкчеләр» дип атасалар, әниләребез сөйләве буенча, бездә «чабаталы аклар» дип әйткәннәр.

Үдик волостенда совет власте урнашу муллаларның һәм байларның ачуын китерә. Алар, халык белән җитәкчелек итүнең большевиклар кулына күчүенә риза булмау сәбәпле, төрле провокация, фетнә һәм чуалышлар оештыра. Мәсәлән, 1918 елның февраль аенда Үдик волостендагы кулаклар фетнәсен алыйк. Бу фетнәгә кулаклар барлык авылда да әзерләнә, Кодаш муллалары да активлык күрсәтә. Алар крәстиәннәрне: «Без кяферләрне юк итәргә тиеш!» – дип алдап, балта, пычак, сәнәк белән коралландыра һәм, Күҗәмәт, Түбәнавыл, Каенавыл байлары оештырган төркем белән бергә, Үдик волосте йортына һөҗүм ясый.

Фетнәчеләр телефон линиясенә, юлларга каравыл куя. Юлларны ничек кенә күзәтмәсеннәр, Үдиктән берничә коммунист, чаңгы киеп, авылдан чыгып китә һәм Гамицы авылыннан Осага хәбәр итәргә өлгерә. Ә аннан хәбәр Пермьгә җиткерелә. Ике көн үткәч, Үдиккә Зайцев җитәкчелегендә Мотовилиха эшчеләреннән төзелгән отряд килеп җитә. Фетнәдә иң актив катнашучыларның дүртесен атарга хөкем итәләр.

Шулай да Кодаш байлары бу фетнәгә күпчелек халыкны тарта алмый, ярлы крәстиәннәрнең күбесе юлда качып кала. Мәсәлән, Шамгулов Бәшәр абыйның бабасы берничә иптәше белән, төнге караңгылыктан файдаланып, Байавылдан читкә качып кала. Кодаш байлары Барсаев Гәрәй, Матишев Закир, Хәмзин Әмин, Косых Миха-

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

ил, Рахмангулов Хәсән, Матишев Җәңгир, Матишев Гыймал, Матишев Хәйретдин Үдиктәге фетнәне оештыруда актив катнаша.

Бу гына җитми, Кодаш байлары, коткы таратып: «Большевиклар Майданка авылына килеп җиткән, аларга каршы барып, кырып бетерергә кирәк», – диләр һәм халыкны шунда таба куалар. Барырга теләмәүчеләрне: «Син мөселман түгел икәнсең, сине дә үтерергә кирәк», – дип куркыталар. Шулардан куркып, халык төркеме Майданкага агыла һәм анда бернәрсә дә очратмыйча, кире кайтып китә.

1918 елның июлендә Уймуж урманнарында Адутов Хикмәт җитәкчелегендәге «чабаталы аклар» төркеме хәрәкәт итә башлый. Кодашта да ул оештырган төркемнән йөздән артык кеше качып ята. Алар авыл халкының сарыгын, сыерын урлап алып китеп суялар, башка төрле дә зыян салалар.

«Чабаталы аклар» чорында Тол буе авылларында ике йөздән артык кеше җәзалап үтерелә. Ноябрь аенда фетнәчеләр Күңгер тирәсендә Колчакка барып кушыла.

КЫЗЫЛ КӨЧ

1918 елның 15-20 октябрендә Оса өязендә Кызыл Армиягә мобилизация башлана. Шул ук елны Кодаштан хезмәткә яраклы ирләр армия сафына алына, ләкин аларның кайберләре сугышчан частьтан корал, хәрби киемнәр белән кача һәм авылга керергә куркып, дезертирларга кушыла.

1919 ел башында кызыл отрядларның һөҗүме башлана. Хикмәт Адутовның төркеме Көңгергә чигенә, бирейдә Колчак армиясенә кушылып, алар яңа һөҗүмгә күчәләр. Яхшы коралланган Колчак армиясе басып алган җирләрдә чын фаҗига башлана. Беренче алынган Шермейка һәм Печмән олысларында совет властена хезмәт иткәннәрне, активистларны, якын-тирә авыллардан куып китерелгән кешеләрне атып һәм асып үтерәләр. Бер Шермейкада гына да 300ләп кеше җәзага тартыла.

1919 елның 17 февралендә Әрҗән һәм Барда басып алына, тагын, тагын атулар... Кызыллар Озын Яланга чигенә. Район биләмәсе өч айдан артык фронт зонасы булып тора. Толның, Барда елгасының уң як ярында – Колчак армиясе, сул ягында – кызыллар. Мәсәлән, Иске Чат, Кодаш авыллары, бер караганда – кызылларда, икенче карасаң – акларда. Туктаусыз, коточкыч ату тавышы... Бәрәңге базында, салам асларында качып ятулар... Язын исә җир сөрергә чыккан ирләрне басуда эшләгән җирләрендә атып үтерәләр.

Кодашлылар бу вакыйганы яхшы хәтерли. Байлар коткысы белән авылдан Хаҗи Таер улы Барсаев, Бәкинбаш-Кусавай аша Үдиккә чаңгы белән барып, акларның штабына керә. Ул кызылларның хәлен сөйләп бирә, аларны камап алу планын тапшыра. Сатлыкҗан акларны Кусавай, Бәкинбаш, Бәкин аша Кодашка алып килә. Нәтиҗәдә, аклар кызыллар отрядын тар-мар итә. Урам сугышы вакытында әсир төшкән кызылгвардиячеләрне, кыш көне күлмәк-ыштаннан гына калдырып, сарайга ябып куялар. Аларны икенче көнне нык кыйныйлар, күлмәк җиңнәре аша аркан үткәреп, тезеп бәйлиләр. 15ләп кешене Әмҗе аръягына алып китеп аталар. Мәрхүмнәрнең җәсәден авыл карты Барсаев Гата җирли.

МӘРИНӘ ТАУ

Аклар авылның гади кешеләрен дә гаепсезгә җәзалап үтерә. Марина исемле апа Кодашка шушы авыр елларда читтән күчеп килгән. Бу вакытларда аның фикер сөреше «керәле дә чыгалы», ягъни бер караганда – акларны, икенче мәртәбә кызылларны мактап сөйли торган була. Көннәрдән беркөнне акларның берничә солдаты Марина апаны,

Әмҗе аръягындагы тауга алып менеп, ерткычларча җәзалап үтерә, аның җан авазы белән кычкырган тавышы авылга кадәр ишетелә. «Чабаты аклар» аны кабер казып җирләп мәшәкатьләнмәскә дә кушкан була. Шулай да Байскин Мулланур абый, бер иптәше белән, Марина апаны һәлак булган урынында кабергә иңдерә. Шушы вакыттан бирле кодашлылар бу тауны «Мәринә тау» дип атап йөртә.

Басып алган авылларда, мәсәлән, Каенавылда, 500ләп кешене җәзалыйлар, үтерелгәннәрне сазга батыралар. Биредә Кадыйр Адутов дигән кеше үзенең ерткычлыгы белән аерылып торган. Үлемгә хөкем ителгәннәрнең ул башта кылыч белән башын чабып өзә, гәүдә җиргә ауганчы, үле гәүдәнең корсагын айкап алырга өлгерә. Әлеге ерткыч көн саен ун-унбиш кешене шулай җәзалый. Кодаштан исә 30 активист җәзалап үтерелә.

Бер кич Кодашның өч ир кешесен аклар, юк гаеп табып, сарайга кертеп бикли. Юныс Хафиз улы һәм Әхәт Хәйдәр улы Алачинов, төнлә җир казып, үзләре генә сыярлык тишектән чыгып кача. Берсе исә: «Ходай кушканны күрермен», – дип, качмый кала. Билгеле, иртәгесен аклар аны чыгарып ата. Ә скрипкачы Юныс бабай да, Әхәт абый да, тормыш кадерен белеп, озын-озак яшәде.

Гражданнар сугышы чорында Оса төрмәсенә районыбыздан 370 кеше ябыла. Һәркөн диярлек 15-20 кешене Кама буена алып чыгып, залп белән аталар, калган 300ен Пермьгә озаталар.

АЧЛЫК ФАҖИГАСЕ

1921 елда каты корылык булу сәбәпле, илгә коточкыч ачлык килә. Халык сыерларны һәм калган вак малларны суеп ашап бетерә. Авылдашыбыз Мәннәф Гариф улы Матишев сөйләвенә караганда, урамда йөргән эт-мәчеләрне дә ашаучылар була. Халык үлән, төрле суррогатлар белән туклана, ачтан үлмәс өчен, юкә кабыгын юнып, киптереп һәм тарттырып ашый. Бу елда кодашлылар ачлыктан күпләп кырылган, хәтта кайбер йортта бер генә кеше дә исән калмый үлеп бетә. Мәетләрне җирләргә кеше булмау сәбәпле, аларны кәфенсез, юмыйча гына базларга ташып күмәләр. Халык ачтан, төрле авырулардан шешенеп үлә.

1922 елда яз бик яхшы килә. Чәчелгән игеннәр ифрат уңа. Бу елдагы уңышны картлар: «Бер вакытта да, беркем дә күрмәгән иген», – дип искә ала иде. Игенне урырга кеше җитми, чөнки ул өлгерә башлау белән, авылда орлык, икмәкне чамасыз күп итеп ашап үлүчеләр саны арта гына.

***

Югарыда искә алынган вакыйгалар Кодаш авылы тарихыннан берничә тамчы гына. Алда кодашлыларны күмәк хуҗалыклар чоры, бай-мулла дип яки башка сылтаулар табып сөргенгә озатылу, атеизм шаукымы, Икенче Бөтендөнья сугышының канкойгыч вакыйгалары көтә. Әмма без алар турында язуны киләчәккә калдырабыз. Әлеге мәкаләне, укучыларыбыз ата-бабалары борынгыдан тир түккән җирнең нинди бәһа белән яулап алынганын, без яшәгән һәм хәзер инде юкка чыгарылган Совет дәүләтенең нинди кан коюлар, зур корбаннар бәрабәренә төзелгәнен, илнең байлар һәм ярлыларга бүленүе кайчан да булса зур фаҗигагә китерәчәген онытмасыннар иде, дип яздык. ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

«ДОГА ИТТЕК АЛЛАҺКА...»

Мәхмәт Хулуси Акчура

1970 нче елларда Төркиядә барлыгы сигез татар авылы исәпләнә, хәзер исә аларның саны алты. Төрек илендә гомер иткән татарлар үзара йөрешеп, аралашып торган. Шундый бер сәфәр тарихына багышлап озын бәет тә чыгарылган.

*Бу сәфәр 1972 елда Ураза бәйрәме уңаеннан оештырыла. Истанбулда яшәүче татарлар, бергә җыелып, 600 чакрым ераклыктагы Көнья шәһәре һәм Җиһанбәйле районының Бөгредәлик авылына юл тота. Бөгредәлик – дин галиме, Япониядә ислам динен таныткан хәзрәт, мәгърифәтче, милли сәясәтче **Габдерәшит Ибраһим** нигез салган татар авылы. Авыл халкы хәзер дә Габдерәшит хәзрәтне «бабай» дип йөртә.*

Бәетне Төркия татарларының көнкүрешен чагылдырган тарихи язма, дип тә әйтергә мөмкин. Мөһаҗирләрнең Төркиядә туган беренче буын балалары нинди телдә аралашкан, ничек тормыш алып барган – боларның барысы да бәеттә чагылыш тапкан. Төрек сүзләрен татарчалаштырып әйтүләре, гомумән, җирлектәге сөйләмнең телгә йогынтысы сизелә әсәрдә. Төркия татарлары үзләре әйткәнчә: «Россия татарларының теле – русчага, безнеке төрекчәгә авышкан».

*Бәетнең авторы – Османия Корыһөйүк (ягъни Корытау, төрекләр ясалма тауларга һөйүк диләр) авылында туып-үскән **Мәхмәт Хулуси Акчура** (1931-1980). Мәхмәт Хулусиның бабасы Якуп Россиядән гаиләсе белән 1890 нчы елларда китә. Башта Сүриянең Шам шәһәрендә яши, 1915 елда Төркиянең Ушак шәһәренә килеп төпләнә. Бу чакта Мәхмәтнең әтисе Йосыф Акчура (сәясәтче Йосыф Акчура түгел) бала гына була. Аларның чыгышы билгеле түгел, чөнки Якуп бабай бик аз яши. Аның вафатыннан соң, Йосыф Корыһөйүк авылында гомер итә, самавырларны төзәтүче оста буларак таныла.*

Йосыфның шигъри юллары авыл халкы телендә һаман да яши. Бу сәләте бәетләр язган улы Мәхмәткә дә күчкән...

1955 елда Мәхмәт Хулуси, берничә авылдашы белән, Курыһөйүктән Истанбулга килеп төпләнә. Бу вакытта язучы, сәясәтче Гаяз Исхакый бакыйлыкка күчкән була, соңрак Истанбулда Идел-Урал җәмгыяте дә төзелә. Мәхмәт Хулуси җәмгыятьнең иң актив әгъзасы буларак танылa. Милли хәрәкәткә аны Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң Төркиягә килгән җәмәгать эшлеклесе Кәбир Канбир җәлеп итә. Аннары Мәхмәт, 1977 елдан алып мәрхүм булганчыга кадәр, әлеге җәмгыятьне җитәкли. Ул вафат булганнан соң күп тә узмый, 1980 елның сентябрь аенда Төркиядә хәрбиләр инкыйлаб ясый. Нәтиҗәдә, төрле җәмгыятьләр, шул исәптән татарларныкы да ябыла.

Мәхмәтнең якыннары, бәет кульязмасы 1983 елдан соң югалган, дип уйлый. Быел аны кабат укырга насыйп булды. Ул югалмаган, ә Бөгредәлик авылында бәеттә телгә алынган азанчы Бәһчәт Кылычның өй чормасында сакланган икән. Бәһчәт бабай авылда яшәүче татар җәмәгать эшлеклеләре Рәхмәтулла Куртаран һәм Аднан Җиңгезне өенә дәшә. «Картая башладым. Өй түбәсендә китаплар булырга тиеш, карагыз, яраклы булганнарын алыгыз», – ди ул. Шул иске китапларны барлаганда «Мөхәммәдия» арасыннан әлеге бәетнең дә кульязмасы килеп чыга.

Менә шулай итеп, бәет Төркиядә яшәүче татарларга барып ирешә. Чит илдәге милләттәшләребезнең тормышы, үткәне белән татарстанлылар да даими кызыксынып тора. Шул хакта уйлап, әлеге бәетне, читтә яшәүче татарларның сөйләм телен үзгәртмичә, кыскартып, бары тик кайбер аңлатмалар белән генә журнал укучыларына тәкъдим итәбез.

Ният иттек Бөгредәликкә китәргә,
Китмисезме, дип, кешеләргә әйтәргә.

Китәбез, дип разый булып әйткәннәр,
Вакыт җиткәч, башладылар
яфрак кебек түгелергә.

Инде китәргә вакыт җитте,
Беркач кеше барып араба[1] тотты.

Арабаны тотып эш беткәч,
Китәчәк 35-40 кеше 30 кешегә төште.

Гарәфә көнне сәгать дүрт почыкта[2],
Араба Ватан җаддәсенә[3] килде.

Халык эчендә утырып ифтарын итте,
Арабаның шөфере бер сәгать
Әхмәт бәйне көтте.

Ниһаять, араба Харәмгә[4] чыгып җитте,
Ул якта көткәннәр суыктан өшеп бетте.

Һәм бергә уйнап-көлеп арабага мендек,
Анда фазла көтмичә хәрәкәт иттек.

Бисмиллаһ белән юлга чыктык,
Арабада уйнап-көлеп киттек.

Дөзҗәгә[5] барып ашарга төштек,
Ашап-эчкәч, яңадан юлга чыктык.

Араба юлда кычкырып китә,
Шөфер юлда төрле шакалар[6] әйтә.

Шулай итеп, Җиһанбәйлегә бардык,
Юл чатында каршыланып алдык[7].

Каршыланганыбыз өчен
бик күп шатландык,
Иртән, таң атканда, Бөгредәликкә бардык.

[1] Араба – машина, бу очракта автобус.
[2] Почык – «бучык» (ярым) дигән төрек сүзен Төркия татарлары «почык» диләр.
[3] Җаддә – зур урам, проспект.
[4] Харәм – бистә исеме.
[5] Дөзҗә – шәһәр.
[6] Шака – шаяртулар.
[7] Каршыланып алдык – каршы алдылар.

Бөгредәликкә барып төштек,
Дуслар белән күрешеп алдык.

Әзерләгән чәйләрне эчтек,
Андан инде кунак булган өйләргә киттек.

Өйгә барып, аптәс[8] алып,
Гает намазына киттек.

Дуслар белән бергәләшеп,
Гает намазын кылдык.

Хуҗа[9] көрсидә вәгазь бирә,
Сөйләгән сүзләре йөрәккә тия.

Аять-хәдис белән аңлата,
Иң ниһаять, җәмәгатьне елата.

Гаеттән чыгып зиярәткә киттек,
Зиярәттә, бергәләшеп, дога иттек.

Хуҗа Куран укыды, без Фатиха,
Аннан инде иләргә[10] кайттык.

Игә кайтып, бәйрәмләшеп,
Хазер булган бәйрәм чәен эчтек.

Һәм эчәбез, һәм сөйләнәбез,
Хасарәтне китәрәбез.

Урамга чыктык идән йөрергә,
Дус-ишләрне күрергә.

Бәйләшеп[11] йөрдек,
Бик күп хөрмәтләр күрдек.

Һәр идә дога итәләр,
Һаман шикәрне тоталар.

Шикәрне кулга аласың,
Ашый алмыйча, кесәгә саласың.

Инде бәйрәмләшү бетте,
Ахшам җыенга киттек.

Уйнап-көлеп ерладык,
Хәсрәт тулы күңелләрне юадык.

Хәйдар абзый аккардеон чаладыр,[12]
Чалганда бик могайып киткән.

Иззәт абзый скрипкә чала,
Чалганда могайып кала.

Чыда инде, чыдый белсәң,
Йөрәк маен иретеп[13] ала.

Хәйдар абзый аккардеон чала,
Иззәт абзый скрипкә тарта.

Ерлаучылар могайып ерлый,
Моңлы тавышлары йөрәккә тия.

Бәйрәмнең икенче көне,
Идел-Урал яшьләре
милли уеннар көстәрде[14].

Ахшам кич вакыт уеннар бетте,
Инде нәшәле[15] вакытлар үтте.

Бүген дә уйнап-көлеп китте,
И дуслар, сезгә туймыйча
ятарга вакыт җитте.

Иртән торып, бергәләшеп,
тауга мендек йөрергә,
Бөгредәликне югарыдан күрергә.

Андан йөреп иләргә кайттык,
Аптәс алып, җомгага киттек.

Ашап-эчеп урамга чыктык,
Бергәләшеп, бер игә киттек.

Утырып ерлаган чакта...
Бер әче хәбәр ишеттек.

Мәрфуга башын бәргән,
Һәм бәргән һәм ярган.

[8] Аптәс – тәһарәт.
[9] Хуҗа – хәзрәт.
[10] Иләргә – өйләргә.
[11] Бәйләшеп – тотынышып.
[12] Чаладыр – уйныйдыр.
[13] Иретеп – эретеп.
[14] Көстәрде – күрсәтте.
[15] Нәшәле – шатлыклы.

Шунда куллар төште түбәнгә,
Ямь калмады күңелдә.

Иртән һәркәс[16] тупланды,
Хастаның хәлен белде.

Хаста ару булгачтын,
Пашаны көтәргә калды.

Паша килеп, хастаны карады,
Хәерле хәбәрләр бирде.

Хәбәрләрне ишеткәч,
Инде китәргә калды.

Без китәбез, дигәчтен,
Ер ериннән уйнады[17].

Китәчәкләр нәрсә карасын алды,
Һәркәс әзрәк елап алды.

Халык клубның алдына китте,
Араба хастаны алып килде.

Анда килеп көтеп торды,
Анда инде кыямәт купты.

Халык дуар[18] читенә тезелде,
Җыелышып рәсемнәре чигелде[19].

Халык башлады бәхилләшергә,
Һич кемсә тоталмый күз яшен дә.

Рәхмәт әйтеп, кочаклыйлар,
Бәхил булыгыз, дип елыйлар һәм елаталар.

Халык күрешеп йөри,
Һәм күрешә, һәм елый.

Мәхмүт агай (Ураллы) еламыйм, дип,
Читтә рәсем тартып[20] йөри.

Бергәләшеп, тәкъбир әйтеп,
Мендек шулай арабага.

Исән-сау кайтырбыз, дип,
Дога иттек Аллаһка.

Юлга чыктык, араба китә,
Дусларыбыз, аерылмыйча, арттан килә.

Ярты юлга килеп җиттеләр,
Шунда туктап, азан әйттеләр.

Бәһчәт агай азан әйтә,
Шунда инде там[21] аерылып етте[22].

Йөрәк мае эреп бете,
Араба там хәрәкәт итте.

Әй, дуслар, без китәбез,
Иншаллаһ, каушырбыз, дип.

Аллаһ безне сезгә кавыштырсын,
Тиз көннәрдә күрештерсен, Амин.

Без китәбез юлларда,
Һәркәс хәзер еларга.
Һичкемсә дә тавыш юк,
Сүз таба алмый сөйләргә.

Юлда киткән чакта
Карыннар бик ачыга.
Күчтәнәч, дип куйган бәлешләрне,
Халык башлады берәр-берәр ашарга.

Шулай итеп, юлда киттек,
Харәмга килеп җиттек.
Аллаһым, сиңа чок[23] шөкер,
Исән-сау өйләргә кайттык.

Бу эшләр шулай бетсен,
Китмәгәннәр үкенсен.
Моны язган Хулуси,
Ярты төн җитте, йокларга китсен!

Кереш мәкалә белән текстны басмага
***Айзирәк Гәрәева** әзерләде.* ■

[16] Һәркәс – һәр кеше.
[17] Ериннән уйнады – җир селкенде.
[18] Дуар – дивар, стена.
[19] Рәсемнәре чигелде – фотога төшелде.
[20] Рәсем тартып – фотога төшерә.
[21] Там – тәмам.
[22] Етте – җитте.
[23] Чок – күп.

«МИНЗӘЛӘ» ГАЗЕТАСЫНА – 100 ЕЛ

ГАСЫР ДӘВАМЫНДА ҮТКӘН ЮЛ

Илдус Шаһиев

Иҗади һәм тарихи варисы бүгенге көндәге «Минзәлә» – «Мензеля» район газетасы булган «Минзәлә иле» – «Мензелинский край» газетасының беренче саны 1917 елның 23 октябрендә (иске стиль буенча – 10 октябрь) дөнья күргән. Бу бөтен илне генә түгел, дөньяны тетрәткән, ил халкын бөтенләй башка юнәлештә хәрәкәт итәргә мәҗбүр иткән Бөек Октябрь социалистик революциясе алдыннан Уфа губернасында чыга башлаган бердәнбер өяз газетасы булган.

Газетаның эпиграфы-шигаре итеп мондый сүзләр алына: *«Бары тик көрәштә генә үз хокукыңны яулый алырсың, көрәш!»*

Газета тиз арада халыкның киң массалары, аеруча крестьяннар арасында зур ихтирам казана, аның мәхәббәтен яулый. Инде 1918 елда ук тиражының 5-6 мең данәгә җитүе әнә шул хакта сөйли.

Газета төрле елларда төрле исемнәр астында чыга: «Известия», «Красные известия», «Кызыл әләм» («Красное знамя»), ә 1920 елның 17 августыннан «Игенче» («Пахарь») дип атала башлый, соңрак «Агроиндустрия комбинаты» дип үзгәртелә.

1932 ел башыннан 1962 елның маена кадәр газета «Ленин байрагы» («Знамя Ленина»), аннары «Коммунизм таңы» («Заря коммунизма») исемен йөртә.

1991 елдан башлап газета «Минзәлә» – «Мензеля» исеме белән чыга. 2008 елның 1 гыйнварында узган үзгәртеп корудан соң, редакция «ТАТМЕДИА» АҖнең «Минзәлә» ММҮ филиалы дип йөртелә башлады.

Татар телендә чыккан район газетасының икенче мөхәррире Фатих Айдашев 1918-1928 елларда эшләгән. Биредә аның истәлекләреннән өзекләр тәкъдим итәбез *(«Мәдәни җомга» газетасыннан алынды. –* **Ред.***): «Минем Минзәләгә кайтып эшли башлаган чак. Минзәлә – Уфа губернасының ярты миллионга якын халыклы өязе. Халыкның 80 проценты – татар. Аңлату эшләрен көчәйтергә кирәк. Уфада безнең делегатлар Галимҗан ага Ибраһимов белән очраша. Минзәләдә газета чыгару турында уйлашканнар. Ниһаять, 1917 елның 23 октябрендә «Минзәлә иле» исемле газета чыга башлый... Типографиядә махсус хәрефләр юк. Газетаның башын ничек кирәк алай агачтан ясап куйдык. Ул бик ямьсез булып чыга башлады. Нишләмәк кирәк, ямьсез булса да ярап тора инде.*

1918 ел башында Мәскәүдә Үзәк мөселман Комиссариаты төзелде. Аның «Чулпан» исемендә газетасы чыга башлады. Галимҗан ага – Комиссариат члены, «Чулпан»ның редакторы. «Минзәлә иле» белән «Чулпан» арасында бәйләнеш башланды. Озак та үтмәде, «Чулпан»нан, «Минзәлә иле» газетасына бүләк итеп, металлга эшләнгән бик матур клише ясатып җибәрделәр. Шулай итеп, бу газета матур баш белән чыга башлады. Шуның белән Галимҗан ага ике арада эш буенча бәйләнеш башлатырга сәбәпче булды...

1922 елның июль башлары. Мин Минзәләдә эшләүне дәвам итәм. «Минзәлә иле» газетасы «Игенче»гә әйләнеп чыга башлаган. Контрреволюция тар-мар ителгән, ләкин ачлык фаҗигасе белән зур көрәш бара. Ул вакытның хуҗалык хәлләрен тасвирлау өчен, Минзәләдән Казанга килү эпизодын күрсәтеп үтәргә мөмкин. Мин моны ул вакытта язылган һәм хәзер дә исән сакланып калган блокнот битләреннән алып язам. Матбугат эшчеләренең беренче өлкә съезды 10 нчы июльдә ачылып, 11ендә бетте. Мин бу съездда «Игенче» газетасыннан вәкил булып катнаштым. Бу съездда башыннан ахырына чаклы Галимҗан ага Ибраһимов та катнашты. Ул съездда катнашучылар белән рәсемгә дә төште. Без аның белән утырып төшкән идек. Съезд бетү белән, Минзәләгә кайтып китәргә туры килү сәбәпле, ул рәсем минем кулга кермәде. Галимҗан ага мине бик тиз таныды. «Нихәл, Әбдаш! – дип күреште, хәлләремне сорашты. – Мин «Игенче»не карап барам. Газетагыз матур чыга», – диде. Ул «Игенче» газетасының барышы һәм укучылары белән бәйләнеше, матди яклары турында бик кызыксынып сорашты. Бигрәк тә газетаның язылу бәясен икмәкләтә кую тәртибенә күчү мәсьәләсе белән кызыксынды.

«Капчык күтәреп икмәк җыярга чыгу булмасмы соң ул?» – дигән сорау да куйды. Ләкин бу хакта тулы рәвештә аңлашканнан соң, ул тәртиптә чорына карата бик нәтиҗәле булу ихтималы барын әйтте. «Бу эшне сез тирәнтен уйлап эшләгәнсез, күренә, кыю хәрәкәт итегез», – диде.

Без кыю хәрәкәт иттек. «Игенче»нең язылу бәясен икмәкләтәгә күчереп, матди кыенлыктан чыктык. Газетага язылу өчен икмәкне сельхозкооперациянең волостьтагы складларына тапшырыла торган итеп ясадык. Ул вакыт типография дә сельхозкооперация кулында иде. Газетаның чыгару расходлары өчен типография һәрбер номерына 4 пот икмәк исәбеннән хисап йөртә торган булды. Газетада эшләүчеләрнең хезмәт хакы да икмәкләтә көйләнеп китте. Икмәк ул чорда алтын валюта иде. Нәтиҗәдә, без газетадан тыш, авыл хуҗалыгын күтәрү юлында булышлык күрсәтердәй брошюралар да чыгара башладык.

«Минзәлә иле» – «Игенче» газетасының куелышында Галимҗан аганың мораль катнашы да аз булмады.

1932 елның май урталары иде. Мин, газета өчен кәгазь табып кайту нияте белән, Минзәләдән Казанга килдем. Бер көн Кремль ягыннан университетка таба кайтып ятам. Икенче Советлар йортын үтеп, кечкенә сәгать мастерское янына барып җиткәндә (Главпочтага каршырак), Галимҗан ага белән капма-каршы очрашабыз. Ул кул биреп күреште дә: «Синең бик кирәк чагың иде бит әле, Әбдаш», – диде һәм үзе белән китеп тә бардык.

Бүлмәгә керү белән, Галимҗан ага, өстендәге плащын сала-сала: «Кара, синең газетаның теле бөтенләй рәтләнгән бит, хәзер Бурнашка бәйләнергә урын да калмаган. Шушы арада гына 2-3 айлык газетаңны карап чыккан идем мин синең», – диде. Бу чорда «Игенче» газетасының телен, артык простойга көйләнгән, дип гаепләбрәк сөйләүчеләр бар иде. Бу тирәдә Галимҗан ага белән Фәтхи Бурнаш арасында бераз полемика да булып алган иде...»

1933 елның 15 июнендә газета колхозчы-ударникларның беренче район съездыннан материаллар бастыра. Аларда мондый мәгълүматлар бирелә: әгәр 1932 елда колхозлар биләмәләрендә җирләрнең 65 проценты булса, 1933 елда бу күрсәткеч 90 процентка җитә. Шуларны анализлап, газета мондый нәтиҗә ясый: «Колхозлар җиңеп чыктылар һәм җиңелмәс булдылар».

Дәһшәтле Бөек Ватан сугышы елларында район газетасының күләме кимеп, әйдәп баручы хезмәткәрләрнең күбесе яуга китсә дә, ул фронтка ярдәм итү өчен хезмәт ияләрен мобилизацияләү, тылда халык хуҗалыгы бурычларын хәл итү буенча зур эшләр башкара. «Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен!» – әлеге сугышчан шигарь район газетасының эшендә төп юнәлеш булып тора. Аның битләрендә фронтта геройларча көрәшкән якташларыбызның йөзләгән хатлары дөнья күрә, кешелекнең явыз дошманын җиңү бәрабәренә фидакарь хезмәт итүче колхозчылар һәм эшчеләр турында сөйләнә, Кызыл Армия сугышчылары өчен өс һәм аяк киемнәрен, кораллануга акча җыю барышы турында бәян ителә.

Сугыштан соңгы тыныч тормыш төзегән шартларда аерым басма булып чыккан «Ленин байрагы» һәм «Знамя Ленина» газеталары, һәр алдынгы, прогрессив яңалыкларны хуплап, яңа бишьеллыкларны киң пропагандалый, рухи торгынлык һәм искелек күренешләрен утка тотып, кимчелекләрне кыю тәнкыйтьли. Газеталар колхоз-совхоз, оешма-предприятиеләр эшчәнлеген контрольдә тота. Газетаның һәр санында яхшы уйлары, эш-гамәлләре тасвирланган хезмәт кешесе төп герой булып тора.

50 нче елларда, 60 нчы еллар башында Фәрди Вахитов, Хәйдәр Ишморатов һәм Фатих Сәлимов «Ленин байрагы» газетасының редакторлары була. Газетада язучы

1986-1991 елларда баш мөхәррир вазыйфасын башкарган Илдус Диндаров авыл хәбәрчесенә бүләк тапшыра

Рәкыйп Шәйхетдинов, Вәли Закиров, Мирсәет Хафизов, Фәрит Мөслимов, Хәрәви Басыйров, Илдус Диндаров, шагыйрь Дифгат Сираев, Сәмигулла Хәйруллин кебек тәҗрибәле журналистлар эшли, Илгизәр Әхмәтшин, Миргасыйм Сафиуллин, Лидия Варламова корректор вазыйфасын башкара.

Василий Токарев, Евгения Кукаркина, Владимир Платонов, Гөлсабира Хәкимова «Знамя Ленина» газетасы редакторлары була, Сергей Гусев, Сергей Бывальцев, Вил Хәбибуллин кебек хезмәткәрләр эшли.

Тарихи документлардан күренгәнчә, Минзәләдә беренче типография 1887 елда ачыла. И.Н.Кибардин, В.Ш.Калиник аның беренче хуҗалары була. 1917 елга кадәр Г.А.Губанов, К.И.Докукин эшли. Алдагы елларда типография хуҗаларының кем булуы хакында мәгълүматлар юк. Типография белән редактор идарә иткән, ягъни бер үк вакытта ул типография директоры вазыйфаларын да башкарган, дигән фаразлар бар. Шунысы мәгълүм: 1937-1953 елларда редактор булып эшләгән Фәрди Вахитов бер үк вакытта типографиягә дә җитәкчелек иткән.

1996 елда типография «Минзәлә» – «Мензеля» газетасы белән берләштерелә.

1962 елда авыл хуҗалыгының Минзәлә зонасы производство идарәсе булдырылу сәбәпле, район газеталары урынына Актаныш, Зәй, Минзәлә, Мөслим һәм Сарман районнары өчен «Коммунизм таңы» («Заря коммунизма») баш астында берләштерелгән газета чыга башлый һәм аңа рус телендә дубляж ясала. Моңа кадәр Актаныш район газетасында редактор булган Вагыйз Маликов берләштерелгән газетаның редакторы итеп билгеләнә. Мөслимнән Кәрим Вәлиуллин, Минзәләдән Фатих Сәлимов, Сарманнан Илгизәр Кушаев журналист булып эшли.

1962 елдан редакциянең радиокомитеты тапшыруларны бөтен районга җиткерә һәм колхоз-совхозларның җирле радиоүзәкләренә методик ярдәм күрсәтә. Традициягә тугры калып, 2005 елның декабреннән «Болгар» радиосының FM-107,3 ешлыгында трансляцияләнүче «Минзәлә дулкыннары» җирле радиостанция тапшырулары кабаттан чыга башлый.

1964 елда, зональ сәнәгать идарәләре үзгәртелгәннән соң, «Коммунизм таңы» («Заря коммунизма») газетасы Минзәлә район газетасы буларак басыла башлый һәм шул исемдә 90 нчы еллар башына кадәр чыга.

60-90 нчы елларда район газетасында Фәрит Хәбибуллин, Юныс Йосыпов, Хәмит Мөхәммәтшин, Илдус Диндаров, Миргасыйм Сафиуллин, Мөҗип Хәбриев эшли. Язучы Рәкыйп Шәйхетдинов, шагыйрь Фәйзи Хуҗин, Сергей Гусев, Хәниф Хөснуллин, Римма Зарипова – редактор урынбасарлары, Ирек Шәрипов, Илдус Шаһиев, Флера Мусина – җаваплы сәркатипләр, Сафура Сафиуллина, шагыйрь Рәшит Гәрәй, язучы Фәнзаман Сәетабатталов (Фәнзаман Баттал), Мирсәет Хафизов, Фәрит Мөслимов, Әзһәр Шакиров, Салих Мөхәммәтшин – бүлек мөдирләре һәм әдәби хезмәткәрләр, Фаяз Габдриев – фотокорреспондент. Люция Мөхәммәдиева, Венера Зарипова, Роза Муллахмәтова, Рәйхана Сәгыйтова – «Заря коммунизма» дубляж газетасының тәрҗемәчеләре һ.б.лар. Машинистка Валентина Казакова редакциядә гомере буе хезмәт куйды, шулай ук Гөлсинә Курмашева, Нурания Хәкимҗанова, Фәния Фәсхетдинова озак еллар машинистка булып эшләде, алар телне камил белүләре, игътибарлылык һәм иң мөһиме – үз вазыйфаларына намуслы караш кебек сыйфатлар белән аерылып торды.

Якташларыбыз – язучылар һәм шагыйрьләр Валентин Ерашов, Вячеслав Шугаев, Роман Солнцев (Ринат Суфиев), Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары, Марс Шабаев һәм Гөлшат Зәйнашева, шулай ук Газиз Мөхәммәтшин, Габделхәй Сабитов, Рәшит Гәрәй, Фәннур Сафин, Салисә Гәрәева, Фәнзаман Баттал, Фәйзи Хуҗин кебек танылган шәхесләрнең беренче язмалары нәкъ менә район газетасында басылган.

Каһарман-шагыйрь Муса Җәлилнең көрәштәше Абдулла Алиш та 30 нчы елларда Минзәләдә җир төзү эшләре буенча белгеч вазыйфаларын башкарган вакытта газета белән тыгыз элемтәдә торган, шагыйрь Нур Баянның шигырьләре дә район газетасында басылган.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә Минзәләдә хәрби-сәяси курсларда укыган каһарман-шагыйрь, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил истәлекләрен газетабыз бүгенге көнгә кадәр кадерләп саклый. Легендар шагыйрьнең, сугыш башлангач, шул исәптән Минзәләдә иҗат ителгән шигырьләре иң беренче булып безнең газетада басылган.

Азат Мәрдан, Фәрит Миргалимов, Флера Садретдинова, Нәкирә Лотфрахманова, Надежда Пучкованың танылган каләм әһелләре булып өлгереп җитүендә дә район газетасының роле зур.

Дөньялар үзгәрә, аның белән бергә без дә үзгәрәбез. Бүген без «Минзәлә» – «Мензеля» газетасының 100 еллыгын «ТАТМЕДИА» АҖ составында, бөтенләй яңа – мультимедиа форматында билгеләп үтәбез. 2015 ел нәтиҗәләре буенча филиаллар арасында «Газетаны сыйфатлы үзгәрткән өчен» номинациясендә «Ел лидеры» Дипломы белән бүләкләндек, «Бәллүр каләм» журналистлар премиясе лауреаты булдык. Без әле яшь, энергиябез ташып тора, без, гасыр призмасы аша, киләчәккә өмет вә оптимизм белән карыйбыз! ■

12 ЕЛЛЫК ТАТАР ҖӘНЛЕК КАЛЕНДАРЕ ЯЗМА ҺӘМ ТЕЛ ЧЫГАНАКЛАРЫНДА

Венер Әхмәтов,
аспирант

Монголиядәге рун язулы мәңгеташ янында. 2008 ел, август

Хәзерге Монголия җирләрендә сакланучы VIII нче йөз мәңгеташларына тукытылган (тукып, чүкеп язылган) рун язулы истәлекләрдә урын алган календарь атамаларының (җанвар исемнәренең), хәтта тулаем календарь системасының бүгенге татар телендә үзгәрешсез кулланыла килүе – сокландыргыч һәм тирән мәгънәле факт. Чөнки теге яисә бу белем системасының бер телдә тулысынча сакланып калуы башка шундый системаларның да әлеге телдә үзгәрешсез сакланып кала алу ихтималы булуын белдерә. Менәрчә ел дәвамында китаплы булган халкыбыз теленең борынгы төрки (552-745), ойгор (745-840), сөн (б.э. к.1200-б.э.170) язма чыганакларын һәм культурасын өйрәнүдә бердәнбер ышанычлы чыганак икәнлеге күренә.

Атаклы галимнәр Томсен белән Радлов рун язулы төрки истәлекләрне 1894 елда дешифровка ясап укый башлый. Мәкаләбезнең тикшерү үзәгендә торган «Азнакай календаре» (табылган урыны буенча шулай атыйк) кебек татар язмалары исә бу табыштан егерме ел тирәсе алданрак язылган булуга карамастан, галимнәр, ни сәбәптәндер, бүгенге көнгәчә мондый татар мирасын күрмәмешкә салыша, аны чагыштырып өйрәнми. Чит илләрдә узган төрле конференцияләрдә чыгыш ясаганда мин моңа тәмам инандым.

Татар укучысына исә үз мирасы кадерлерәк булыр дип ышанасы килә.

КАЙБЕР ТАШЪЯЗМА ҺӘМ КУЛЪЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРДӘ ЕЛ АТАМАЛАРЫ

Татар эпиграфикасында 12 еллык календарьның күпчелек җанвар атамасы да табылды (түбәндә үрнәкләре китерелә). Кулъязмаларда алар тулысынча сакланган. Байтагын галим М.И.Әхмәтҗанов табып, укып, хәзерге имлада бастырып чыгарды.

Үрнәкләр: һиҗри 1059 (милади 1649) ел – «**Сычқан** йылы» һәм «**Сығыр** йылы» [Әхҗ-2011-ТТ, 36-37], 1062 (1652) ел – «**Ләw** йылы» [Әхҗ-2011-ТТ, 36-37], [АхзКШ, 203-205], 1069 (1658-1659) ел – «**Дунгоз** йылы» [АхзОЛТЭ, 76, ӘхмәтҗановТКК, 148, Әхҗ-2011-ТТ, 88], 1086 (1675-1676) ел – «**Сычқан** йылы» [Әхҗ-2011-ТТ], 1677-1678 еллар – «**Йылқы** йылы» [АхзОЛТЭ, 76, ӘхмәтҗановТКК, 148; Әхҗ-2011-ТТ, 91], 1679-1680 еллар – «**Таwық** йылы» [Әхҗ-2011-ТТ, 93], 1688-1689 еллар – «**Йылан** йылы» [Әхҗ-2011-ТТ, 108], 1689 ел – «**Қуй** йылы» [Әхҗ-2011-ТТ, 68], 1692 ел – «**Сығыр** йылы» [Әхҗ-2011-ТТ, 114], 1736 ел – «**Таwышқан** йылы» [Әхҗ-2011-ТТ, 177, 258].

Эпиграфикада татар телле уникееллык календарь куллану беренче мәртәбә 731 елгы Күлтигән *(Күлтәгиннең дөрес язылышы шулай. –* **В.Ә.***)* каберташында табылган. Төркиләр тар-мар ителгәннән соң, 745 елда ойгор каһанлыгы оеша. Анда кулланылган календарь терминнары хәзерге татар теленә якын.

734 елгы ташта Эт елы турында мәгълүмат бар – *«**ыт** (эт. –* **В.Ә.***) **йылқа** оча барды»*; 731 елгы Култигән ташта – *«**қуй йылқа** йите йегермекә очды, тукызынчы ай йите утызка йуг иртертемез»*, *«**бечин йылқа** йитенч ай йите утызка куп алкадымыз»* [Orkun, 52]. Татар кулъязма китапларында бу терминнар барысы да комплекслы сакланган. 1876 һәм 1902 елларны белдергән «бечин йылы» «Азнакай календаре»на да урнашкан ([ИЯЛИХ-39-5165].

Җучы империясе татар ханлыкларының рәсми документларында вакыт бары тик татар календарь терминнары белән даталана. Бу күренеш металл өстенә төшерелгән эпиграфикада да, тәңкәләрдә дә кулланылган, дип фаразларга нигез бар. Татар иле җимерелү чорына кергәндә генә документ даталары гарәп телле мөселман календарь атамаларына алышына башлый. Татар кулъязмаларында, әйтик, 1680 елларда язылган «Дәфтәре Чыңгызнамә», Кадыргали Җалаиринең (1535-1607) 1602 елдагы «Җәмигъ әт-Тәwәрих», Шиһабетдин Мәрҗанинең 1897-1900 елларда басылган «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» кебек хезмәтләрендә дә татар календарь терминнарын байтак очратып була.

«Дәфтәре Чыңгызнамә» җыентыгыннан кайбер үрнәкләр: *«...ул кыргындыйн соң урыс ханы Казанны билəде, ул wақытда тарих туқоз йөз алтмыш бердә (1552) ирде Казан wилайатын кәфер урыс йәкшәнбә көн алды ирде* ***сычқан йылы****нда ирде...»* [Ivanich M. 2002, 91]. Тагын бер саллы үрнәк: *«...Әм(м)а Йәдегәр хан заманында тарих туқоз йөз илле йитедә (1550) көн тотолды. Андыйн соң Шыгалы хан, андыйн соң кәфер урыс*

(Казанны) алды... Андыйн соң тарих мең дә ун да йитедә (1609) ирде кенәз Митри яғы булды (1609), ***ташоқ йылы*** *ирде. Андыйн соң тарих мең дә йегерме түртдә ирде Җаналы яғы булды (1613),* ***ташышқан йылы*** *ирде; андыйн соң тарих мең дә илледә ирде Иркә чирүwе булды (1643),* ***йылан йылы*** *ирде; андыйн соң тарих мең дә илле өчдә ирде кенәз Михайла хан булды (1645),* ***қуй йылы*** *ирде; андыйн соң тарих мең дә алтмыш биш дә үләт булды (1655),* ***йылкы йылы*** *ирде; андыйн соң тарих меңдә йитмеш бердә ирде башқорт* ***урыс берлән яғы*** *булды (1661),* ***барыс йылы*** *ирде; андыйн соң тарих мең дә йитмеш туқозда ирде* ***эт йылы*** *ирде пәлид қазақ (урос берлә) йағы булды (1669); тарих мең дә сиксән туқозда* ***мечин йылы*** *ирде, hawада асманда бер йақты өлкән йолдоз пәйдә булды (1678. –* **В.Ә.***), көндин-көн йақтолыгы артды, тәмәм қырық көнгәчә торды, көн инеше (көнбатыш) тарафындыйн туғоп, көнчығошы тарафыга китәр ирде, төрлег төслө йолдоз ирде, күкле, яшелле, қызыллы ирде. Күргән әдәмиләр таң ғаҗәйепкә қалып, бу нә төрлөк нишандор (билгедер) тийеп әйтеп йығлашор ирделәр. Барча җиһан халқы, оло-кече, кәфер-мөэмин бу йолдозны әшекәрә (анык) күрделәр,* ***мечин (бечин) йылы*** *ирде...»* [Ivanich M. 2002, 92].

731, 734 елгы Күлтигән һәм Белгә каган истәлегенә куелган мәңгеташлар да бүгенге татар календаре терминнары белән даталанган: *«Күлтигән* ***қуй йылқа*** *йите йегермекә очды... Барақын бидәзен ташын* ***бечин йылқа*** *йите утызқа қоп алқадымыз...»*

Онгиндагы Илтырыш (Гудулу-Котло) каһанга куелган булырга тиешле ташбилгедә: *«...Көнтуғысықыңа кисрә көнбатысықыңа... Йите Ирән йағы булмыш қаңым (хан атам. –* **В.Ә.***) Баға Тәңрекин анда йорымыш, эшег көчөн бирмеш... Туқоз уғоз тәг йағы ирмеш... Тәңре қан (Котлы?)* ***луй йылқа*** *(692 ел?) йитенч ай... қаганымда(н) адырылу бардыңыз (каган үлде)». Күлечурга багышланган урында: «Күлечур йите йашына... Қарлоқ йағытоқда Тәздә сөңөшдөкдә... санча ыдып...»*

Ойгор каһанлыгы (745-840) чоры рун язуында: *«...***Барс йылқа** *Чик (халыкына. –* **В.Ә.***) тапа йорыдым, икенте ай түрт йегермекә Кәмдә (Енисей) туқыдым (сугыштым. –* **В.Ә.***), ул йыл... ул йыл көзөн элгәрү йорыдым татарығ (татарны. –* **В.Ә.***) айтдым,* ***Табышған йыл****...»*

«АЗНАКАЙ КАЛЕНДАРЕ» ТЕРМИННАРЫНЫҢ ТӨРЛЕ ТАРИХИ ЯЗУ ҺӘМ СӨЙЛӘМ ТЕЛЛӘРЕНДӘ САКЛАНЫШЫ

Үрнәк итеп китерелгән **«Азнакай календаре»** [ИЯЛИХ-39-5163] һәм шуңа охшаш башка татар кульязма календарьларында [39-2337, 39-516] терминнар орфографиясе бер үк, кайбер кечкенә булса да әһәмиятле аермалыклар да очрый: әйтик, *«бечин»*, *«печин»*, *«мечин»* һ.б.

«Азнакай календаре» транслитерациясе: «Сычқан йылы: 1876, 1888, 1900; Сығыр йылы: 1877, 1889, 1901; Барыс йылы: 1878, 1890, 1902; Таwышқан йылы: 1879, 1891; Ләw йылы: 1880, 1892; Йылан йылы: 1881, 1893; Йылқы йылы: 1882, 1894; Қуй йылы: 1883, 1895; Печин йылы: 1884, 1896; Таwық йылы: 1885, 1897; Эт йылы: 1886, 1898; Дуңыз йылы: 1887, 1899.»

Кәгазьдәге татар язуында: 1 нче: Сычқан йылы; 2 нче: Сығыр йылы; 3 нче: Барыс йылы; 4 нче: Таwышқан йылы; 5 нче: Ләw йылы, Лү йылы; 6 нчы: Йылан йылы; 7 нче: Йылқы йылы; 8 нче: Қуй йылы; 9 нчы: Бечин йылы, Печин йылы, Мечин йылы; 10 нчы: Таwоқ йылы; 11 нче: Эт йылы; 12 нче: Дуңоз йылы;

Таштагы татар (эпиграфик) язуыда: 1 нче: Сычқан йылы; 2 нче: Сығыр йылы; 3 нче: --- йылы; 4 нче: Таwышқан йылы; 5 нче: Ләw йылы; 6 нчы: Йылан йылы; 7 нче: Йылқы йылы; 8 нче: Қуй йылы; 9 нчы: --- йылы; 10 нчы: Таwық йылы; 11 нче: --- йылы; 12 нче: Дунгоз йылы;



«Азнакай календаре». XIX йөз уртасы. Күчермәнең аскы уң ягында – В.Әхмәтов искәрмәләре

Таштагы төрки (эпиграфик) рун[1] язуында (552-745): 1 нче: (?Сычқан, ?Күсгө) йылы; 2 нче: (?Ингәк, ?Боқа) йылы; 3 нче: Барыс йылы; 4 нче: Табышған йылы; 5 нче: Ләw йылы, Лүй йылы; 6 нчы: Йылан йылы; 7 нче: Йылқы йыл, (?Ат, ?Йон(а)т) йылы; 8 нче: Қуни йылы; 9 нчы: Бечин йылы, Печин йылы; 10 нчы: (?Тақығо) йылы; 11 нче: Ыт йылы; 12 нче: Лағзын йылы, Лақзын йылы, (?Туңоз);

Таштагы ойғор (эпиграфик) рун язуында (745-840): 1 нче: Күсгө йылы; 2 нче: (?Ингәк, ?Боқа) йылы; 3 нче: Барыс йылы; 4 нче: Табышған йылы; 5 нче: (?Ләw) йылы, Оло йылы; 6 нчы: Йылан йылы; 7 нче: Йылқы йыл, (?Ат, ?Йонт) йылы; 8 нче: Қуни йылы; 9 нчы: Бечин йылы; 10 нчы: Тақығо йылы; 11 нче: Ыт йылы; 12 нче: Лағзын йылы (?Туңоз);

Бируни[2] (973-1048) 1: 1 нче: Сычқан йылы; 2 нче: Од йылы; 3 нче: Барыс йылы; 4 нче: Тафышхан йылы; 5 нче: Ләw йылы, (Лү) йылы; 6 нчы: Йылан йылы; 7 нче: Йонт йылы; 8 нче: Қуй йылы; 9 нчы: Бечин йылы; 10 нчы: Тағоқ йылы; 11 нче: Эт йылы; 12 нче: Туңоз йылы; (тагы бер кулъязма чыганакта ВМ 10-11 берлә DS 234: 4 нче: tawышхан, 10 нчы: тақоқ);

Кашгарлы Мәхмүд[3] (1074): 1 нче: Сычған йылы [МК 1, 345]; 2 нче: Од йылы; 3

[1] Җәя эчендәге терминнар рун язулы истәлекләрдә булырга тиеш дип фараз кылып язылган. Рун язуына карамаган тарихи язу һәм сөйләм телләрендә календарь термины булмаган синоним атамалар бирелә.
[2] Урта гасыр төрки галиме Әбү Рәйхан Мөхәммәд ибн Әхмәд Әл-Бируни (973-1048).
[3] Урта гасыр төрки галиме Мәхмүд ибн Әл-Хөсәен ибн Мөхәммәд Әл-Кашгарый (1074 елгы сүзлек авторы).

нче:Барыс йылы; 4 нче: Таwышған йылы; 5 нче: нәк йылы, Ләw йылы (Лү); 6 нчы: Йылан йылы; 7 нче: Йонд йылы; 8 нче: Қуй йылы; 9 нчы: Бечин йылы (?Печин йылы); 10 нчы: Тақаға йылы; 11 нче: Ыт йылы; 12 нче: Туңоз йылы [МК 1, 346];

Брахми язудагы татар (1277/1278 елгы): 1 нче: сычқан йылы (ойгорныкы булса, Күскө аталыр иде. Язуда «Сычкам»); 2 нче: От йылы; 3 нче: Барыс йылы; 4 нче: Т(а) wышқан йылы (Язуда «Тwышкам»); 5 нче: Лү йылы; 6 нчы: Й(ы)лан йылы (Язуда «Йлам»); 7 нче: Йонт йылы; 8 нче: Қуйн йылы; 9 нчы: П(е)чин йылы (Бичен кебек булса И беренче иҗектә язылыр иде, димәк татар транскрипциясы миндә дөрес. Язуда «Пчем»); 10 нчы: Т(а)қыға йылы; 11 нче: Эт йылы; 12 нче: Т(у)ңоз йылы;

Илхан Ираны (15 йөз): 1 нче: Күскө йылы; 2 нче: От йылы; 3 нче: Барыс йылы; 4 нче: Таwышқан йылы; 5 нче: Ләw йылы; 6 нчы: Йылан йылы; 7 нче: Йонд йылы; 8 нче: Қуй йылы; 9 нчы: Бежин йылы; 10 нчы: Дақоқ йылы; 11 нче: Эт йылы; 12 нче: Туңоз йылы;

Унгот (ак татар) ташка язуда 12 йөз: 1 нче: Күсгө йылы; 2 нче: --- йылы; 3 нче: --- йылы; 4 нче: Таwышқан йылы; 5 нче: Лүw йылы; 6 нчы: --- йылы; 7 нче: --- йылы; 8 нче: --- йылы; 9 нчы: Бечин йылы; 10 нчы: Тақығу йылы; 11 нче: --- йылы; 12 нче: (?Туңоз) йылы;

Чагатай несториан христианнары (12-14 йөз): 1 нче: Сычқан йылы; 2 нче: Од йылы; 3 нче: Барыс йылы; 4 нче: Табышқан йылы; 5 нче: Ләw йылы; 6 нчы: Йылан йылы; 7 нче: Йонт йылы; 8 нче: Қуй йылы; 9 нчы: Бечин йылы; 10 нчы: Тақоқо йылы; 11 нче: Эт йылы; 12 нче: Туңғоз йылы;

Мисыр татары (14 йөз): 1 нче: Сычқан йылы; 2 нче: Сығыр йылы; 3 нче: Парс йылы, қаплан йылы (барыс), ыслан йылы, (а)слан; 4 нче: Таwышған йылы; 5 нче: Балыг йылы; 6 нчы: Йылан йылы; 7 нче: Ат йылы; 8 нче: Қуйын йылы; 9 нчы: Бечин йылы; 10 нчы: Тақоқ йылы; 11 нче: Эт йылы; 12 нче: Дунгоз йылы;

Абулгазы (Үргәнеч татары) (1640 ел): 1 нче: Сычқан йылы; 2 нче: Сығыр йылы; 3 нче: Барыс йылы; 4 нче: Қуйан йылы; 5 нче: Ләw йылы, Балыг йылы; 6 нчы: Йылан йылы; 7 нче: Йылқы йылы, Ат йылы; 8 нче: Қуй йылы; 9 нчы: Бечин йылы; 10 нчы: Таwоқ йылы; 11 нче: Эт йылы; 12 нче: Туңоз йылы;

Идел-Урал татары (20 йөз): 1 нче: Тычқан йылы, Чычқан йылы; 2 нче: Сыйыр йылы (Инә); 3 нче: Барыс йылы; 4 нче: Таwышқан йылы (Қуйан йылы); 5 нче: Ләw йылы (аждаһа), Балық йылы; 6 нчы: Йылан йылы; 7 нче: Йылқы йылы, Ат йылы; 8 нче: Қуй йылы, сарық йылы; 9 нчы: Бечин йылы, мечин йылы, печин йылы, (маймул); 10 нчы: Таwоқ йылы; 11 нче: Эт йылы; 12 нче: Туңоз йылы, чучқа йылы;

Болгария кырым татары (20 йөз): 1 нче: Шышқан йылы, Шышан йылы; 2 нче: Сығыр йылы, сыйыр йылы; 3 нче: Барыс йылы; 4 нче: Таwшан йылы, қойан йылы; 5 нче: Улуw йылы, балық йылы, бақа йылы; 6 нчы: Җылан йылы; 7 нче: Җылқы йылы; 8 нче: Қой йылы; 9 нчы: Мешен йылы; 10 нчы: Таwоқ йылы; 11 нче: Ийт йылы; 12 нче: Доныс(з) йылы, домус(з) йылы;

Казах (20 йөз): 1 нче: Тышқан жылы; 2 нче: Сыйыр жылы; 3 нче: Барыс жылы; 4 нче: Қойан жылы; 5 нче: Олу жылы (аждаһа); 6 нчы: Жылан жылы; 7 нче: Жылқы жылы (Ат); 8 нче: Қой жылы; 9 нчы: Мйешен жылы (маймул); 10 нчы: Таwық жылы; 11 нче: Эйт жылы; 12 нче: Доңуз жылы (шошқа);

Ойғор (20 йөз): 1 нче: Тычқан йылы; 2 нче: Кәлә йылы; 3 нче: Барс йылы; 4 нче: Тошқан йылы; 5 нче: Олу йылы; 6 нчы: Илан йылы; 7 нче: Ат йылы; 8 нче: Қой йылы; 9 нчы: Мичин йылы, мәймүн йылы; 10 нчы: Тоқа йылы; 11 нче: Эт йылы; 12 нче: Дөңүз йылы;

Таранчы кәгазь язуында (19 йөз): 1 нче: Сычқан йылы; 2 нче: Уй йылы (кәлә); 3 нче: Барс йылы; 4 нче: Таwышқан йылы; 5 нче: Балық йылы; 6 нчы: Илан йылы; 7

12 еллык татар календаре. 1935-2030 еллар

нче: Ат йылы; 8 нче: Қой йылы; 9 нчы: Мәймүн йылы; 10 нчы: Таwоқ йылы; 11 нче: Эт йылы; 12 нче: Тоңуз йылы;

Төркия төркисе (20 йөз): 1 нче: Фаре йылы; 2 нче: Сыыр йылы (инек), өкүз йылы; 3 нче: Парс йылы; 4 нче: Тавшан йылы; 5 нче: тимсах йылы (крокодил), Эждер (ләү) йылы; 6 нчы: Илан йылы; 7 нче: Ат йылы; 8 нче: Қойун йылы; 9 нчы: Маймун йылы; 10 нчы: Тавуқ йылы; 11 нче: Көпек йылы; 12 нче: Донуз, домуз йылы;

Болгария, Дунай болгарлары (866 ел): 1 нче: Сомор (йылы); 2 нче: Шегор (йылы), Сигор (йылы); 3 нче: Вер (йылы); 4 нче: Довшон (йылы); 5 нче: Дилом (йылы); 6 нчы: Дилан (йылы); 7 нче: Морен (йылы); 8 нче: Текучитем (йылы); 9 нчы: Кучин (йылы); 10 нчы: Тох (йылы); 11 нче: Этх (йылы); 12 нче: Доқс (йылы);

Берничә мең ел кичкән татар 12 еллык календарендагы еллар (җанварлар) атамасының барлык төрки халыклар өчен охшаш булуына карамастан, ул атамаларның VIII гасырдан бирле билгеле булып, бары тик татар халкында гына бүгенге көнгә тикле үзгәрешсез диярлек саклануы ачыкланды. Бу борынгы истәлекләрне өйрәнүдә татар теле нең һәм татар культурасының рун язуларына ачкыч булуын дәлилләде.

Татар календаре буенча киләсе Яңа – Сары Эт елы (2018 нче ел февраль ае 16 нчы көндә башлана һәм 2019 нчы февраль ае 4 нче көндә бетә) котлы булсын! ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

ИЛ АГАСЫ

Нәсим Акмал

Узган 2017 ел ахырында Минзәлә районының Татар Мөшегесе авылында истәлекле вакыйга булды. Халык шушы төбәкнең мөхтәрәм аксакалы, сугыш һәм хезмәт ветераны, Ленин ордены кавалеры Нәҗип ага Галимәрдәновның 90 яшьлек юбилеен билгеләп үтте.

Сүз үз заманында даны бөтен тирә-юньгә яңгыраган «Марс» колхозы белән чирек гасырга якын җитәкчелек иткән, шушы җирлектә матди һәм рухи мирас калдырырлык зур эшләр башкарган шәхес турында бара.

Аның бай тәҗрибәсе әле бүген дә актуаль һәм ул бүгенге шартларда да тормышта кулланма булырлык әһәмияткә ия. Шуңа да аксакалның өеннән авылдашлары да, авыл һәм район җитәкчеләре дә өзелми.

Авыл мәктәбендә уздырылган бу бәйрәм үзенең мәгънәсе, эчтәлеге һәм тирәнлеге белән республика күләмендәге чараны хәтерләтте.

Кичә тантаналы музыка астында Татарстан Президенты **Рөстәм Миңнехановның** Нәҗип Галимәрдән улына юллаган «Рәхмәт сүзе»н җиткерүдән башланып китте. Шулай ук Татарстанның беренче Президенты **Минтимер Шәймиевнең** котлау телеграм-

Минзәлә районының Татар Мөшегесе авылы күренеше

Сугыш беткәч – солдат хезмәтеннән кайткач. 1950 ел

Колхоз рәисе булып эшли башлаган еллардан бер истәлек. 1957 ел

масы да яңгырады: *«Хөрмәтле Нәҗип ага! Республикабызның авыл хуҗалыгы үсешендә Сезнең өлешегез бәяләп бетергесез зур, бүгенге уңышларыбызга гаять авыр елларда Сез һәм Сезнең кордашларыгыз салган ныклы нигездә ирешелә. Сез кылган игелекле эшләр, Бөек Ватан сугышындагы батырлыкларыгыз яшь буын өчен үрнәк булып тора... Сез һәрвакыт якташларыгыз мәнфәгатен кайгырттыгыз. Кешеләрне ярата торган зирәк җитәкче булдыгыз.*

Күп еллар буена бергә бер-беребезне аңлап эшләдек. Моның өчен зур рәхмәтемне кабул итегез».

ТР Премьер-министры урынбасары-авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры **Марат Әхмәтов** Казаннан видеоэфир аша Татар Мөшегесе мәктәбе белән турыдан-туры элемтәгә керде: *«Хөрмәтле Нәҗип ага! Сез безнең илебез язмышының иң авыр, хәлиткеч чоры вәкиле. Сугыш еллары да, аннан соң илне торгызу да Сезнең буын җилкәсендә булды. Халык бөтен барлыгы белән җитәкчегә бирелгән, ышанган шартларда, нинди генә авырлыклар аша узарга туры килсә дә, Сез, йөзләгән кешеләрнең язмышын үз өстегезгә алып, намуслы хезмәтегез белән аларның ышанычын акладыгыз. Инде менә күп еллар узгач та, халык Сез җитәкчелек иткән чорларны сагынып искә алып, үзенең аксакал җитәкчесен зурлап яши икән, моннан да мәгънәлерәк тормыш булырга мөмкинме?»* – диде ул.

«Сетевая компания» ААҖ генераль директоры **Илшат Фәрдиев**нең юбилярга юллаган котлау телеграммасы да рәхмәт хисләре белән сугарылган иде. Анда мондый юллар бар: *«Хезмәт кешесе – хөрмәт кешесе, диләр. Сездәй кешеләрне ил байлыгына тиңлиләр. Күңелегездә тормыш яме, йөрәгегездә дәрман уты сүнмәсен. Киләчәктә дә балаларыгызның, оныкларыгызның бәхетен күреп, кадер-хөрмәттә тормыш итәргә язсын!»*

Минзәлә районы җитәкчеләрдән һәрвакыт уңды. Нәҗип агага исә үз гомерендә аларның бик күпләре белән бергә эшләргә туры килде. Бүген Минзәлә муниципаль район хакимияте башлыгы **Айдар Сәлахов** Нәҗип Галимәрдәновның иң авыр заман-

Җиңүнең утыз еллыгына багышланган митинг. Чыгыш ясаучы – Нәҗип Галимәрдәнов. 1975 ел

нарда район үсешенә керткән өлеше, аның әле бүген дә яңа буын җитәкчеләр өчен бер үрнәк булуы турында сөйләде.

Татарстан кулланучылар оешмасы берлеге рәисе **Мәхмүт Фәттахов**, юбилярны котлап, аңа «Россия кулланучылар кооперациясе үсешенә керткән хезмәтләре өчен» орденын тапшырды һәм үзенең хезмәт юлында Нәҗип аганы үрнәк итеп яшәвен әйтте. Гомумән, Фәттаховлар династиясе вәкилләре, республиканың кайсы гына тармагында хезмәт куеп, нинди генә җаваплы эшләрдә эшләсәләр дә, үзләре тәмамлаган Татар Мөшегесе мәктәбенә, аларны укыткан укытучыларга, шул җирлектә бөтен көчен биреп эшләгән җитәкчегә – бүгенге юбилярыбызга һәрвакыт рәхмәтле булып, ярдәм итеп яши.

Хәтердә әле, 2007 елда Нәҗип аганың 80 яшьлек кичәсе Татар Мөшегесе мәдәният

Н.Галимәрдәнов кошчылык фермасы алдынгысы, Октябрь революциясе ордены кавалеры Мария Камаевага бүләк тапшыра. 1967 ел



Нәҗип Галимәрдәнов хезмәттәшләре белән: беренче рәттә уңда – Рафаяз Каюмов; икенче рәттә сулдан уңга – Әзһәр Билалов, Әбүрәй Сруров. 1963 ел

йортында зурлап билгеләп үтелгән иде. Шул көннән соң бер дистә ел үтеп тә киткән. Чакырылачак кунаклар исемлеген барлый башлагач, гаҗәпкә кала ул: шушы ун ел эчендә авылдан һәм туган-тумача, дус-иш арасыннан 50 кеше бакыйлыкка күчкән. *«Беркем дә мәңгелек түгел, исән вакытта бер-беребезнең кадерен белик»*, – дип, кичәне арабыздан киткәннәрнең якты рухын искә алудан башларга тәкъдим итте Нәҗип ага.

Юбилейны да ул «очрашу» дип атады. «Бер күрешү – үзе бер гомер» дигән исем астында үзенең якыннарын, туганнарын, хезмәттәшләрен бергә җыеп, аларга күңелендәге рәхмәт сүзләрен җиткерде. Экранда юбиляр турында күрсәтелгән фильм да:

«Ходайга мин рәхмәтлемен,
Гомерләр биргән өчен;
Язмышларны сезнең белән
Бергә бәйләгән өчен», – дигән шигъри юллар белән төгәлләнде...

Инде шушы күркәм очрашуның түр башында республика җитәкчеләренең котлавын, авылдашларының ихлас сүзләрен кабул итеп утыручы Нәҗип аганың үзен, аның тормыш юлын, бу дөньяда кылган гамәлләрен игътибар үзәгенә алыйк.

Ул 1927 елның 8 октябрендә Татар Мөшегесе авылында дөньяга килә. Җидееллык мәктәп тәмамлаганнан соң, гади колхозчы булып эшли башлый, яшүсмер килеш сугышка китә, илне саклый, Җиңү яулап туган авылына кайта. Аннан соң, башаягы белән шушы авыл тормышына, халык, кешеләр язмышына бирелә. Күп тә үтми, авылдашлары аны рәис итеп сайлый.

Күңелдә матур уйлар, мәхәббәт, наз көткән яшь чаклар! Татар Мөшегесе мәктәбендә директор булып эшләүче Клавдия Смирнова белән әнә шул мәхәббәт кавыштыра аларны. Ул чагында әле Татар Мөшегесе Мөслим районы составында була. Территориаль бүленешләр бер-бер артлы үзгәреп торган заманнарда авыл төрле елларда Калинин, Матвеевка, Сарман, Мөслим, Актаныш, Минзәлә районнарына караган.

Нәҗип абый җитәкләгән «Марс» хуҗалыгына кергән авылларда җиде төрле милләт вәкилләре бер тату гаилә булып яши. Гөрләп узган Сабан туйларында элек-электән үк татар, рус, мари, керәшен җырлары яңгырап торган. Төрле халык вәкилләрен



Нәҗип Галимәрдәнов хатыны Клавдия Смирнова белән. 1963 ел

берләштергән хуҗалык җитәкчесе булып эшләү, һәр милләтнең, һәр гаиләнең күңелен, фикерен белеп, аларны уртак матур хезмәткә туплау һәм шундый матур нәтиҗәләр белән эшли белү, әлбәттә, җиңел бирелмәгәндер.

Гадәттә, район чикләрендә урнашкан авылларга игътибар җитеп бетми, аларның юллары да, социаль корылмалары да әлле-мәлле генә була. Н.Галимәрдәнов хуҗалыкның нәкъ әнә шундый чагында җитәкчелеккә керешә. Ә ул инде ярты юлда туктала торган егет түгел: үзе дә тынгы белми, башкаларны да тик тотмый, үзсүзлелеге дә җитәрлек. Нәҗип иң әүвәл Мөслим МТСы белән эшлекле, хәтта дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыра. Чөнки ул елларда бөтен техника, алдынгы технологияләр әнә шунда. МТС җитәкчесе Минтимер Шәймиев белән бик тиз уртак тел таба ул. Булачак Президентның – ул чакта әле Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап кайтып, хезмәт юлын башлап кына җибәргән Минтимер атлы егетнең Татар Мөшегесе басуларында колхозчыларны техникага өйрәтеп, трактор артында үзе сабанчы булып йөргән чакларын да

2011 елда Татар Мөшегесе урта мәктәбенең 80 еллык юбилее билгеләп үтелде. Мәктәпкә гомерен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган данлыклы мөгаллимә Клавдия Смирнова исеме бирелде

Юллар, юллар, инде ничә еллар...
Нәҗип Галимәрдәнов шоферы Ясүр Сәлахов белән. 1967 һәм 2014 еллар

хәтерлиләр биредә. Шуңа күрә дә, Минтимер Шәймиев Минзәлә МТСына күчкәч, мөшегелеләр тиз арада Минзәлә районына кушылу ягын карыйлар.

Колхоз ныгыганнан-ныгый бара. Амбарлар, ашлык киптерү җайланмасы, автотрактор паркы, гаражлар, терлекчелек фермалары, пилорама төзелә.

Нәҗип Галимәрдәнов, эшли башлаган елларында ук, дизель двигателе белән эшләүче ток генераторы куеп, авылга электр керттерә. Озак та үтми, гомер бакый юлсызлыктан интеккән бу якларда яхшы юллар сузыла, суүткәргеч уздырыла. «Марс» колхозының даны районга, бөтен республикага тарала. 1965-1970 елларда хуҗалык, төрле күргәзмәләрдә катнашып, ул заманның иң мәртәбәле бүләкләре – ВДНХ дипломы, Партия ҮК, профсоюзларның һәм ВЛКСМ ҮКның Кызыл Байраклары белән бүләкләнә. Җитмешенче елларда биредә, Мелиорация министрлыгы ярдәме белән, зур буа төзелә. Моңа кадәр тал-тирәкләр арасыннан мыштым гына агып яткан Чәтки елгасы нәни диңгезгә әверелә. Аның әйләнәсендә наратлык үсеп чыга. Авыл таулары, елгалары белән агачлыкка күмелә. Кешеләр, бу якларның табигатенә сокланып, шәһәрләрдән кайтып ял итә, тәннәренә сихәт алып китә. Яшел парк Сабан туйлары үткәрү, кешеләрнең ял итү урынына әверелә. Аннары инде Нәҗип абый, авылдашлары белән бергәләп, урамнарга да нарат агачы утыртуны оештыра. Нәтиҗәдә, Татар Мөшегесе урман эчендәге авылга охшап кала. Әнә шул агачлыкларның берсе бүген халык телендә «Нәҗип паркы» дигән исем белән телгә кереп бара.

Авыл тернәкләнә, киң күләмдә төзелеш эшләре башлана: административ бина, клуб, китапханә, кибет, медпункт, яңа йортлар салына, авылда ике катлы яңа мәктәп үсеп чыга.

Нәҗип ага лаеклы ялга чыккач та тик ятмады. Хәер, тик ятса, ул Нәҗип Галимәрдәнов булмас та иде. Ул әле озак еллар буе Сугару һәм су чистарту системалары Тукай идарәсенең Ык аръягы участогында эшләде, аннары авыл ветераннары советы рәисе хезмәтен башкарды.

Шөкер, дип әйтик, Нәҗип абыйлар салган нигез тагын да ныгый бара: газ кертелгән, соңгы ун елда авылны су белән тәэмин итү системасы тулысынча алыштырылган, яңа мәдәният йорты файдалануга тапшырылган. Республика программасы ярдәмендә бик күп яшь гаилә, яңа йортлар салып, тормышларын туган нигезләре белән бәйләгән. Яңа йортларны киң-иркен итеп, шәһәр рәхәтлекләре белән салалар биредә. Шулай ук авылга асфальт юл да уздырылган. Халык күпләп яшелчә, җиләк-җимеш, чәчәк үстерә, җитештергән продукциясен ярминкәгә алып чыга. Кыскасы, яңа заманга җайлашып көн күрергә күнегеп килә.

Җиңүнең 60 еллыгын бәйрәм иткән көн. Казан. 2005 ел

Оныклар белән. 2006 ел

Кызы Рима һәрвакыт янәшәдә. 2017 ел

Соңгы елларда белем бирү системасында да зур үзгәрешләр булган. Мәктәп бинасы төзекләндерелгән, аның матди-техник базасы ныгытылган. Үз вакытында башкарылган бу эшләр Татар Мөшегесе мәктәбенең районда урта белем бирүче база мәктәбе буларак сакланып калуына зур этәргеч ясый. Әлеге эшләрне тормышка ашыруда ярдәм иткәне өчен Илшат Фәрдиевкә авыл халкы тирән рәхмәтен белдереп яши.

Ә инде 2016 елда Республикада игълан ителгән дәүләт программасы буенча уздырылган капиталь ремонт мәктәпнең мөмкинлекләрен тагын да киңәйтте. Бүген биредә хоккей тартмасы, спорт мәйданчыгы, заман таләпләренә туры китереп төзелгән спорт залы – барысы да балаларның сәламәтлеген ныгытуга юнәлтелгән.

2011 елда мәктәпнең 80 еллык юбилеен билгеләп үткәннәр. Мәктәпкә гомерен бала-

Минзәлә районы җитәкчеләрдән һәрвакыт уңды. Районның бүгенге башлыгы Айдар Сәлахов Нәҗип аганың киңәшләрен игътибар белән тыңлый. 2017 ел

ларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган данлыклы мөгаллимә Клавдия Смирнова исеме бирелгән. Инде фани дөньядан китүенә егерме елдан артык вакыт узса да, халык аны һаман да юксынып, аның тормыш юлын үрнәк итеп искә алып яши.

...Нәҗип Галимәрдәновның юбилее тормыш иптәше исемендәге шушы күркәм мәктәптә үткәрелде – монысы да ниндидер бер символик мәгънәгә ия. Һәм аксакалның авылдашлары, кордашлары, хезмәттәшләре, күрше-күлән, балалары, оныклары җыелган бу мәҗлес хезмәт кешесен, фидакарьлекне олылау тантанасы булды.

Шушы очрашудан соң, миңа Нәҗип аганың якыннары белән сөйләшеп утырырга туры килде. Алар әти-әнисен шулай олылаган, хөрмәт иткән, аларның хезмәтен югары бәяләгән авылдашларына, район һәм республика җитәкчеләренә чиксез рәхмәтле булуларын белдерделәр. ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

ТӘҢРЕ, ДИНГИР ВӘ УМАЙ...

Айрат Галимҗанов*

Борынгыдан килгән ышанулар

*Төркиләрнең **Олуг Аллаһ – Күк**, ягъни **Тәңре**не олылаулары элек-электән сакланып килеп, хәзерге заман төрки халыкларына атаклы һуннар чоры аша килеп җиткән.*

*Әйтик, бүгенге карачайлардагы **Тәйри** алласы үз вакытында ауропалыларны яулары белән борчып-куркытып торган кыпчаклар өчен дә – шул ук Тәңре!*

Аны Тува халкы **Дәәр** дип йөрткән, шумерлар – **Дингир**, саха-якутлар – **Тангара**, полинезиялеләр – **Тангароа**, таитилеләр – **Таароа**, азәрбайҗаннар – **Танры** яисә **Таңры**, төрекләр – **Танры**, нугайлар – **Тәңри**, казан татарлары һәм башкортлар – **Тәңре**, караимнәр – **Тары**, алтайлылар – **Тэҥэрэ**, чувашлар – **Тура** (Дуры), хакаслар – **Тенгири**, үзбәкләр – **Тангри**, төрекмәннәр **Таңры** дип атаган.

---

*Айрат Галимҗанов Казанда туып (1962) үскән. Чувашстан Язучылар берлеге әгъзасы. Шагыйрь, тәрҗемәче.Төрки дөнья турындагы мәкаләләре Татарстан, Мари Иле, Чувашстан, Алания-Осетиядәге газета-журналларда дөнья күргән.

Күпчелек төрки кабиләләрдә Олуг Алла исеме Күк дигән сүз белән янәшә йөртелгән. Хәзерге заман Алтай шагыйре **Борис Укачин**ның шундый шигъри юллары бар:

Тәңредә тик ялгыз ал Ай,
Дөньяда тик ялгыз Алтай!

Төрки пантеонының балкарлар һәм карачайлылар **«Уллу Тейри» (Олы Тәңре)** дип атап йөрткән Олуг Алласы бөтен яшәү барышын, хәрәкәтен әйдәп барган, бәхет иңдергән, бәла-каза, кыенлыклар һәм җәзалар китергән: һава торышына, яшен, күк күкрәве, җилянгырга хуҗа булган; мул уңыш, мал-туар үрчеме һәм башкаларны тәэмин иткән.

Дайчин-Тәңре (Тибет, Далха) ук-җәя белән коралланган, сул кулында – байрак.
Һейдельберг, картиналар галереясы

Балкар белән карачайлыларның туй алкышлары (теләкләре) Тейрине искә алмыйча үтмәгән:

Тейри булышсын,
Тейри ялварсын,
Уң (уңай) атлы
итсен,
Уң яратсын,
Игелекләр бирсен,
Яманлыкны кире илтсен.

Берничә йөз еллар элек кыпчаклар: «Тәңри көчледер», – дия торган булган.

Бу гыйбарә **«Кодекс куманикус»** сүзлегендә дә күрсәтелгән. Казан татарларының ата-бабалары, Олуг Тәңрегә тагын 16 тәңре буйсынган, дип санаган.

Төркиләр Күккә атап ат, тәкә һәм башка терлекләрне корбан итеп чалган. Ошбу гамәл кымыз, әйрән, сөт, ит шулпасы эчү белән бергә башкарылган.

Төрки шаманнардан тувалы, алтайлы, качин, белтирләр XX гасыр башында да Күккә махсус догалар кылган. Бу борынгыдан килгән Тәңре гореф-гадәтен 90нчы елларда, **Рамай Юлдашев**, **Дамир Шәйхетдинов** һәм башкалар башлангычында, Идел буе төркиләре яңартты. Мондый бәйрәм Иске Казан төбәгендә хакасларның **«Тигир тай»** бәйрәме кебек үк үткәрелә.

Мисал өчен, тувалылар язның беренче яшенле көнендә Кояшка һәм Дәэрга күмәк рәвештә дога кыла.

Беренче күк күкрәгәндә хакаслар, юрталары тирәли йөренә-йөренә, Күкне һәм Җирне әйрән белән туендыра-туендыра: «Иске ел китсен! Яңа ел килсен!» – дип кабатлый.

Күктә салават күпере пәйда булуны төркиләр **«Тәңре эзәре»** («Тәңре билбавы»), **«Күк кушагы»**, **«Тәңре Кылычы»** дип, ә хакаслар **«Тигир Куры»**, алтайлылар **«Тәңәрә Куры»** дип атаган. Балкарлар белән карачайлылар язгы беренче салават күпере күренгән вакытта гыйбадәт кылган һәм муллык, иминлек теләгән. Изге тауларны борынгы төркиләрчә хөрмәтләү – олылау шорларга да, алтайлылар, тувалылар һәм хакасларга да хас булган...

Тувалылар, тауларның үз рухлары – хуҗалары «даг ээзи» бар, дип исәпләгән, моны хакаслар **«тах ээзи»** дип йөрткән (татарча **«Тау иясе»**).

Матриархат булу сәбәпле, тувалылар, ихтимал, **Олы Енисей** (төркичә **«Олы Ана – Әни Су»**) башлангычындагы тау өркәчен – **«Өтүкен»**не хатын-кызлар алласына тиңләгән.

Икенче Каганаттагы төркиләрдә ул Ил-Ватан һәм Яклаучы саналып, анда аларның сәяси һәм хәрби үзәге урнашкан булган.

Уйгырлар белән саларлар исә 6995 метр биеклектәге тауны **«Хан Тәңре»** дип атаган.

Шунысы кызык: Алания-Осетиядә шулай ук **«Тенгир-тау»** булып, аңа бу атаманы һуннар яисә аларның кабиләдәш тармакларыннан берсе булган болгарлар биргән булган.

Японнардагы таулар һәм урманнар иясе **«Тэгу»** рухы атамасының килеп чыгышы да борынгы төркиләр яисә гомум алтайлыларга бәйле булуы ихтимал.

Монгол кабиләләрендә дә дистәләрчә тәңреләр билгеле. Үзләренең бер императорын монголлар хәтта **«Тәңре-йин-Тэдхуг-сэн»** дип йөрткәннәр («СССР Фәннәр академиясенең Шәрык институтындагы монгол, бурят-монгол һәм ойрат кулъязмалары һәм ксилографлары. 1. Тарих, хокук», А.С.Пучковский, Мәскәү-Ленинград, 1957, 27 бит). Борынгы төркиләр һәм Дунай буе болгар чыганаклары нигезендә Болгария галиме **А.Стойнев** башлангыч болгарларның **Олуг Алла**сын болай дип бәяләгән: *«Тәңре кешегә хас рәвештә сурәтләнгән күренмәс ир-ат Алла кыяфәтендә күз алдына китерелеп, ул күк, кояш, айгыр, бөркет билгеләмәләре белән сыйфатлана, ә вазыйфалары исә хәрби, төзү-хуҗалык, хокук (гаделлек, кешеләр язмышы белән идарә итү, яклау, курку хисе биреп торучы, җәза кылучы, бүләкләүче), дини хөкемдар дип бәян ителә».* («Волжская Булгария: духовная культура», домонгольский период 10-нач. 13 вв., Г.М.Дәүләтшин, Казан, 1990, 58 бит).

Анда язылганча: *«Болгарлар уенча, Тәңренең хәтта төсе дә (зәңгәр, ак, ачык) саклау куәтенә ия булган»* (шунда ук, 59 бит).

Борынгы төркиләрдә шулай ук **Җир-Су тәңресе** дә шөһрәт ителгән. Бу хәтта ислам динен кабул иткән төркиләрдә дә сакланып калган. Әйтик, кыргызлардагы **Жер-Суу** рәвешендә.

Сүз уңаеннан: тугандашлык нәтиҗәсендәме, ерак Индонезиядә «ватан», «ил» мәгънәсендәге гыйбарә төркиләрдәге **«Җир-Су»** – **«Танах-Аир»**га туры килә.

Нугай татарлары балигъ булып җиткән егетләргә мондый алкышлар – теләкләр тели торган булган:

Тәңрең иңдергән бәхетең
Һәрвакыт синдә торсын,
Халыктагы ат-аманың
Хөрмәтле билге булсын.
Өлкәннәрне олы ит син,
Кечеләрне кече ит,
Туган вә тумачаларыңны
Какма-сукма, кеше ит.
Куәтле бул син таулардай,
Иркен күлдәй шаулардай...

(«Дагыстан халыкларының тылсым поэзиясе», Махачкала, СССР Фәннәр академиясенең Дагыстан филиалы, 1989, 74-75 битләр).

Умай – хатын-кыз кыяфәтендәге алиһә (төрек телендә – **«Таңрыча»**). Умай борынгы төрки рун язмаларында искә алына.

Умай – балалар, яңа туганнар, йөкле хатыннар, уңдырышны яклаучы зат, аны Алтай шаманнары, камнары бүгенге көндә дә хөрмәтле. Урта Азиядәге кыргызлар миң белән туган балаларны, **«Умай эзләре»,** дип, бәхетлегә юрый.

Төркиләрнең юлбашчысы Төньюкүк шәрәфенә халык «Күк», ягъни «Тәңре» дигән рун язмасы пәйда була, дип көткән, ул җиңү китерә, дип ышанган.

Умайны (**«Ымай»**, **«Омай»**) телеутлар, белтирләр, качиннар, сагайлар, кумандиннар, шор татарлары, кара татарлар (төньяк алтайлылар һәм далаганнар). Ә тувалылар, белтирлар, сагайлар, качиннар һәм шор татарлары тагын **«Кара Умай»** дигән затны да белгән.

Алтай кабиләләре Умайны төрлечә – **«Умай Ана»**, **«Ымай»**, **«Май»** дип атаган.

Умайга мөрәҗәгать иткәндә телеутлар һәм хакаслар аны Ут сурәтендә чакырган, кыргызларның Ут культы кайвакытта балаларны яклаучы Умайга төбәлгән (юнәлтелгән) була.

Кыргызларда бүгенге көнгә кадәр, «Сиңа Умай ана ярдәм итсен» дигән алкыш сакланып калганын искәртеп китү урынлы булыр. Дагыстандагы хатын-кызларның төрки кумык лигасы **«Умай»** дигән исем йортә.

«Борынгы болгарларның ырым-ышанулары нигезендә ут башлангычының шактый киң җәелүе хакында археология чыганаклары, аерым алганда, савыт-сабалардагы хач (тәре), свастика, ромб һәм башка билгеләр шәһадәтнамә була ала». («Волжская Булгария», домонгольский период, 10-нач. 13 вв., Г. Давлетшин, 1990, 61 стр.)

Тәре (хач, кач), свастика, ромб һәм башкаларның сурәтләрен мишәр вә башка төркиләрнең кием-салымнары һәм сөлгеләре бизәк-нәкышләрендә күрергә була.

Чуваш шагыйре **В.Тургай** болай дип язып чыккан иде: *«Сталин заманында йөзләрчә чуваш авылы кызлары ГУЛАГта фәкатъ гореф-гадәтләрне дәвам итеп, тегү-чигүдә чуваш нәкышенең иң борынгы формасы – свастика тукыганнары өчен генә дә харап булды!»*

VIII-X гасырларда Көньяк-көнчыгыш Ауропадагы күчмә төрки халыкларның мәдәниятен һәм тормыш-көнкүрешен өйрәнгәндә, С.Плетнева аларның дөньяны аңлауларын чагылдырган амулетларын (бөтиләрен) билгеләп үтә.Алар арасында бигрәк тә Тәңре һәм Кояшка бәйле булганнары игътибарны җәлеп итә.

Балкарлар белән карачайларда иң күп таралган бөтиләрнең берсе – ут-кояш-хачның әйләнмәдәге сурәт мәгънәсе борынгы заманнарда бик киң таралган вариантлардан берсен тәшкил иткән дүрт нурлы түгәрәктән гыйбәрәт.

Бу ут-кояшның борынгы символы балкар, карачай халыкларының киез келәмнәрендәге, папаха, киез эшләпәләре һәм башлыкларындагы иң яратып тукыла торган бизәкләрен тәшкил итә. Бу уңайдан Баксан тарлавыгындагы Тызып елгасы башлангычының XVI-XVII гасырларга караган тау кыяларына төшерелгән үзара кисешле дүрт нурлы әйләнәне искә төшерү кызыклы булыр. Ошбу мәгънәле сурәт балкар һәм карачайларның борынгы һәм катгый каргышлары «Тейри урсун!» («Тәңре орсын»ы!) белән бәйле.

М.Ковалевский билгеләп үткәнчә, балкарлар борынгы бер йоланы саклап килә: *«Таяк очы белән җиргә әйләнә сызалар, шуннан соң аңа аркылы-торкылы ике сызык (дүрт нур) төшерәләр, түгәрәк уртасына кереп басалар да ант итәләр. Бу йола аларда кач дип атала».* (Төрек телендә – хач). («Очерки истории: культура Балкарии и Карачая XIII-XVIII вв»., И.И.Мизиев, Нальчик, изд. «Нарт», 1991, 149 стр.)

Әлеге китаптан китерелгән өзек кырым татарларында: «Тәңре урсун сизни!» – «Сезне Тәңре орсын!» – дип яңгырый. (Хәзерге казан татарларында: «Кояш орсын!», «Яшен орсын!», «Җир орсын!»).

Ахыры бар ■

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫННАН ҮРНӘКЛӘР

БӨЕК ТУКАЙ АДАШЫ

Сәхифәне Ләбиб Лерон алып бара.

Үзбәк шагыйре Абдулла Арипов Казанга 1986 елның июнендә Тукайның 100 еллыгы уңаеннан оештырылган бәйрәмгә килгән иде. Без шул бәйрәм көннәрендә таныштык. Ул чакта аңа – 45, миңа 25 яшь булган икән. М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында узган тантаналы чара вакытында Абдулла әкә белән без залда янәшә утырдык. Чыгыш ясар алдыннан аның: «Бөек Тукай белән без адашлар: ул да Габдулла, мин дә. Аның әтисе дә Гариф исемле, минеке дә!» – дип әйткәне истә калган.

Кунаклар, шул исәптән Абдулла Арипов та, Казанга 10 июньдә килде. 11ендә Тукай музее ачылды, кичен Опера һәм балет театрында зур тантана булды. 12 июньдә исә барча халык мәшһүребез Тукай ватанына – Кырлайга җыелды. 13ендә кунакларны озаттык. Саубуллашыр алдыннан, Абдулла әкә «Моему брату, другу Лобибу с уважением и благодарностью. Приезжай, пожалуйста, в Ташкент. Казань. 13 июня, 86» дип язып, Ташкентта рус телендә чыккан китабын («Удивление») бүләк итте.

Ни кызганыч, Абдулла әкә белән безгә очрашу бүтән насыйп булмады.



Абдулла Ариповның Ләбиб Леронга биргән култамгалы китабы. 1986 ел

Үзбәкстанның халык шагыйре Абдулла Арипов

1941 елның 21 мартында, ягъни Бөек Ватан сугышы башланырга нәкъ өч ай кала туган Абдулла Гарифбәй улы Арипов 2016 елның 5 ноябрендә АКШның Хьюстон шәһәре хастаханәсендә вафат була. Үзбәкстанның халык шагыйре (1983), Үзбәкстан Каһарманы (1998), Үзбәкстан гимны сүзләре авторының җәсәден 10 ноябрь көнне Америкадан Ташкентка алып кайтып, Чыгатай зиратында җирлиләр.

Гарифбәй Гобәйдулла улы гаиләсендә сигезенче бала булып туган Абдулла «Кош» дип аталган тәүге шигырен Ташкент дәүләт университетының үзбәк филологиясе факультетында – журналистика бүлегендә укыган чакта яза. «Йолдызчык» дип аталган беренче китабы исә 1965 елда дөнья күрә. 1996-2009 елларда А.Арипов Үзбәкстан Язучылар берлеге рәисе вазыйфасын башкара.

Абдулла Арипов шигырьләре

ГАДЕЛЛЕК

– Шикләнми ал! – дип, ярлыга
Тәкъдим иттеләр байлык.
– Кирәк түгел, байлык бит ул,
Ким дигәндә, бер айлык! –
Дип әйтте карт һәм өстәде:
– Әйткәнем хак, дөрестер.
Бу дөньяда гаделлек бар,
Бар байлыктан ул өстен!

Бервакытны, ахшам җиткәч,
Килделәр дә янына,
Үләргә яткан бер байдан
Сорадылар җай гына:
– Алтын колы булмаган зат
Бу дөньялыкта бармы?
Иреннәрдән чыкты өч сүз:
– Хаклык эзләүче ярлы.

КОШЛАР КИТКӘНДӘ

Өер-өер кошлар очып үтте.
Кулда каурый. Буп-буш күк йөзе.
Еракларга очты тиле яшьлек,
Сагыш булып калды тик эзе.

Сагыш кына калды яшьлектән, дип,
Син алай бик әйтмә кистереп.
Һаман да бит тәүге үбешкән мәл
Тора йөрәкләргә көч биреп.

ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

Кайгылы йөз ясап йөрмә, егет,
Тырышма да, шуны аңла син:
Минем кебек көлә белсәң дә бит,
Минем кебек елый алмассың.

***

Җәлләгән булып,
син кимсетмә шагыйрьне.
Тормыш бит: гел тигез
булмый ул барыр юл.
Шуны бел: дөньяда мәхәббәт бар әле,
Яшәтә шагыйрьне, яшәртә бары ул.

***

Бар да бертөсле булса әгәр дә,
Дөнья кызыксыз булыр иде бик.
Һәр акыллыга йөз ахмак тиеш,
Саклансын, дисәң, җирдә тигезлек.

Л.Лерон тәрҗемәсе. ■

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

Томск. Почтамт урамы. XX гасыр башы

ТОМСК

Томск шәһәре элек-электән гаять мәшһүр сәүдә үзәге булган. Кайчандыр биредә бик зур базар шаулап торган, бөтен Себердән сәүдәгәрләр җыелып, биредә сәүдә итә торган булганнар.

Ул заманнарда әле тимер юл булмаса да, атлар, чаналар кулланып, 2000-5000 чакрым юл үтеп килгәннәр. Ул заманнарда Русиядә прогон[1] юлы салынган һәм бөтен шәһәрләр бу юл аша бер-берсенә бәйләнгән була. 20-25 яки иң күп дигәндә, 30 чакрым саен бер станция булган. Бу станцияләрдә һәрвакыт атлар әзер тотылган, ә станция хуҗалары, һәрвакыт әзер булып, юлчы көткәннәр. Юлчы килеп җитәр-җитмәс, атлар алыштырылып

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

[1] Рус телендәге *прогон* «куып алып бару» сүзеннән булырга тиеш. Бу юллардан шәһәр базарларында сату өчен терлекләр куып алып барылган ***(тәрҗ. иск.)***.

җигелә торган булган һәм юлчы шунда ук утырып китеп тә барган. 25 чакрым юлны кыш көннәрендә атлар ике сәгать эчендә үтә алалар икән. Алдагы станциягә килеп җиткәч, атлар кабат алыштырылган һәм шул рәвешле, юлчы көне-төне бертуктаусыз, атларны алыштыра-алыштыра, юлын дәвам итә торган булган. Нәтиҗәдә, тәүлеккә 300 км тирәсе юл үтә алган. Моның чыгымнары һәр чакрым өчен ике атка – 30-40 тиен, өч ат җиксә, 50-60 тиен акча булган. Безнең Русия сәүдәгәрләре ул заманнарда Томск шәһәренә менә бу юл белән ел да бер тапкыр барып кайта алганнар. Хәзер исә, тимер юл салынгач, ел да берничә тапкыр барып кайтырга мөмкинлек туды.

Томск – сәүдә үзәге генә түгел, гыйлем чишмәсе дә, ул бик дәрәҗәле университетка ия. Университетлы шәһәр булу – мәгариф мәмләкәте булу дигән сүз. Шәһәрнең бөтен җире тәртиптә тотылганлыгы күзгә ташлана. Биредә бу шәһәрнең мөселманнары турында бераз мәгълүмат бирергә телим.

МӘЧЕТ, МӘДРӘСӘ, МӘКТӘП

Томск мәчетенең бинасы бик төзек һәм матур. Мәчет бүгенге көндә бөтен Себердәге мәчетләр арасында иң зуры, иң күркәме. Әйтүләре буенча, ул бары тик халыкның үз көче белән генә салынган. Мәчет каршысында бик төзек, бик матур мәдрәсә дә бар.

Томск шәһәрендә 3000гә якын мөселман яши, боларның барысы да бер мәхәлләгә карый. Моннан тыш, әле биредә 3 мәктәп тә бар. Мәктәпләрнең һәрбере аерым, үзләренең идарәләре бар, акчалы һәм ачык фикерле берничә кешенең ярдәме белән эшләп киләләр. Ахун җәнаплары исә, мәчетне һәм аңа бәйле оешмаларны үзенең малы итеп саный, 20-30 шәкертне ул зур биналар эчендә ачлы-туклы тота. Шул ук вакытта, Томск байларының берсе – Кәрим Хәмитов, берничә кеше белән берләшеп, 70-80 шәкерт укыта. Болардан тыш, Шаһихаҗи Сәйдәшев җәнаплары да олы җанлылык белән байлыгыннан өлеш чы-

Томск. Мәчет. XX гасыр башы

гарып, 60лап мөселман баласын укыту-тәрбияләү эшенә ярдәм итә.

Шул рәвешле, өч якта өч көч булып хезмәт итүче бу төркемнәрнең барысының да ниятләре изге икәнен сизеп, боларның бер көч булып берләшүләренә этәргеч булырга тырыштым. Бик күп үгет-нәсыйхәт бирдем, күп кеше җыелган мәҗлесләрдә дә, кара-каршы күрешеп сөйләшкән вакытларда да калебләрне берләштерү өчен гыйбрәтле сүзләр сөйләдем, күп көч куйдым. Аллага шөкер, беркадәр уңышка да ирештем. Бер-берсенә сәлам да бирми яшәгән кешеләр, моннан соң бер-берсен өйләренә чакырып кунак итә башладылар, кардәшлек хисләре яңарды.

ТОМСК МӨСЕЛМАННАРЫ

Томск мөселманнары – гаять саф күңелле, гади кешеләр. Аларда фанатлык та юк, шул ук вакытта араларында гыйлем һәм мәгърифәт әһелләре дә юк. Болар язмышларының шаукымы белән Русиянең эчке төбәкләреннән бу якларга килеп урнашканнар. Араларында берән-сәрән генә булса да бай кешеләр дә очрап куя.

Томск шәһәрендә «инородец» дигән җирле татарлар инде юкка чыгып беткәннәр диярлек, бик аз калганнар. Араларында бай кешеләр очрый, ләкин күп түгел. Бохаралылар да инде тәмам юкка чыгып баралар. 400-500 еллар элек Бохарадан бирегә килеп урнашкан, бу җирләрне ватаннары иткән бичараларның бүгенге көндә тамырлары корып бара, нибарысы 150ләп кеше калган. Шулай булса да, үзләренең аерым идарә төркемнәре бар.

Томск мөселманнары арасында үтә ярлылар да, артык байлар да юк. Һәммәсе дә – кулы эш белгән кешеләр яисә сәүдәгәрләр.

Боларның күбесе бүгенге көндә тегүчелек белән шөгыльләнә. Сәбәбе шул: русларның күбесе монда татар киемен кия икән, кеше күп, эш күп. Шулай итеп, тегүчелек татарларга көн күрү өчен һөнәргә әйләнгән.

Томск шәһәрендә бай яисә урта хәлле мөселманнар миңа хөрмәт күрсәттеләр, шул ук вакытта руслардан да шактый кеше игътибар күрсәтте, махсус мәҗлесләр оештырып чакырдылар, профессорлар Соболев[2], Малиновский[3] һәм мәшһүр сәяхәтче Потанин[4] һәм башка кайбер шәхесләр белән таныштым.

ТОМСК ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘСЕНДӘГЕ АВЫЛЛАР

Томск янында мөселман авыллары бик аз, саны нибарысы 25ләп булыр. Авыл халкының күпчелеге җирле Себер татарлары булса да, Русиянең эчке төбәкләреннән күчеп килеп урнашканнар да аз түгел. Араларында, үз теләкләре белән күчеп утырганнар белән бергә, сөргенгә сөрелеп килгәннәр дә аз түгел. Тик болар җирле татарлар белән, матди һәм рухи мәнфәгатьләргә туры китереп, кыз алып, кыз биреп, туганлашып, дуслашып яшәгәннәр. Шул сәбәпле, беренчедән, нәселләре корый башлаган Себер татарларында гаҗәеп дәрәҗәдә халык саны арту күзәтелә башлаган. Икенчедән, Русиянең эчке төбәкләреннән күчеп утырган мөселманнар Ислам динен яшәтү һәм җәелдерү өчен тырышканнар, һәр җирдә мәктәп ачканнар, мәчетләр төзегәннәр. Шул кечкенә-кечкенә авылларның һәрберсендә Исламиятнең бер билгесе булган мәктәпләр бар. Ике төрле канның бер-беренә кушылуы рухның көчәюенә китергән. Себер татарлары – саф күңелле,

[2] Соболев Михаил Николаевич (1869-1945) – экономист, Томск университеты профессоры, Г.Н.Потанинның якын дусты ***(тәрҗ. иск.)***.

[3] Малиновский Иоанникий Алексеевич (1868-1932) – тарихчы, хокукчы, җәмәгать эшлеклесе, 1898-1913 еллар арасында Томск шәһәрендә яшәгән, Томск университеты профессоры ***(тәрҗ. иск.)***.

[4] Потанин Григорий Николаевич (1835-1920) – география һәм этнография белгече, фольклорчы, публицист, җәмәгать эшлеклесе, 1902 елдан Томск шәһәрендә яшәгән һәм 1920 елда шунда вафат булган ***(тәрҗ. иск.)***.

тыныч холыклы мөселманнар, Русиянең эчке төбәкләреннән күчеп килгәннәр исә – эшчән һәм хәрәкәтчән кешеләр, ике ыруның берләшүеннән төс-кыяфәт белән дә, әхлак һәм холык-фигыль белән дә уртача булган халык барлыкка килгән. Бу якларда элек-электән яшәгән җирле татарларның ырулары буенча ак калмыклар[5] булулары кайбер борынгы язмалардан билгеле.

Бу татарлар арасында мәҗүсиләр дә бар. Мәҗүсиләр белән мөселманнарның телләре бер, ләкин мәҗүсиләрне «абгайлар» дип атау киң таралган. Руслар исә аларның һәммәсен дә «инородец» дип атый. Гомумән, бу атама бөтен Русиядә рус булмаган халыкларның барысына карата да кулланыла һәм мәгънәсе дә шул ук – «чит ырудан, ягъни рус булмаган».

РУСЛАРНЫҢ ТОМСК ТӨБӘГЕН ЯУЛАВЫ

Ул заманнарда бу җирләр киң дала икән. Берән-сәрән, күчмә тормыш итүче берничә мең татардан башка беркем юк икән. Руслар килгәннәр: «Бу җирләр инде безнеке булды», – дигәннәр. Яулап алу өчен бөтен хокуклары – менә шул. Бу хәлләрдән соң: «Юк, бу җирләр минеке», – дип, каршы төшүчеләр дә булган. Аларга берни димичә, чикләренең кайда икәнен сораганнар. Болар, күз җитеме бер җирдә чикне күрсәткәннәр, аларга бу җирне калдырганнар. Калган бөтен очсыз-кырыйсыз җирләр бер-ике кешенең осталыгы белән яулап алынган.

Бүгенге көндә кайбер татарларның кулларында шактый киң мәйданны тоткан җир хуҗасы булуларын күрсәтүче һәм руслар тарафыннан расланган таныклыклар бар. Болар югарыда әйтелгәннәргә дәлил булып тора, чөнки бу таныклыкларда зиһеннәрне тынычландырыр өчен язылган гыйбарәләр дә бирелгән.

КАЛТАЙ АВЫЛЫ

Томск төбәгендә бу авыл игътибарымны бик нык җәлеп итте, шуңа күрә аның хакында аерым язарга кирәк, дип таптым. Калтай – күпчелек өлеше руслар булган бик зур авыл. Аның 21 йортында татар гаиләләре яши. Болар бик ярлы мөселманнар булсалар да, үзләренең мәчетләре, мәктәпләре һәм китапханәләре бар. Бер ел элек ачылган мәктәпләрендә 45ләп бала укый. Укытутәрбия эше бик яхшы тәртипкә куелган. Мәктәп ачылганга кадәр, бу балалар укый-яза белмәгәннәр. Мин мәктәпкә килгәч, аларның һәммәсеннән имтихан алдым. Барысы да бик яхшы укый һәм яза, Ислам нигезләре, фарыз һәм шартларыннан тыш, әле тагын арифметиканың дүрт гамәлен дә беләләр. 21 йорттан 45 укучы белем ала. Болар арасында 21 яшьлек егетләр дә, 18 яшьлек кызлар да бар. Аларны ике төркемгә – ир балаларга һәм кыз балаларга аерып укыталар. Яшьләрне Ислам әдәбенә туры китереп тәрбияләргә тырышулары күренеп тора. Авылның олы яштәге ирләре исә кичке дәресләргә һәм китапханәгә йөриләр икән.

Мөселман мәхәлләсенә терәлеп үк яшәп яткан 100 йортлык урыс мәхәлләсендә берни, хәтта чиркәү дә юк. Кайбер урыс балаларын мөселман мәктәбенә бирергә теләүчеләр булган, ләкин хөкүмәт кешеләре каршы чыккан.

Бу авылда мәктәпнең чыгымнары елга 550 сум тирәсе җыела һәм аны да әлеге 21 йорт бергәләшеп күтәрә икән. Бу күренеш – нигездә бер имам белән бер мөгаллимнең тырышлыгы нәтиҗәсендә барлыкка килгән дини куәт.

Бездә «Колларның иҗтиһады, ягъни тырышлыгы, үлгәнне дә терелтер» дигән мәкаль бар, нәкъ менә бу авылдагы мөселманнарның хәленә туры килә.

---

[5] Ак калмыклар – бүгенге алтай халкының тарихи этник компонентлары булган телеут һәм теленгитларның борынгы атамасы (тәрҗ. иск.).

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

СӘФӘРЕМНЕҢ АХЫРЫ

Бу көнгә кадәр сәфәремнең кайда тәмамланасын берәүгә дә әйтмәгән идем. Беркөнне Томск шәһәрендә Потанин әфәнденең өендә кунакта идем, тагын берничә кеше бар иде. Сәфәремнең кая кадәр дәвам итәчәге турында сорадылар, аннары «Сибирская жизнь» газетасына бер мәкалә язуымны да үтенделәр.

Биредә сәфәремнең соңгы ноктасы турында рус газетасына язма бирәчәгем беленгәч, бу вакыйганың гаиләм кешеләренә аерым тәэсире булачагын уйлап, иң башта аларга хат язып, бу хакта хәбәр бирдем. Үз матбугатыбызга да сәфәремнең кайда тәмаммланачагын ачыклап мәкаләләр җибәрдем.

Беренче мәкаләм «Сибирская жизнь»[6] газетасының 265 нче санында басылып чыкты. Анда сәфәремнең күпмегә сузылачагы, кай җирләргә барачагым турында шактый җентекләп язган идем.



...дарственнаго кредита нашло, что министерство финансовъ при составленіи государственной росписи доходовъ и расходовъ «прибѣгло къ совершенно незаконному и съ бюджетной точки зрѣнія не допустимому обходу». Министерство въ росписи чрезвычайныхъ расходовъ не включило займъ въ 300 милліоновъ рублей, подлежащій оплатѣ въ маѣ 1909 г.

Въ данномъ случаѣ, по мнѣнію докладчиковъ, «министерство очевидно руководилось желаніемъ преуменьшить дефицитъ».

Если къ этой суммѣ теперь прибавить пособія населенію, пострадавшему отъ неурожая, *) то цифра дефицита возраститъ до угрожающихъ размѣровъ полумилліарда!

Н. М.

(Окончаніе будетъ.)

Изъ мусульманскаго міра

Общій обзоръ положенія мусульманъ въ Россіи.

Сколько вѣковъ прошло уже съ тѣхъ поръ, какъ мы, русскіе мусульмане, въ особенности внутреннихъ губерній Россіи, живемъ вмѣстѣ съ нашими покорителями — русскими въ одномъ отечествѣ, губерніи, уѣздѣ, волости, деревнѣ и городѣ, а иногда даже и въ одной семьѣ, вмѣстѣ работаемъ, торгуемъ, учимся, прово...

*) Хотя г. министръ категорически заявляетъ, что таковыхъ расходовъ «не потребуется». Но на основаніи заявленія г. министра, нѣсколькими страницами передъ этимъ, о значительномъ недородѣ, я думаю, что таковые расходы потребуются.

ТОМСК ДЕПУТАТЫ НЕКРАСОВ[7]

3 ноябрь көнне Томск шәһәреннән китәргә уйладым. Саубуллашыр өчен Потанинның өенә барган идем, ул миңа: «Иртәгә кич безнең депутатыбыз Николай Некрасов җәнаплары III Думаның эшләре турында сайлаучыларына хисап бирәчәк, сәфәрегезне бер көнгә кичерегез дә бу җыелышка сез дә катнашыгыз», – диде.

Мин бик теләп ризам булдым. Ул көннәрдә Томскига хокукчылар делегациясе тәркибендә (составында) килгән Закир әфәнде Ишмөхәммәтов җәнаплары да Томск шәһәрендә иде, аның янына киттем. Без инде аның белән берничә тапкыр күрешкән дә идек. Аңа да Некрасов җәнапларының җыелышына килергә тәкъдим иттем.

Икенче көнне кич белән билгеләнгән җиргә килдек, зал туп-тулы иде, 3000ләп кеше булгандыр. Без урыннарыбызга утырганнан соң 5 минут вакыт та үтмәгәндер, Некрасов җәнаплары трибуна артына чыгып басты. Ораторлыгы белән киң танылган бу шәхес, күп дигәндә 33 яшьләрдәге яшь кенә кеше иде.

*Төрекчәдән **Асия Рәхимова** тәрҗемәсе.* ■

---

[6] Габдеррәшит Ибраһимовның бу мәкаләсе «Из мусульманского мира. Общий обзор положения мусульман в России» дип атала. Мәкаләнең астында авторның тулы исеме күрсәтелмәгән, Ибрагимов дип кенә куелган һәм [Продолжение будет] дигән искәрмә тора ***(тәрҗ. иск.)***.

[7] Николай Виссарионович Некрасов (1879-1940) – белгечлеге буенча инженер, сәясәтче, Дәүләт Думасының III һәм IV чакырылышларында Томск губернасыннан сайланган Дума әгъзасы, революциядән соң Уфада һәм Казанда яши, 1939 елда Мәскәүдә кулга алына һәм 1940 елда атып үтерелә ***(тәрҗ. иск.)***.

Уфада яшәп иҗат итүче өлкән шагыйребез Мидхәт Әбделмәнов янә ике җырчыбыз – Зөһрә Сәхәбиева белән Бәширә Насыйровага «Безнең мирас» журналын яздырды. Игелекле гамәлегез өчен бик зур рәхмәт, Мидхәт ага!

Рәхмәт сүзе

Хөрмәтле кардәшем!

Телебез һәм милләтебез язмышы өчен борчылудан йөрәкләребез парә-парә килгән шушы авыр, болгавыр заманда «Безнең мирас» журналы белән бергә булганың өчен әүвәл Сиңа ихлас рәхмәтемне белдерәм!

Чын мәгънәсендә туган җанлы, ярдәмчел, игелекле, милләтпәрвәр затларыбыз бар ул, бар! Мәсәлән, Уфада яшәп иҗат итүче өлкән шагыйребез **Мидхәт ага Әбделмәнов** – нәкъ менә шундый шәхесләребездән берсе. Ул янә ике асыл җырчыбыз – Зөһрә Сәхәбиева белән Бәширә Насыйровага **«Безнең мирас»** журналын киләсе ярты еллыкка яздырды (бүләк итте, дип аңларга кирәктер)! Без белгән һәм әле белеп өлгермәгән шундый бик күп фидакәрләребез бар, Аллага шөкер! Рәхмәт яусын аларга да!

«Безнең мирас» битләрендә тугандаш Башкортстанга (әйтик, Туймазы, Эстәрлебаш, Чакмагыш, Шаран һәм Илеш районнарына), Татарстанның ут-күршесе булган Ульяновск өлкәсенә, аерым алганда Иске Кулаткы төбәгенә, Мари Иленең Бәрәңге һәм Курган өлкәсендәге Сафакүл һәм Әлмән районнарындагы авылларга, үзебезнең Арча, Әтнә, Әлмәт, Азнакай, Алабуга, Чаллы, Мөслимгә кагылышлы, динебезгә, әдәби мирасыбызга нисбәтле кызыклы язмалар еш басыла икән, моның сәбәбен ул төбәкләрдә яшәүчеләргә басмабыз күбрәк тарала, дип аңларга кирәк. Журналыбызны нәкъ менә шунда алдыруда яисә таратуда исә, әлбәттә, игелекле, изге ниятле җитәкчеләребезнең – «Таттелеком» АҖнең генераль директоры **Лотфулла Шәфигуллин**ның, «Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе **Рөстәм Мөхәммәдиев**нең, Татарстан Язучылар берлеге рәисе **Данил Салихов**ның, «Бөтенроссия татар авыллары» иҗтимагый оешмасы рәисе **Фәнир Галимов**ның, Россия мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте рәисе, шәех, мөфти **Равил** хәзрәт **Гайнетдин**нең, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти **Камил** хәзрәт **Сәмигуллин**ның, Уфадагы «Ислах» мәчете имам-хатыйбы **Мөхәммәт** хәзрәт **Галләм**нең, Курган өлкәсе Татар конгрессы рәисе **Марат Юнысов**ның, Чаллы шәһәре башкарма комитеты рәисе урынбасары **Рамил Хәлилов**ның, Иске Кулаткы, Бәрәңге, Әтнә, Азнакай, Мөслим районнары хакимияте башлыклары **Эдуард Ганиев**, **Әлфит Ибраев**, **Габделәхәт Хәкимов**, **Марсель Шәйдуллин** һәм **Рамил Хәмзин**нарның, Питрәч районы мәдәният бүлеге җитәкчесе **Айгөл Хикмәтуллина**ның, Казандагы 20 нче гимназия директоры **Рәхимә Арсланова**ның «Минзәлә» газетасының баш редакторы **Илдус Шәһиев**ның, шулай ук нәкышче, рәссам-хаттат **Нәҗип Нәккаш**, **Дамир Юнысов** (Свердловск өлкәсе) кебек аерым милләттәшләребезнең өлеше зур. Олы рәхмәт сезгә, кадерле туганнар! Эшләрегез гөрләп барсын, уй-ниятләрегез тормышка ашсын!

Бергә булыйк, бердәм булыйк. Бергә булсак, берәгәйле булырбыз, иншаллаһ!

Ихтирам белән:
«Безнең мирас» журналының баш мөхәррире ***Ләбиб ЛЕРОН***
25 декабрь, 2017 ел ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

Хәлфә бабай

Госман Гомәр

Эссе

«Әрәд-дунийа хәрабән бигътибарый фә лә йәбка мәдамнән бил-карарый».

Ошбу гыйбарәнең тәрҗемәсе болайрак булыр: «Күрәмен үтеп баручы дөньяны җимерек хәлендә, шул килеш тормас ул бертөрле мәңгегә».

Тарих тәгәрмәченең зырлап әйләнүен тоемлаган Хәлфә бабай Коръәни-Кәримне яшьтән үк хәтем кылган. Хәлфә бабай – Идрис Зөлмөхәммәд улы, авылдаш-якташларына әлеге сүзләрне еш искәртә торган булган. «Фани дөньяда гафиллек берлән яшәмәгез, безне көткән бакыйлыкны (мәңгелекне) истән чыгармагыз, изге гамәлләр кылыгыз, Аллаһының сөекле бәндәсенә әверелегез!

Бер надан кемсәнең (затның) бозык юлга барганын күреп, галим булып та, аңа төзек юлны күрсәтмәсәң – олуг хыянәт ошбудыр.

Аллаһ ризалыгы өчен, туган кавеме файдасына башкарылган бер саваплы эш – мең баләдән коткарыр...» – дип үгет-нәсыйхәт биргән Идрис хафиз.

Кем соң ул халыкка шулай тәрбия биргән Хәлфә бабай?

Чын аты тарихта мәгълүм инсан – Идрис хафиз Зөлмөхәммәд улы – күренекле дин белгече, нигезен шәех Һидиятулла Хуҗа Әхмәт Ясәви хәзрәтләре салган тарикать тарафдары, фәлсәфәче, табиб-күрәзәче (яхшы мәгънәсендә), әдип-шагыйрь һәм башка рухи байлыкларга ия зат. 2000 елның җәендә киң җәмәгатьчелек аның 350 еллыгын фәнни-гамәли конференция белән билгеләп үтте, каберен зиярәт кылды. Мәгълүм булсын: бөек шәхеснең җәсәде – хәзер Балык бистәсе районына кергән Чаллы ханлыгы туфрагында.

Беренче чыганак буларак, без Идрис хафиз Зөлмөхәммәт турындагы мәгълүматларны Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Мөслими әл-Болгариның «Тәварихы Болгария» һәм Таҗетдин Ялчыголның «Рисалаи Газизә» дигән китапларыннан табабыз. Соңрак галимнәребез Марсель Әхмәтҗанов, Фаяз Хуҗин, Рәшит Галләмов, әдип һәм журналист Нурулла Гариф хезмәтләре аша әлеге шәхеснең яңа яклары ачылды. Филология фәннәре докторы М.Әхмәтҗанов хезмәтләренә таяну – безнең өчен зур мәртәбә, чөнки аның дәлилләре нигезле. Идрис хафизның әтисе Зөлмөхәммәд хәзрәтнең XVII гасыр башларында элекке Чаллы ханлыгында яшәгәнлеген искәртә галим. Ниндидер сәбәпләр аркасында, хәзрәт Болгар туфрагына барып сыена – Базарлы Матак (хәзерге Әлки районына керә) карьясында кинәт кенә пәйда була. Туган җирен искәртеп торсын, дип, яңа урында Яңа Чаллы авылын нигезли. Бүгенге көндә дә авыл халкы зираттагы бер кабер ташын Зөлмөхәммәдкә куелган кабер ташы дип исәпли. Ул хәтта сәяхәтче мосафирларның юлъязмаларында «Зөлкә ата», «Чөлкә ата», «Чүлкә ата» рәвешендә искә алына. Идрис хафиз – шул атаның газиз баласыдыр!..

Зөлмөхәммәд хәзрәт үзенең зур өметләр баглаган, яшьтән үк Коръән хафиз дәрәҗәсенә ирешкән укмышлы улын, ни өчендер, Шәрык тарафына түгел, Явыз Иван яулап канга батырган Казан ханлыгы җиренә озата, аның иза чигүче милләттәшләрен яклаячагына өметләнә. Яшь егет чыннан да көрәш юлына баса, көчләп чукындыру сәясәтен гаепләп чыгышлар ясый, аны туктатуны таләп итә. Бер үк вакытта үзендәге сихри (яхшы мәгънәсендә) куәт белән авыру-сырхауларны дәвалый. Әлбәттә, аның бу гамәлләре шовинист түрәләрнең ачуын кабарта.

Бер риваять. Патша хөкүмәтенең көчләп чукындыру сәясәтенә каршы чыккан милләтпәрвәрне әләрлеклиләр, кулга алып, зинданга ташлыйлар. Идрис хафизның алдан күрүчәнлегенә, башкаларны дәвалау сәләтенә ия икәнлеген ишеткән Казан губернаторы аны үз янына китертә.

– Җә әле, татар, син ничек киләчәк турында әйтә аласың? – дип сорый түрә аннан.

– Аллаһы Тәгаләнең көче, аның рөхсәте илә, – дип җаваплый тоткын.

– Син миңа бу көчне нинди юл белән исбатлый аласың?

– Могҗиза юлы белән, – ди хафиз.

Губернаторга ул үзен Кабан күленә алып барырга куша. Билгеле инде, ни булыр икән, дип, губернатор сараендагы гавам да күл буена ашыга. Халык җыелып беткәч, Идрис хафиз, кулындагы балдагын салып, губернаторга бирә һәм карап торучылар алдында аны күлгә ыргытырга куша. Балдак, билгеле инде, чупылдап, су төбенә китә. Идрис, дога укып, Аллаһыга ялвара. Шулчак могҗиза була: балдак, судан чыгып, һавага күтәрелә, аннары хуҗасының бармагына кигезелә. Бу хәлләргә хәйран калган губернатор татарны иреккә җибәрергә боера. Идрис хафизга исә халыкны котыртып бозмаска куша.

Ике ут арасында калган Идрис хафиз Кирмән тавына күтәрелә дә, таягын һавага чөеп, очы кай тарафка караса, шул якка китәрмен, ди. Шулай итеп, ул, ата-анасы дөньяга килгән борынгы Чаллы ханлыгы тарафына юл ала, Тәберде Чаллысы авылына килеп төпләнә. Бу чакта аңа егерме яшьләр тирәсе булгандыр, дип фараз кылына. Укымышлы, илаһи көчкә ия егет, һәрхәлдә, керәстиян эше белән шөгыльләнмәгәндер, мөгаллимлек иткәндер. Башкача булганда, үзенә, олылап, «Хәлфә» кушаматы ничек тагылыр иде?! Ул биредә авылның чибәр кызына өйләнеп, гаилә корып җибәрә. Берничә ел матур гына яшиләр. Уртак балалары булу-булмау мәгълүм түгел. Гыйлемгә омтылган Идрис хәлфә авыл халкы өчен көтелмәгән юлны сайлый – Бохарага укырга барырга ниятли. «Мине биш ел көт, кайтмасам, тагын ике ел көт, аннан соң да кайтмасам, кияүгә чыгарсың», – ди җәмәгатенә. Хатыны биш ел көтә, тагын ике елны да көтә – ире күренми. Җиде ел узгач, хатын күрше авыл мулласына кияүгә чыга. Җиде елга дип чыгып киткән Идрис Тәберде Чаллысына унбиш елдан соң гына әйләнеп кайта. Үзенең васыяте буенча, хәләл җефете инде икенче ирәүдә – күрше авыл мулласында кияүдә. Бу хәлне ул рухи фаҗига буларак кабул итә – кайгыра, зар елый. Әмма нишләмәк кирәк?! Ара өзелгән, никах укылган, хәләле икенче ирәүнең хатынына әйләнгән.

Хәлфә бабай кабере

Яшьлек мәхәббәтен күрәсе килү теләге шулкадәр көчле була ки, ул үзен тотып кала алмый, әүвәлге хатыны яшәгән йортка килә. Мосафир сыйфатында: «Өегезгә кереп, Коръән укып кына чыгыймчы», –

дип рөхсәт сорый. Хуҗабикә: «Чит кешене кертергә ирем өйдә юк шул, кырда, эштә чагы. Алай Коръән укыйм, дисәң, әйдә, рәхим ит», – дип, мосафирны ишектән үткәрә. Шулчак ни була?! Ходавәндә! Бу ул бит! Идрис хәлфә...үзе! Хатын аны мәкаменнән (көйле тавышыннан) танып ала һәм елап: «Җитте, җитте, белдем, син Идрис икәнсең», – дип туктата. Алга таба ни сөйләшкәннәрдер, Хәлфә бабай анысын язып калдырмаган. Фәйләсуф рухлы шагыйрь үзенең ошбу сәфәрен шигъри юллар белән тәмамлый:

«Килеп кердем гөлдәй булып,
Чыгып киттем көлдәй булып».

Шагыйрь, дидек. Чыннан да, Хәлфә бабай иҗат кешесе була, илдәге төрле вакыйгаларга карата фикерләрен халыкка шигъри юллар белән җиткерә. Әйткәнебезчә, киләчәкне алдан күреп тасвирлый, үткәндәге фаҗигаләр турында исә зар елый:

«Кала тавын Хан корыр,
Әйләнәсе яу булыр.
Тез тиентен кан булыр,
Чаллы кыры сау булыр».

Хәлфә бабай шушы исән калган Чаллы кырында (туфрагында диик) соңгы сулышына чаклы гомер кичерә. Алга китеп әйтик, җәсәде Тәберде Чаллысы зиратына иңдерелгән. Кабергә якын урыннан шифалы «Хәлфә бабай чишмәсе» тибеп тора. Суы ифрат сихәтле, аны тирә-як халкы гына түгел, Казан каласыннан да махсус килеп алалар.

Инде Калатау турында берничә сүз. Шагыйрь «Калатау» дип Чаллы ханлыгы кирмәнен әйтә. Ул бүгенге Тәберде Чаллысының сул ягына, биек тау башына урнашкан була. Кирмән өч кат үр белән әйләндереп алынган. Без яшь чакта диварның нигез ташлары күренеп тора иде әле. Аннары күп еллар бу урын колхозның авыл хуҗалыгы техникасын төзекләндерү мәйданына әверелде, пычранды, ямьсезләнде. Районның элекке җитәкчесе Равил әфәнде Хәйруллинга рәхмәт, техника станциясен башка урынга күчертү әмәлен тапты. Алай гына да түгел, кирмән-калага күтәрелү юлына символик капка да эшләтте.

Ни өчен капкамы? Риваятьләрдә, ханлык кирмәненең капкасы алтыннан коелган иде, диелә. Имештер, ханлыкны җимерергә килүче дошман явы турындагы шомлы хәбәрне ишеткәч, шәһәр халкы «Алтын Капка»ны җир астына күмеп куя. Ул хәзер дә шунда ята, ди. (Җәяләр эчендә генә булса да шуны әйтәсем килә: нишләп галимнәребез махсус приборлар ярдәмендә капканың урынын ачыкламыйлар икән соң? Әллә бу кадәресе матур бер әкият кенәме?! Һәрхәлдә, бай ханлык булган бит үзе. Шигырьдәгечә, кан коелган, ханлык җимерелгән. Тирә-як авыллар көчләп чукындыруга дучар ителгән. «Чаллы кыры сау булыр» дигәне зур авыллардагы төп халыкның исән калуына ишарә булып тора кебек. Җаны әрнегән шул Хәлфә бабайның).

Чаллы ханлыгына килгәндә, ул Казан ханлыгы белән бер чорда яши. Хаҗи Гәрәй хан вакытында зур күтәрелеш кичерә, байлыгы белән шөһрәт казана. Казан алынгач, Мәмәш Бирде җитәкчелегендә, Ватан азатлыгы өчен каршылык үзәгенә әйләнә.

Авылдашлары, алай гына да түгел, тирә-юнь халкы өчен Идрис хафиз – беренче чиратта остаз, өйрәтүче, дәвалаучы табиб, күңелләрне иркәләүче шагыйрь-чәчән дә. Яратып-сөеп әйтелгән исеме – «Хәлфә бабай». Аның киләчәкне алдан күреп әйтә белүе күпләрне таң калдыра, чөнки әйткәннәре һәрчак чынга аша – рас килә. Үри Чаллысы, Чураш һәм башка керәшен авылларында сырхауларны дәвалап йөргәндә, Ислам динен таратуга да зур әһәмият бирә ул. Татарларның бу тармагының көннән-көн батгаклыкка бата баруларына тирәнтен борчыла, аларны аракы зәхмәтеннән коткарып калырга омтыла. Күрәзәчелек, дигәннән, Үри Чаллысы авылында йөргәндә бер урынга

таяк белән төртеп киткән Идрис хафиз: «Монда могҗиза булыр», – дигән. Соңыннан шул урынга чиркәү салына.

Әйдәгез, Хәлфә бабайның үткәндәге вакыйгаларны төгәл чагылдырган шигъри юлларына кабат мөрәҗәгать итик:

«Чаллы кырында кан түгелер,
Сөн ягында мал түгелер.
Муллалар чалмасы белән
Бүрсет (хәзергечә Бирсут) суы бүелер».

Явыз Иванның җәза отрядлары халыкны көчләп чукындыруына, боз тишеп, бәкегә батырып үтерүенә ишарә түгелмени бу?! Капкасына тиклем алтыннан коелган Чаллы ханлыгы рәхимсез рәвештә, вәхшиләрчә юкка чыгарылса да, аның җир-суы, шунда көн күрүче мөселман кавеме исән. «Чаллы кыры сау булыр», – дип безгә шул хакта җиткергән Хәлфә бабайга мең рәхмәтләр!..

Инде Идрис хафизның кайбер тәгъбирләренә килик:

– Өч бурам булыр, соңгысын керәшеннәр бурар.

– Ирләр бүреген хатыннар кияр.

– Кала тавында йортлар корылыр.

– Чаллы белән Бөкәш кушылыр.

Беренче юлны бүгенгегә күчерсәк, Татарстанның мөстәкыйльлегенә янаулар дип кабул итәргә мөмкин. Ирләр бүреген хатыннар киюен яки бөтенләй чишенеп йөрүләрен исә үз күзләребез белән күреп торабыз. Ә менә Калатауда – Чаллы ханлыгы кирмәне уртасында кайчан да булса туристлар өчен отель-кунакханәләр үсеп чыгасына, шәхсән, мин үзем шикләнмим. Ял өчен бакча-парк та булыр. Килгән туристлар Кирмән нигезендәге елап яткан ташларны куллары белән тотып-тотып карарлар. Калатау башына менеп, тирә-якны, Чулмансу елгасы тарафын күзәтерләр, бу яктагы табигатьнең хозурлыгына сокланырлар. Соңгысына килсәк... Тәберде Чаллысы белән Бөкәш авыллары күптән кушылды инде.

*Мөхтәрәм авторыбыз – танылган язучы һәм журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, журналистларның Хөсәен Ямашев, язучыларның Фатих Хөсни исемендәге премияләре лауреаты **Госман Гомәр улы Гомәров**ның 10 гыйнварда гомер бәйрәме – 85 яшь тула. Госман аганы юбилее белән ихластан котлап, аңа саулык-сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары телибез!*

Нәкъ менә әлеге кушылган урында – изгеләр зираты эчендә Хәлфә бабай – Идрис хафиз Зөлмөхәммәд улы истәлегенә куелган һәйкәл тора. Әйткәнемчә, янына гына шифалы чишмә тибә. Халык шуннан дәва ала.

Соңгы сүз. XYII гасыр татар әдәбиятының гүзәл үрнәкләреннән саналган «Дастане Чыңгызнамә» әсәре дә Идрис хафиз Зөлмөхәммәднең иҗат җимешедер, дигән фараз бар. Галимебез М.Әхмәтҗанов та шушы фикерне алга сөрә. Аның белән килешмичә мөмкин түгел.

Үткәннәрне онытмау, олуг шәхесләребезне белү кирәк!..■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

КАҺАРМАН КАТЫЙЛ

Әүвәл заманда пәриләр белән адәмиләр сугыш кылырлар иде. Адәмиләр пәриләрне җиңәр булдылар.

Көннәрдән беркөнне бер пәри падишаһы адәмнәр падишаһы белән сугыш кылды. Адәмне җиңә алмады, бик кайгылы булды.

Пәри падишаһының бер вәзире бар иде. Әйтте:

– И, падишаһым! Адәмиләрдән бер егет алып, тәрбияләми булмас, – диде. Падишаһ:

– Һич белмимен, алыйкмы икән, алсак, кемне алыйк? – диде. Вәзир әйтте:

– Шул фәлән шәһәрдә бер падишаһ бардыр. Аның бер кече углы бар, гаять көчле, ике-өч яшендә генә үзе. Атын аның Каһарман Катыйл дияләр. Әйдә, аны урлап алып кайтыйк, – диде. Падишаһ вәзирнең сүзен хуш күрде.

Беркөн ул угланны урладылар, падишаһка китереп бирделәр. Углан һәрьяктан җитеш, камил иде. Падишаһ сөенде, асрады. «Углан олыгаеп килә, качып китәр», – дип, зинданга салдылар, авыр богаулар белән богаулап куйдылар. «Сугыш вакытына әзер итеп тотарбыз», – диделәр. Яхшы ризыклар китереп ашатырлар иде.

Каһарман Катыйл зинданда өч ел торды, һич адәм күргәне юк, теле-тотышы пәриләрнеке кебек, адәми телен белмәс иде. Йәнә пәриләрдән ишеткән иде: «Урлап китерделәр, шуның өчен илен, ата-анасын сагынып елар», – дип сөйләшкәннәрен. Бервакыт күңелендә әйтте:

– Мин монда торсам, гомерем үткәнче чыгармаслар, – дип уйлады. Беркөн бер карарга килеп, бер кулы белән зинданның почмагын күтәреп карады. Зиндан күтәрелә башлады һәм, ниһаять, тәмам ачылды. Каһарман Катыйл дә, зиндандагы башка тоткыннар да һәммәсе чыгып качты.

Каһарман Катыйл дала буйлап бара, бар нәрсәгә гаҗәпкә калыр, чөнки һич далаяпан күргәне юк иде. Күп җирләр баргач, бер куаклыкка кереп утырды. Бераз вакыттан күрде: шул урынга гаскәр килеп туктады. Гаскәриләр егетне күрделәр. Падишаһ боерды:

– Барыгыз, ул нинди адәм икән, монда алып килегез! – диде. Бер гаскәрине җибәрделәр. Ул гаскәри әйтте:

– Әй, адәм! Ни кеше син? Әйдә, падишаһ катына! – дип, кулыннан өстери башлады. Каһарман аның ни әйткәнен аңламады, кулыннан тотканына ачуы килеп, гаскәринең кылычын тартып алды, башын кисте. Падишаһ йәнә ике-өч кеше җибәрде. Алар йәнә әйттеләр:

– Әй, адәми! Ни кеше син? – диделәр, падишаһ катына барырга өндәделәр. Каһарман аларның телен белмәс, болар Каһарман телен белмәс иделәр. Каһарман торды, сугышты, барысын да җиргә орды.

Ә бу падишаһ исә Каһарманның атасы иде. Угланы урлангач, һичбер хәбәрен

ишеткәне юк иде. Бик күп эзләткәннән соң, гаскәр җыеп: «Бер-бер хәбәрен белмәмме икән», – дип чыккан иде. Улын танымас иде.

Каһарман күп кешеләрне кырды. Падишаһ гаҗәпкә калды:

– Диюме йә пәриме, әллә адәмиме? – дип, үзе якын килде, күрде: углына охшаган адәм икән. Күңелендә: «Улыммы икән әллә?» – дип уйлады. Аңа карап:

– Һай! Ни адәми син? Яраннарымны хәйран иттең, харап кылдың, – диде. Каһарман торды, падишаһны җиргә күтәреп орды, ләкин үтермәде. Падишаһ аваз кылды:

– Һай, егет! Мине һич кеше екканы юк иде, син ектың, юкса, улым Каһарманмы әллә син?! – диде исә, Каһарман аны калдырды.

Падишаһның пәри телен дә белгән бер кешесе бар иде. Ул килеп сөйләшеп карады, сөйләшкән сүзләрен падишаһка тәрҗемә кылды. Падишаһ, сөенеп, углы икәнен белде, үз өенә алып кайтты. Анасы белән күрештеләр, елаштылар. Тора-бара адәм телен өйрәнде.

Йәнә көннәрдән беркөнне падишаһ, сөенеченнән, углын яраннары белән ауга чыгарды.

Япанда йөргән чагында Каһарман бер киек күрде. Өсте төрле-төрле асылташлар белән бизәлгән сыман иде. Каһарман аңа бик кызыкты, ат белән аны куа китте. Яраннары да артыннан калмадылар.



Каһарман туктаса, киек тә туктар иде, Каһарман куаласа, йәнә китәр иде. Шул хәл белән шактый җирләр киттеләр. Атыннан төште, аты бик нык арган иде. Үзе җәяү йөгерде. Киек бер тау өстенә менде. Каһарман кире төште «Инде кумыйм», – дип тик торды, ятып йоклады.

Уянып китсә, күрде: бер егет каршында торыр, күзләреннән яшьләр агар. Каһарман әйтте:

– Кайдан син? – диде. Ул егет сөйләп бирде:

– Исемем Хәрүҗиндер, үзем пәримен. Шәһәремдә үземә никах кылган кызым бар иде, әле үземә алмаган идем, күрекле иде. Башка шәһәрдә бер дию бар иде, килеп, шәһәребезне алды, ул кызны алып китте. Ул дию үз шәһәрендә падишаһтыр, аты Әкүал Нәрдибандыр. Инде безнең шәһәребез аның кул астында калды. Йәнә ул:

– Миңа егерме ел буе һәр елны бер гүзәл кыз биреп торырсың! – дип шарт куйды. Йәнә минем ата-анамны, кызның ата-анасын богаулап, тоткын итеп алып китте. Минем яшәрлегем калмады. Миңа берәү әйтте:

– И, Хәрүҗин! Монда ник торасың? Бар, шул фәлән җирдә бер батыр бар, Каһарман Катыйл диярләр, бик көчледер, сереңне аңа белгерт, эшеңне тәмам кылыр, – диде. Мин шул сәбәптән монда килеп торырмын, – диде.

Каһарман әйтте:

– Ул җир бик еракмы?

Хәрүҗин әйтте:

– Адәми йөресә, илле-алтмыш еллык юлдыр, әмма пәри йөресә, бер сәгатьлектер, – диде. Каһарман атын бер җиргә куйды. Пәри, Каһарманны күтәреп, үз шәһәренә җиткерде.

Шәһәр буйлап икесе килер, күргәннәр әйтер:

– Әй, Хәрүҗин! Бичара адәмне үлемгә ни өчен алып киләсең? Әкүал Нәрдибанны кем, кайчан җиңсен?! Бигрәк кыю, башсыз адәм икән, – дип, үкенер иделәр. Хәрүҗин Каһарманны үз өенә алып кайтты.

Йәнә ул шәһәрдә падишаһның бер вәзире бар иде, Әкүал Нәрдибан аңа әйткән иде: Хәрүҗинне тапсаң, миңа китер, дигән иде. Ул вәзирне чакырдылар. Каһарман әйтте:

– Инде сүз бер булсын: мине богаула, ул Әкүал Нәрдибан шәһәренең тыш ягында куй, үзең кереп әйт: «Хәрүҗинне таптым, үз шәһәрендәдер, сиңа яманлык кылырга бер адәмне алып килгән, аны тотып монда алып калдем», – дигән.

Вәзир белән икесе киттеләр, Нәрдибан шәһәренә җиттеләр. Каһарманны богаулары белән шәһәрнең тыш ягында куйды. Үзе Әкүал Нәрдибан янына керде. Әйтте:

– Хәрүҗинне таптым. Сиңа яманлык кылырга бер адәм табып алып килгән икән, – диде. Әкүал, моны ишеткәч, Хәрүҗин белән никахланган кызга әйтте:

– Әй, кыз! Инде миңа буйсынмыйсың, йөз чигерәсең. Инде менә Хәрүҗин тоткын булган, мин аның башын кисәрмен, син дә миңа буйсынмасаң, минеке булырга теләмәсәң, башыңны кисәрмен, – диде.

Ул арада Каһарман Катыйлне алып керделәр. Каһарман кызны күрде. Кыз әйтте:

– Үлсәм-үләрмен, ләкин, Әкүал залим, синеке булмам! – диде. Әкүал Нәрдибан, бу сүзне ишеткәч, ачуы килеп, «үтерәм!» – дип, кызның чәченнән алды. Каһарман, моны күреп, богавын бер кулы белән тартты, һәммәсе сынып чыкты. Аның куәте шулкадәр иде – бер кулы белән сарайларны егар иде, зынҗыр-богаулар шул арада, бер мизгелдә тузан булыр иде. Әкүал Нәрдибан аңа каршы торды. Әкүал Нәрдибанның җитмеш батман авырлыкта тимер чукмары бар, аны кулына алды, Әкүал Нәрдибанны орды. Моның башы шаңрады, әмма аяк өстендә калды:

– Һай, егет! Тагын бер ор! – диде. Каһарман әйтте:

– Әй, мәлгунь! Бүтән орып тормыйм, – диде. Дию егылды, калтырана-калтырана җан бирде.

Каһарман бөтен чылбырларны өзеп ташлады, барча тоткыннарны коткарды. Барысы да Каһарманның аягына егылдылар, сөенешеп тордылар. Нәрдибанның үлгәнен ишетеп, барча диюләр җыелып килделәр, һөҗүм иттеләр. Каһарман барчасын үтерде.

Йәнә Каһарман «инде кайтырмын» дип тора иде, күрде: шәһәр халкы барчасы шәһәрдән чыгып баралар. Каһарман сорады:

– Ни өчен чыгасыз, ни сәбәптән? – диде.

Шәһәр халкы әйтте:

– Һәр елны шушы вакытта кырык тырнаклы бер коточкыч җанвар диңгездән чыгар, халкыбызны йотар, – диделәр. Каһарман әйтте:

– Аның чыкканын ничек белерсез, – диде.

Әйттеләр:

– Шуннан белербез: су дулкынланыр, каты тавыш чыгар, – диделәр. Каһарман әйтте:

– Сез, курыксагыз, шәһәрдән чыгыгыз, мин калып торыйм, – диде. Шулай дип бер өйдә торып торды.

Шәһәр халкы һәммәсе чыгып китте. Бераз заманнан соң, бер каты тавыш килде, йөрәк ярылырдай куркыныч тавыш иде. Каһарман карап торды, гаҗәпкә калды: суның асты-өскә килде, каты дулкын күтәрелде. Дулкыннар арасыннан бер куркыныч җанвар килеп чыкты, тау сыман, һичнәрсәгә охшамаган. Шәһәргә керде исә, бик куркыныч бер кыяфәт белән барган көйгә сикереп Каһарманга ябышты. Каһарман җанварга ябышты, ләкин һич тибрәтә алмады, шундый куәте белән аны урыннан кузгата алмады. Җанварның кырык тырнагы һәммәсе Каһарманга ябышты, тәненә батып-батып керде. Тырнаклары коточкыч яман иде, нәрсәгә ябыша – шуны ярып төшерер иде. Каһарман, каты кычкырып, «тырнакларын өзәм», – дип, кылычын суырып чыгарды, шундый көч белән орды ки – ул җанварның тырнаклары Каһарманның билендә калды, үзе акырып-бакырып йөгерә-йөгерә суга керде һәм шунда җан бирде..

Читтән күзәтеп торган шәһәр халкы, һәммәсе сөенеп, Каһарманның аягына төште, үз өйләренә керде. «Ничәмә-ничә еллар михнәтләр сөрдек, Аллаһы Тәгалә куәтеңне арттырсын», – дип, күп гозерләр кылдылар, тәгамнәр җийделәр. Йәнә Каһарман кызны алды һәм барча җәмәгатен алып, Хәрүҗин шәһәренә киттеләр, кызны Хәрүҗингә никах кылып бирделәр. Падишаһ үз падишаһлыгына утырды. Каһарманга күп бүләкләр бирделәр.

Аннан соң Каһарман әйтте:

– Мине үз җиремә илтеп ташла, – диде. Хәрүҗин шул заман әйтте:

– Йом күзеңне, үзеңне миңа тапшыр, – диде. Каһарман тапшырды, күзен йомды. Хәрүҗин әйтте:

– Инде ач! – диде. Күзен ачты, үзен атасы шәһәрендә күрде. Атасына хәбәр булды, сөенешеп чыктылар. Каһарман башыннан үткәннәрне сөйләп бирде. Атасы һәм анасы, барча халык хәйран булды. Падишаһ көчле, ә Каһарман исә аннан да көчлерәк иде. Сугышларда гомер кичерделәр, һәммәсендә җиңеп чыктылар.

Моратларга ирештерүче бер һәм бар Аллаһы Тәгаләгә бар мактау-данлауларыбыз булсын!

Казан дәүләт университетының Лобачевский исемендәге
фәнни китапханәсе. Сирәк китаплар бүлеге. Кульъязма №Т-143.

*Язманы **Нәҗип Нәккаш** әзерләде.* ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

Ышанычсыз юлга бер адым

Драма, өч пәрдәдә

Габделгазиз Монасыйпов

Шагыйрь, драматург, прозаик, журналист, сәясәтче, татар милли азатлык хәрәкәтенең күренекле вәкиле Габделгазиз Монасыйповның 1913 елда Казан шәһәрендә («Юл» нәшрияты, «Өмид» басмаханәсе) дөнья күргән бу пьесасын кыскартып тәкъдим итәбез. XX йөз башында татар хатын-кызының җәмгыятьтә һәм гаиләдә хокуксызлыгы проблемасын күтәргән әлеге әсәрнең тулы текстын ***beznenmiras.ru*** *сайтыннан укырга мөмкин.*


ع. مناسيف.

اوشانچسز يولغه

بر آدوم

دراما، ٣ پردەدە.

يول كتابخانەسى نشرياتندن

٧٢ نچى كتاب.

КАЗАНЬ.
Электро-типографія „УМИДЪ"
1913.

Монасыйпов Г. Ышанычсыз юлга бер адым: драма, 3 пәрдәдә. – Казан: «Юл» китапханәсе, 1913 ел

УЙНАУЧЫЛАР

Сәлимә: Шәмси агайның кызы, янчегрәк борынлы, йиңелчә генә кыз, 17ләрдә.

Рокыя: Сорурның апасының кызы, Сәлимәнең дусты, 19ларда.

Нәҗип: зур борынлы, холыксыз һәм тәүфыйксыз гына бай баласы, 26ларда.

Хәзрәт: яшел чапанлы, агара башлаган сакаллы, 55ләрдә.

Карчык: аздырып йөрүче, дөнья күргән бер хатын, 60ларда.

Беренче пәрдә

УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәлимә, Рокыя.

Рокыя *(тиз генә ишеккә карап алып)*. Анаң әйтергә кушмаган иде, ялгыш ычкындырдым. Мин әйтде, дип әйтмәссең. Бүген синең туең. Сине Хәмид байның углы Нәҗипкә бирделәр. Никах укылды инде.

Сәлимә. Нәрсә?

Рокыя. Нәҗиптән яучы килгәч тә, сиңа берәү туй буласын сөйләмәсен, дип, сиңа әллә нинди дару эчертеп сине авыру иткәннәр дә, өйгә җабып куйганнар. Бая монда шаһитлар керәсе булгач, сине бакчага чыгардылар.

Сәлимә *(барып Рокыяның ике иң башыннан бик каты кысып тотып)*. Рокыя, җаным! Ходай өчен әйт, уйнап сөйләмисеңме?

Рокыя. Бу уйный торган урын түгел бит.

Сәлимә *(башын ике кулы арасына алып)*. Ах, харап булдым! Яшьлегем! Якты көнем! *(Диванга ташлана)*. Нәҗипкә. Шул тукмак борынга... Соң, Рокыя, син ник миңа аны алдан әйтмәдең? Синең дустлыгың кайда?

Рокыя. Мин аны үзем дә тенә көн генә ишеттем әле.

Сәлимә. Ах! Харап булдым! Харап иттеләр!... *(Бутылкадагы чәчәкне күреп кулына алып)*. Ах! Матур чәчәк! Мин сине өздем, син сулырсың. Мин дә синең төсле үк: мине дә өзделәр, мин дә сулырмын, корырмын! *(Чәчәкне тотып өстәлгә каплана)*.

Пәрдә төшә.

Икенче пәрдә

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәлимә, хәзрәт.

Сәлимә *(качыбрак)*. Хәзрәт!

Хәзрәт *(борылып)*. Нәрсә? Син кем?

Сәлимә. Мин Хәмид байның углы Нәҗипнең хатыны...

Хәзрәт. Йомышың ни?

Сәлимә. Хәзрәт! Иремнең холыксызлыгына бер дә тәкать тотып булмый. Үзе тагын көн дә эчеп, исереп кайта. Кыйный-кыйный күгәртмәгән йиремне калдырмады инде.

Хәзрәт *(Сәлимане туктатып)*. Җә, җитәр, күп такылдама! Ир булсын да, кыйнамасын да, имеш. Үзеңнең килешмәгән йирләрең бардыр. Югыйсә, кыйнамас иде.

Сәлимә. Хәзрәт! Минем бер гаебем дә юк. Карышмыйм, кушканын тыңлыйм. Алай булса да, кыйный. Чыдар хәлем калмады инде, хәзрәт! Ничек тә булса аерттырыңыз! Аерылмыйча хәлем юк...

Хәзрәт. Күп сөйләнмә, дим мин сиңа... Синең шикелле хатыннарның такылдавыкларын бик күп ишеткән инде мин. Чиртергә ярамый – хәзер хәзрәт. Бер сүз әйтергә ярамый – хәзер хәзрәт. Хәзрәт ишегенә килгәнче, иреңнең аяк астында ауна! Ирең дә кыйнамас, үзең дә яхшы торырсың.

Сәлимә *(хәзрәт китә башлагач, җылап)*. Хәзрәт! Шәфкать итеңез инде миңа азрак!...

Хәзрәт. Синең сафсаталарыңны тыңлап, аштан калыр хәл юк әле монда (китә).

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәлимә, карчык.

Карчык *(Сәлимәнең янына килеп).* Әстәгъфирулла! Кызым ни булды сиңа? Гакылдан шаштыңмы? *(Сәлимә, карчыкка карап, күзеннән яшьләрен сөртә, эндәшми).* Шундый кеше күп йөри торган йирдә, урамда егълап утырасың. Нинди кайгың бар ул чаклы?

Сәлимә. Әй, абыстай, сорама инде.

Карчык. Ул ни дигән сүз тагын? Берәүнең егълаганын күр дә, хәлен сорама, имеш... Китап алай кушмый бит кем... кем, чибәр кыз. Кайгылы кешеләрнең кайгыларын уртаклашырга, аларның кайгыларын таркатырга тырышырга куша.

Сәлимә. Әй, абыстай! Китап кушканча гына йөрү кайда соң ул безгә? Кулыңнан килсә, ирекле булсаң, бик китапча йөрер идең дә бит... Ир-атлы ирең үзе көне-төне эчеп-исереп йөргәч, үзе Алласын оныткан бәндә булгач, сиңа китапча йөрергә ирек кайда ул?

[...]

Сәлимә. Соң, абыстай, алай итеп качып чыгып кайда бармак кирәк? Никахлы иреңне ташлап ничек хәер күрерсең? Ничек тамагыңны туйдырырсың?

Карчык. Әле теләнчелеккә чыкмадым. Бик әйбәт тордым. Бай хатыннарыннан да артыграк кадер-хөрмәттә булдым. Матур булсаң, дөньяда теләгәнчә торырга була.

Сәлимә. Мин аңлый алмыйм, абыстай. Ничек ул теләгәнчә торырга? Ирсез торып буламыни?

Карчык. Ирсез, дип, нишләп ирсез булсын? Дөньяда ир беткәнмени? Бер ир урынына биш белән торырсың. Ирләрнең аларның гакыллары юк... Синең шикелле матурларны күрсәләр, малларын да, җаннарын да аямыйлар.

Сәлимә *(карчыкны бүлеп).* Абыстай, нәрсә сөйлисең? Әллә миңа никахлы ир өстенә ир тотарга кушасыңмы?

Карчык. Нишләп син ир өстеннән ир тотасың? Анлар синең никахлы ирең булмыйлар ич, сөяркәң генә булалар... Аннан ары икенче шәһәрдә синең танышларың булмый, берәү дә синең ир хатыны икәнеңне белми. Исемеңне генә башкартасың да, икенче исем белән рәхәтләнеп торасың.

Сәлимә *(күзләрен зурайтып, карчыкка ышанычсыз карау белә карап).* Әллә син миңа сатлык кыз булырга кушасыңмы?

Карчык. И-и, кызым... Аның сатлык кыз дигән аты гына бар. Сатлык кызлар анлар шәһәреңдәге иң беренче бай хатыннарыннан да рәхәтрәк торалар... Кул талдырып эшләмиләр, ир сүгеше ишетмиләр... Гомер буе кунак булып сыйланалар да яталар.

Сәлимә. Соң аның ояты...

Карчык *(Сәлимәне бүлеп).* Аның нәрсә ояты булсын? Кызлар янына барган кеше оят тикшерергә бармый ул... Анда барып ирек ачарга, синең шикелле матур кызлар белән уйнап, көлеп, сөйләшеп, сыланышып утырырга бара.

Сәлимә. Шулай да бик әшәке, бик күңелсез инде ул.

Карчык. Ир хатынының тормышы күңелле дип беләсеңме? Көне-төне эшләү, аның өстенә кыен, орыш... Ә сатлык кызларның аларның бер эшләре дә юк, аларга кул тидереп сугучы, тел тидереп бер авыр сүз әйтүче юк, ашау-эчү яхшы, кием-салым шәп, көн дә кунак, көн дә уен-көлке, гармун... җырлау...

Сәлимә. Ярый инде, абыстай, күңелле булса күңелледер. Синең белән сөйләшеп тора-тора вакытның үткәнен сизми калдым. Көн кич булып бара, мин кайтыйм инде.

Пәрдә төшә.

Өченче пәрдә
ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ
Сәлимә, Нәҗип.

Сәлимә. Кайда барасың инде тагын кич булгач?

Нәҗип. Теләгән йиремә барам. Әллә кайда барганымны да хатынга әйтеп китимме? *(Борылып килеп)*. Беләсең киләме?

Сәлимә. Бу килбәтең белән торганчы, ятып йоклаганың мең өлеш артык булыр иде.

Нәҗип. Синең шикелле шыксыз, булдыксыз берсенең янында мин ник ятыйм? Син куштан түгел, җырлый белмисең, үзең ачучан...

Сәлимә. Соң кем куштан?

Нәҗип. Беләсең киләмени? Беләсең килсә, әйтим алайса.

Сәлимә. Җә, әйт!

Нәҗип. Нәфисә – куштан, Камилә – куштан... *(Чыгып китә башлый)*. Куштаннар күп анда... Акчаң гына булсын.

Сәлимә. Нәрсә дидең әле син? *(Ишекгә йөгереп барып, ишек тоткасын тота)*.

Нәҗип. Беләсең килсә, артымнан бар! *(Ишекгә барып, Сәлимәне төртеп чыкмакчы була)*.

Сәлимә. Ах, залим! Йибәрмим мин сине...

Нәҗип. Йибәрмисең? Бер дә йибәрмисеңме?

Сәлимә. Син әллә кайда... Әллә кемнәр янына китмәкче буласың, син... Син миңа хыянәт итәсең. Мин йибәрмим.

Нәҗип. Соң синең шул янчек борыныңа карап өйдә утырыйммыни?

Сәлимә. Мине яратмасаң, элек аерып йибәр! Аннан соң барырсың.

Нәҗип. Кит! Йибәр ишекнең тоткасын! Мин әле сине аерудан элек кулларыңны каерырмын. *(Сәлимәнең кулларын ишектән ычкындырмакчы була)*.

Сәлимә *(барлык көче белән тырышып)*. Йибәрмим... Аер, элек!

Нәҗип. Чир итәрмен әле мин сине аерганчы. *(Сәлимәнең кулын ычкындырып, ишекне ача)*.

Сәлимә. Залим! Китмә! *(Нәҗипнең җиңеннән барып тота)*.

Нәҗип *(Сәлимәне бик каты төртеп йибәреп)*. Кит моннан, мәлгун! *(Чыгып китә)*. *(Сәлимә идән уртасына кадәр килеп егыла)*.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ
Сәлимә, Рокыя.

Рокыя. Тенә көн Гөлҗиһан җиңгиләргә барган идем. Шунда әби очрады да: «Ни хәлдә торасың, кызым?» – дип, миннән хәл сораша башлады. Мин, бик яхшы торабыз, дигәч, яхшы булса, бик яхшы, яманнан Алла сакласын, ди, менә Шәмси кызы Сәлимә, ди, ире белән ызгышып тора икән, ди, ире эчеп-исереп әллә нинди хатыннар, марҗалар...

Сәлимә *(белешмичә)*. Марҗалар...

Рокыя. Ийе, марҗалар белән йөри икән, ди. Инде кибетендә малы да аз калган. Сәүдә эшләре чуалган, дигән була. Юк сүздер ул, әби, дидем...

Сәлимә *(белешмичә)*. Кара син аны, ә?

Рокыя. Тукта әле, бетмәде. Юк сүздер, дигәч, әйтә, юк сүз булса, бик ярар иде дә, бөтенләй үк юк түгел, ди. Сәлимә муллага барып зарланган икән, мулла үгетләп кайтарган, ди...

Сәлимә *(бераз исен җыеп)*. Җә, тагын да.

Рокыя. Минем ишеткәнем шул гына. Аннан аргысы булса, үзеңез беләә торгансыздыр тагын.

Сәлимә *(төзәтенеп, үзгәргәнен сиздермәскә тырышып)*. Халык дигәнең сөйли, ә? Нинди ялганнар төзеп чыгарганнар бит.

Рокыя. Халыкка сөйләргә сүз генә булсын инде аңар. Ул аның, раст ялганын тикшереп тормый.

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Сәлимә ялгыз.

Сәлимә. Минем кыеннан башым чыкмый, күземнән яшем кипми, күңлемнән хәсрәт китми... Аның өстенә, тагын әчүе, тукмак шикелле борынын кызартып, бутала-бутала, идән буйлап йөри-йөри сүгенүләре... Хыянәте... Моңарчы мин генә белми йөргәнмен аның ниләр эшләп йөргәнен. Миннән башка кешеләр барысы да белгәннәр, ах! Җитмәсә, тагын маржалар белән... *(Диванга утыра)*. Соң мин ник бу кадәрле бәхетсез? Мондый бәхетсезлектә булырлык ниләр эшләдем? Ник минем тормышым башка кешеләрнеке төсле кызыклы түгел? Кызыксыз тормыш белән торганчы, мин ник үлмим?.. Юк! Мин үлмәкче булсам да, миңа үлү мөмкин түгел. Газраил үзе дә миннән кача... Бая теге бүлмәдә, Рокыя килер алдыннан, ак серкә эчеп үлмәкче булдым. Стакан белән инде генә агызымга каптым дигәндә, Рокыяның тавышыннан сискәнеп киттем дә, ул да кулымнан төшеп түгелде. Ахрысы, бөтен дөньядагы нәрсәләрнең барысы да миннән кача, миңа ярдәм итүдән чиркана торганнардыр... Соң хәзер мин кемнән хәлемгә ярдәм сорыйм? *(Уйлана)*. Әллә карчыкның ярдәме белән качыйм микән? Ул карчык миңа ярдәм итәр микән? Ирдә торып бәхетемне сынап карадым, булмады. Әллә инде шул юлда бәхет эзләп карыйм микән?.. *(Торып, уйланып йөри)*. Бәлки анда аз гына рәхәтрәк торыр идем. Әшәке сүзләр ишетмәс идем. *(Барып диваннан шәл ала да, бераз уйлап торып, шәлне җиргә ташлый)*. Юк! Юк! Булмый! Ничек итеп «сатлык кыз» исемен күтәрергә кирәк? Ничек итеп әллә нинди ят кешеләр белән шаярырга кирәк? Ул әшәке эшкә каберендә яткан атамның рухы рәнҗер. Ул, үги ананың сүзе белән миңа белдермәс өчен әллә нинди хәйләләр ясап, мине шушы кабахәткә сатты. *(Йирдән шәлне алып тузанын кага)*. Әллә китим дә микән? Нәҗип эзләп тапмас микән? Карчык, үлгән итеп күрсәтербез дә эзләмәсләр, дигән иде, шулай булыр микән? Ни эшлим икән? *(Уйлап тора да җылый)*. Ни булса шул булыр, китәм! *(Шәлен бөркәнә)*. Мине Нәҗипкә сатып, минем егълап барганнарыма илтифат итмичә, бәлки минем мәхәббәттә икәнемә куанган үги ана, мине үлде, дип уйлап тагын да куансын! Әтидән калган барлы-юклы мирастан миңа өлеш чыгарасы булмаганына куанып, теләгәнчә бәйрәм итсен! «Мине тәүфыйктан яздырдың, эштән чыгардың», – дип, мине орышкан, мине җәберләп, миңа якты көн күрсәтмәгән ир дә, кайда, кайда барасың, дип сораучыдан котылсын! Нәфисәләре белән бәйрәм итсен! *(Кызу-кызу гына ишек янына бара да уйланып тора)*. Мин... Мин ни эшлим? Никахлы ирдән качам? *(Борылып)*. Юк! Булмый!.. *(Бераз торып)*. Аның хыянәте, аның хыянәтен үз агызы белән икърар итүе ир хакын калдырдымыни?.. Китәм... *(Бик кызу ишеккә бара да ишек яңагына башын куеп, уйлап тора. Бераздан, бар көчен бергә җыеп, башын артка ташлап, чыгып китә)*.

Пәрдә төшә.

*Текстны басмага **Гүзәл Төхфәтова** әзерләде.* ■

«ТУКАЕВТАН СОҢ БЕРЕНЧЕ ШАГЫЙРЕМЕЗ...»

(Кәшаф Патии-Зимничәвинең тормыш юлы һәм иҗади эшчәнлеге)

Әлеге шәхес һәм аның иҗаты турында журналыбызның берничә санында кыскача гына язган идек[1], шулардан галимә Әнисә Алиеваның мәкаләсе «Тукай энциклопедиясе» рубрикасында басылды[2]. «Ватаным Татарстан» газетасының 2000 елгы 11 август санында журналист Марсель Әскәровның Кәшаф Патии кызы Рауза Патиева истәлекләре нигезендә язылган мәкаләсе басылган[3].

Әмма аннан М.Әскәровның, шагыйрьнең кызы һәм хәтта тарихчы галим Рәфыйк Нәфыйковның да Кәшшаф Патииның басылып чыккан шигырьләре, китаплары белән таныш түгел икәнлеге аңлашыла. 2004 елда дөнья күргән «Татар шигърияте» исемле китапның авторлары М.Әскәров мәкаләсе белән таныш түгелләр булса кирәк, алар К.Патии шигырьләре һәм аның турында кыска гына мәгълүмат биреп: «Зимничә авылында туып үскән бу шагыйрьнең шәхесен һәм тормыш юлын ачыкларлык башка төр мәгълүматка тап булганыбыз юк әлегә», – дип яза[4]. Узган ел җәй аенда Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районына сәфәребез вакытында, әлеге мөхтәрәм шәхес турында аның авылдашы Иршат Сафинның «Старокулаткинский след на земле Татарстана» исемле китабыннан саллы гына мәкаләгә юлыктык[5]. Бу һәм алда искә алынган әдәбият нигезендә, педагог,

Кәшшаф Патии-Зимничәви

[1] Кәшшаф Патии // Безнең мирас. – 2016. – №8. – Б.40-41.
[2] Алиева Ә. Патии Кәшшаф // Безнең мирас. – 2014. – №4; Шушы ук мәкалә Габдулла Тукая энциклопедиясендә дә басылды (2016 ел, Б.14).
[3] Әскәров М. Патиевлар // Ватаным Татарстан. – 2000. – 11 август.
[4] Татар шигърияте: XX гасыр башы. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б.197.
[5] Сафин И. «Старокулаткинский» след на земле Татарстана. – Старая Кулатка, 2016. – С.13-15.

мулла, шагыйрь, Габдулла Тукайның дусты Кәшшаф Патии (Кәшшаф Зимничәви) – Габделкәшшаф Мөхәммәдшәриф улы Патиевның (1884-1971) тормыш юлы һәм иҗади эшчәнлеге турында мөмкин булганча тулы мәгълүмат бирергә тырышырбыз.

Кәшшаф Патии Саратов губернасы Хвалынск өязенең (хәзер Иске Кулаткы районы) Яңа Зимничә авылында туган. Аның ата-бабалары элек-электән Яңа Зимничәнең беренче мәхәллә мәчете имамнары булган. Шул чордагы гадәт буенча, Кәшшаф та башлангыч белемне әтисе Шәрәф мулладан ала, ә аннары шактый вакыт данлыклы ишан Хәбибулла Хансөяров мәдрәсәсендә укый. Үсеп җиткән яшь егетне татарның рухи-мәдәни мәркәзе Казан үзенә тарта һәм ул укуын «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә дәвам итә. Кәшшаф Патии анда 1901 елда оешкан, татар халкының азатлыгы, милли уянуы өчен көрәшә торган яшерен оешма – «Иттихад»ның әгъзасы була. 1902-1905 елларда мәдрәсәдә Фатих Әмирхан оештырган әдәби түгәрәктә актив катнаша. Шигъри күңелле егетнең әдәби кичәләрдә гаять оста итеп мандолинада уйнавы да мәгълүм. Кәшшафның тәүге шигырьләре Җаек каласында чыга торган «Фикер», Оренбургтагы «Шура» журналларында басыла. 1906 елда исә беренче шигырьләр җыентыгы – «Тугыз чәчәк» дөнья күрә, соңрак ул үзен драматургия өлкәсендә дә сынап карый.

Хәбибулла ишанның мөриде, суфи Мөхәммәдшәриф хәзрәт улы Кәшшафның шәһәр шаукымы белән мавыгуына каршы булып, шигъри җанлы егетне авылга кайтарып, аңа ата-бабалары имамлык иткән мәчетне тапшырырга тели. Өстәвенә революция идеяләре белән мавыккан Кәшшаф турында мәдрәсә мөгаллимнәре Мөхәммәтшәриф хәзрәткә: «Улың монда шикле кешеләр белән аралаша, муллалыкка укучы шәкертләр белән йөрми. Дәресләр калдыра», – дип хат яза. Әтисе мәдрәсәдә укырга акча җибәрми башлагач, Кәшшаф Уфага юл тота, анда, Диния нәзарәтендә имтихан тапшырып, указ ала һәм 1907 елдан Яңа Зимничә авылының беренче җамигъ мәчетендә әтисенә ярдәмче имам булып эшли башлый.

Марсель Әскәров, Рауза апа Патиева истәлеге нигезендә, шагыйрьнең өйләнү тарихын менә ничек яза: «Зимничәдән аңа ниндидер йомыш белән Новосибирскига барырга туры килә. Биредә ул үзенең булачак хатыны – Зәйнәп туташ гаиләсенә аз гына хакка фатирга керә. Ике арада мәхәббәт туып, нәтиҗәдә, ата-ананың хәер-фатыйхасын алып, Кәшшаф белән Зәйнәп Зимничәгә кайтып китә».

Казан каласында җәдиди идеяләр белән сугарылган егет авылга кайтып кул кушырып утырмый, өяз түрәләренең бусагасын таптый-таптый, яңа ысул белән укытыла торган мәктәп ачуга ирешә. Өяз үзәге булган Хвалынск һәм күрше-тирә авыллардан алдынгы карашлы мөгаллимнәр чакырта, кадими мәдрәсә өчен ят булган уку әсбаплары – язу тактасы, карта, басма китап һәм дәфтәрләр сатып ала. Марсель Әскәровның язуынча, аның бу эшенә Зимничә һәм якын-тирәдәге авыл муллалары каршы төшә: «Ул сезнең барыгызны да чукындырырга тели, ул урысларга сатылган!» – дип, халыкны котырталар. Бер төркем халык «шайтан коткысына бирелгән» җәдитче хәзрәтне, төнлә факеллар яндырып, үтерергә дип эзләп йөри, әмма аны якын дусты үзендә яшереп саклап кала. Кәшшаф туган авылында җәдиди мәктәп ачса да, анда озак укытмый, авылдашы, фикердәше Вафа Бәхтияров кебек үк, аны да Казан каласы үзенә җәлеп итә. Шулай итеп, яшь хәзрәт 1909 елда имамлык, мөгаллимлек хезмәтен калдырып, яңадан татар дөньясының башкаласына юл тота.

Шигърияткә тартылган егет, якташлары Вафа Бәхтияров һәм Хөсәен Әбүзәровлар ярдәмендә, Габдулла Тукай белән таныша, аның даирәсендәге кешеләрнең берсенә әйләнә. Тукай белән танышлык Кәшшафны яңа шигырьләр язуга рухландыра. Ә.Алиева язуынча, «Әлгасрелҗәдид»нең 1907 елгы 1 нче санында басылган «Әлгасрелҗәдид журналына» дип исемләнгән шигырендә К.Патии журналны һәрьяклап мактый һәм

аның даими авторы Габдулла Тукайны: «Ул тарафта аның кеби шагыйрь юктыр, һәр шигыре укучыны уйландыра», – дип искә ала.

Кәшшаф Патииның хатыны – Зәйнәп ханым

Кәшшаф Патииның каләм тибрәтү белән мавыккан вакыты Казанда яшәгән елларына туры килә. Биредә ул «Тугыз чәчәк» (1906, 1912), «Кәшшаф Патии шигырьләре» (1910), «К.Зимничәви шигырьләре» (1915), «Әшгарь» (1915) исемле җыентыкларын бастырырга өлгерә. 1910 елгы китабы басылып чыгу уңаеннан, Әстерхандагы «Идел» газетасы, яшь шагыйрьне мактап һәм иҗади рух өстәргә теләпме, әллә инде җыентыкны үтемле товар итү нияте беләнме, гаять яхшы игълан-реклама бастыра. Анда: «Гүзәл, милли вә тәэсирле шигырьләр. Кәшшаф Патии җәнаплары ошбу мәҗмугадагы шигырьләре илә Г.Тукаевтан соң беренче шагыйремез, диюгә лаеклыдыр», – дип язылган.

Кәшшаф Казан университетының медицина бүлегендә иреккле тыңлаучы булып та йөри, табиблык фәне белән мавыга. Шул сәбәпле булса кирәк, дуслары аны Габдулла Тукайның сәламәтлек буенча «подшефные» итеп билгели. Ул рухи остазының бакый дөньяга күчүен авыр кичерә. «Әшгарь» исемле җыентыгында (1915) Кәшшаф Патииның шагыйрь үлеменнән соң язылган «Тукайга» исемле шигыре дә бар. Ул анда:

Бәләнд[6] рухың, бәләнд аң диңгезендә,
Тирән эз калды ул узган эзендә.
Гали максатка юл ачкыч сүзеңдә,
Барыр мәңге, калыр үз телемездә», – дип, Тукай шигъриятенең мәңгелегенә ишарәли.

Шигърият белән мавыгуы, вәгазьләрендә, халык белән аралашканда социалистик юнәлештәге фикер-карашлары һәм үз-үзен артык «дөньяви» тотышы – кепка, тар ыштан, пиджак, эшләпә кигәне өчен «кызыл мулла» дип аталган Кәшшаф хәзрәт, мөгаен, соңыннан революцион идеяләрдән йөз чөергән булса кирәк. Аеруча аның гаиләсен – этисе Шәриф мулла һәм әнисен, кулак, дип, бар мал-мөлкәтләрен талап, туган һәм гомер иткән Яңа Зимничәдән сөргәннән соң, К.Патииның фикер-мәсләге тамырдан үзгәрә. Ә үзен исә «кызара башлаган» эшчәнлеге һәм элек мөгаллим булып эшләве генә коткарып кала.

1921 ел башында Кәшшаф хатыны белән татар укытучыларыннан торган делегация составында совет хакимияте урнаштырырга һәм тугандаш төрки халыкларга аң-гыйлем бирергә Урта Азиягә юл тота. Патиевлар гаиләсе 1921-1927 елларда Хива шәһәрендә яши, биредә ул хатыны Зәйнәп белән педагогия техникумы ачуда катнаша. Соңрак Патиевлар Ташкент, Әндиҗән шәһәрләрендә яши, балалар укыта. 1933-1955 еллардагы

---
[6] Бәләнд – бөек.

тормышлары исә Каракалпакстан белән бәйле. Бөек Ватан сугышы башлангач, аны, улы Иркен белән, Фирганә каналы төзелешенә – «Фархадстрой»га җибәрәләр. Биредә алар агитпунктта эшли – газета чыгара, төрле плакат һәм лозунглар әзерли.

Сугыштан соң, Кәшшаф Патиев «Сталин» күмәк хуҗалыгында бакчачы, агроном, бригадир һәм рәис булып эшли. Җиләк-җимеш, яшелчәнең яңа сортларын булдыру һәм Урта Азиядәге халык өчен ят булган һөнәр – умартачылык белән шөгыльләнә.

Кәшшаф Патии, мулла нәселеннән булганлыктан һәм берничә ел бу хезмәтне дә башкарганы өчен кулга алынып, сөргенгә озатуларыннан куркып яши, иҗат белән шөгыльләнеп, үзенең исемен танытудан да читләшә, башкалар кебек совет илен мактап, «кызыл шигырьләр» дә язмый. Дөрес, үз гомерендә төрле һөнәр – мулла, мөгаллим, шагыйрь, журналист, табиб, колхоз рәисе, бригадир, агроном, бакчачы, умартачы хезмәтен башкарган Кәшшаф Патии картлык көннәрендә, 1960 нчы елларда гына яшь вакыттагы шөгыле –шигырь язу белән мавыгып карый. Әмма алар инде элекке кебек табигый түгел, ә сәяси һәм ясалма патриотизм рухы белән сугарылган була.

К.Патии балаларына, таныш-белешләренә Казан шәһәре һәм бөек шагыйрь Габдулла Тукай турында бик яратып сөйли. Гомеренең азагына кадәр Урта Азиядә яшәү сәбәпле, аның бу истәлекләре язып алынмый һәм китапларда басылмый кала.

ТР Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә Фәридә Гаффарова коллекциясе белән танышып утырганда, Кәшшаф Патииның «Тугыз чәчәк» исемле шигырьләр җыентыгына юлыктык. Игътибарыгызга шуннан бер шигырьне тәкъдим итәбез. Анда халкыбызның (автор «татарстан» дип бирә) бәхәсләшү-тартышу һәм нәфескә иярү кебек начар гадәтләре тәнкыйтьләнә. Кызганыч, әлеге шигырьдә тасвир кылынган кимчелекләрнең үткән тарихыбызда һәм хәзерге заманда мисаллары шактый.

ДӨНЬЯ

Әй, адәми бунча ихлас куймагыл дөньяга,
Бел, бу дөнья охшагандыр вәйран улмыш бинага.
Вәйран улган бина ничек һәр заман тузган булыр,
Һәм бу дөнья вәши[7] кеби галәмгә фетнә булыр.
Бән бөтенләй әмер итмим дөньяны тәрәк итмәгә,
Бәлки син һәм сәүдә иткел ахирәт касд итмәгә.
Ягъни бән сиңа әйтәм: нәфсеңне күтәрмәгел,
Нәфсең өчен син булышып, нәфесеңә иярмәгел.
Нәфсең үзеңә күренмәс, хәйләкәр бернәрсә ул,
Сиңа хәйлә итәр исә, аягыңнан егар ул.
Нәфсең артыннан иярсәң, һәлак итәр, юк шигем,
Дәхи хурлыкка төшерә, тәҗрибәдән белгәнем.
Бел, җәдәл шаигътер[8] татарстан эчендә,
Ләззәт алыр шул җәдәлдән куәт илә, көч илә.
Ләззәт алма син болардан, хур итәр болар сине,
Йә Илаһи, ярлыкагыл, гөнаһымны син бары.

Басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

[7] Сүз йөртүче, ягъни ара бозып йөрүче. – ***Авт. иск.***
[8] Җәдәл шаигъ – бәхәсләшү, тартышуның халык арасында таралуы.

Бөек Ватан сугышында байтак татар язучылары катнашты. Алар, мылтык алып, дошманга каршы сугышты, фронт газеталарында хезмәт итте, ялкынлы сүзләре белән сугышчыларны җиңүгә рухландырды. Гомерләрен илебез азатлыгы өчен биргән бу язучы-фронтовиклар һаман да халык күңелендә. Шулар арасында якташым, язучы, танкист, педагог Хәмит Кави да бар. Ул 1906 елны Чуаштанның хәзерге Козловка районына кергән Әлмән авылында мулла гаиләсендә туа. Әтисе Сәлим һәм әнисе Закирә абыстай авыл балаларына белем бирә.

Язучы, танкист, укытучы

Хәмит Кави 1920-1926 елларда Казанда педагогия техникумында, аннары, читтән торып. Көнчыгыш педагогия институтының биология факультетында (1926-1931) белем ала. 1926 елдан бирле Казандагы урта мәктәпләрдә, мех техникумында биология һәм география фәннәре укыта.

Х.Кави студент чагыннан сәяхәт итә, үзенең күргәннәре турында фәнни-популяр характердагы очерклар, маҗаралы хикәя-повестьлар яза.

1929-1939 еллар арасында аның унлап китабы басылып чыга. Шундыйлардан «Кавказ таулары аркылы җәяү» (1930), «Идел буенда йөрү юллары», «Боз диңгезенә таба» (1932), «Кузбасска сәяхәт» (1934), «Сәяхәт» (1939) исемле китаплары үсмерләр һәм мәктәп укучылары арасында популярлык казана. Казан-Мәскәү чаңгы сәяхәте оештырып, яшь буынга тәрбия бирүдәге зур хезмәте өчен, Хәмит Кавига 1939 елда Мәскәүдә Тышкы сәүдә халык комиссары имзасы куелган исемле кул сәгате бүләк ителә. Шул елны беренче балалары Илдар, ә 1941 елны Илгиз туа. Бөек Ватан сугышы башлангач, сентябрь аенда Хәмит Кави фронтка китә. «Исән-сау кайтам, балаларыбыз күп булып, аларга «ил»дән башланган исемнәр кушарбыз», – ди ул хәләле Әтнә кызы Мәрьямгә.

Хәмит Кави Бөек Ватан сугышында, танк командиры буларак, Идел буеннан илнең Көнбатыш чикләренә кадәр юл уза. 1944 елның 15 июнендә Көнбатыш Украинада урнашкан Волынск өлкәсенең Дружкополь дигән урынында, генерал-лейтенант Ватутин армиясе часте сугышчылары ял иткән вакытта, бандерачылар һөҗүм башлый. Өлкән лейтенант Хәмит Кавиның танкы аларга каршы чыга. Бандерачылар танкны яндыралар. Танк командиры Хәмит Кавиев көрәштәшләрен (алар Актаныштан була) аскы люктан чыгарып җибәрә, тик үзе чыгарга өлгерми. Танк экипажы гомерен саклап, терелəй янып үлгән каһарман Дружкопольдә туганнар каберлегендә җирләнә. «Әтигә быел 111 яшь булыр иде, гаиләм, улларым Рәшит, Шамил белән билгеләп уздык, оныгым Әмир – армия хезмәтендә», – ди геология фәннәре кандидаты Илгиз Кавиев.

Равилә Мөбарәкшина ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

Сулдан уңга: Мирсәй Әмир, шагыйрь Әбүзәр Түрәй, шагыйрь-герой Хәйретдин Мөҗәй. Урта Азия хәрби округы. 1931 ел

Мирсәй Әмир һәм ЛОКАФ

1929-1931 елларда М.Әмир Кызыл Армия сафында була: башта полк мәктәбендә укый, соңрак Казан гарнизонында чыга торган Идел буе хәрби округының «Кызылармеец» газетасында красноармеец-журналист булып хезмәт итә, газетаның күчмә редакциясе белән Урта Азиягә барып, татар-башкорт солдатлары арасында ЛОКАФның (Кызыл Армия һәм Кызыл Флот язучылары берләшмәсе) татар әдәбияты түгәрәкләрен оештыра, армия тормышын яктырткан мәкаләләр яза. Армия хезмәте аның иҗатына яңа темалар алып килә. 1930-1933 еллар арасында әдип тыныч чордагы хәрби тормыш күренешләрен, ил сагына чакырылган авыл егетләренең сугыш һөнәренә өйрәнүләрен кызыклы, көлкеле ситуацияләргә куеп тасвирлаган «Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре» исемле повестен һәм «Аяк», «Сугыш сере», «Клим малайлары» кебек хикәяләрен иҗат итә. М.Әмир хәрби темага «Командир» («Карамалы егете») исемле зур роман язарга да керешә, ләкин әсәр тәмамланмый кала (беренче кисәге 1934 елда аерым китап булып чыга).

Армиядән соң, 1931-32 елларда М.Әмир ТатЛОКАФның идарә секретаре булып эшли.

ТАТАР-БАШКРТ СУГЫШЧЫЛАРЫ, ҮЗ ӘДӘБИЯТЫГЫЗНЫ ТӨЗЕГЕЗ «КЗЫЛ ӘРМИЕС» ГӘЗИТЕНЕҢ КҮЧМӘ РЕДАКЦИЯСЕ ТАТАР ЧӘСЛӘРЕНДӘ ӘДӘБИЯТ ТҮГӘРӘКЛӘРЕ ТӨЗИ*

Казанда чыга торган «Кзыл әрмиес» гәзите янында Кзыл Әрмия вә флот язучылары әдәбият берләшмәсенең татар секциясе төзелде.

Бу секцияне төзүнең әһәмияте бик зур.

Татар эшчесе һәм кристиәне революциядә рус иптәшләр белән бергә үзенә тормыш өчен, азат хезмәт, мәдәният өчен хокук алды.

Хәзер инде, туры Ленин милли сәясәте белән татар кзыл армиесе промфинплан өчен җиң сызганып көрәшә, иҗади салахият (сәләт) күрсәтә, укуда югары темплар белән бара.

Демобилизация ителгән татар кзыл армиесе, әгәр ул кристиән булса — авыл хуҗалыгын социализм нигезендә яңадан коруда актив рәүштә катнаша, әгәр ул эшче булса — производствоны алга җибәрү өчен көрәшә.

Мәдәни үсү киңәя бара, татар пролетар әдәбияты үсә һәм көчәя. Хәзер күп кенә татар хәрби язучылары бар (Кави Нәҗми, Шамил Госман вә башкалар). Аларның язган әсәрләре гражданнар сугышыннан алган материалларга бай һөм киң укучылар гаммәсе эчендә зур игътибар алып торалар.

Ләкин, шулай булса да, Кызыл Әрмия вә флот язучылары әдәбият берләшмәсенең (ЛОКАФ) татар секциясе декларациясендә шушы сүзләр бар:

— Идел, Урал, Перекоп вә башка җирләрдә гражданнар сугышындагы каһарманлыкларны күрсәтә торган тарихи материалларны эченә алган әдәби әсәрләр безне канәгатьләндерми. Хосусан, хәрби тәгълимнең (укытуның) ударниклык темплары күрсәтелгән, алга таба яңа галәбәләргә (җиңүләргә) баручы частьләрне, ударник кызылармеецларны күрсәтә торган әдәби әсәрләр әле бездә юк диярлек.

Декларациянең бу сүзләре, әлбәттә, дөрес. Милли чәсләрнең кзыл армиесләре сугышчылык хәзерлеген күтәрүгә булышлык бирә торган әдәби әсәрләргә мохтаҗ.

Шул мөнәсәбәт белән, ЛОКАФның татар секциясе өстенә зур бурычлар йөкләнә. Ул мәмләкәт мөдәфәгәсе (оборонасы) өчен әдәбият сүзен мобилизоват итәргә, Кзыл Әрмиянең әдәбият фронты кадрларын әзерләргә тиеш.

Хәзер 1-нче полкта, татар-башкрт хәрби мәктәбендә, әдәбият түгәрәкләре төзелде. Бу түгәрәкләр эченә әдәбият эшенә салахиятлы актив иптәшләр керәләр. Алар гәзитләрдә әдәбият бүлемләре төзиләр, поход җырлары җыялар, шигырьләр, хикәяләр вә башка әдәби әсәрләр язалар. Бу түгәрәкләрдә ЛОКАФның татар секциясе беркетеп куйган әгъзалар бар.

Бу әле татар секциясенең беренче адымлары гына. «Кзыл әрмиес» гәзите аркылы секция, татар-башкрт бүлемләре булган чәсләрдә язучыларны һәм әдәбият фронтында эшләргә теләүчеләрне оештыра.

«Кзыл әрмиес» Урта Азиа Округы чәсләре белән нык бәйләнеп тора. Хәзер Урта Азиада «Кзыл әрмиес» гәзитенең күчмә редакциясе эшли. Күчмә редакция башка эшләр белән бергә, татар-башкрт әдәбият түгәрәге төзиячәк.

Урта Азиа чәсләрендә хәзер көчле генә әдәбият кадрлары бар. Алар «Кзыл әрмиес» гәзитендә язышып торалар. Бу иптәшләр төзелә торган әдәбият түгәрәкләренең актив әгъзалары булып, бу юлда актив рәүштә эшләрләр.

Әдәбият сүзе милли чәсләрнең сугыш хәзерлеген күтәрүгә булышлык итәчәк.

М.Әмирев.

*Текстны **Гөлшат Әмирова** әзерләде.* ■

---

*«Перо и винтовка» – «Красная звезда» гәзетасының Урта Азия хәрби округы Әдәби сәхифәсе №1 (24) 1931 ел.

Әдип текстында шул чорның тел үзенчәлекләре, орфографиясе һәм пунктуациясе сакланды. – **Ред.**

Зөлфәт хатыны Фираяга яңа шигырьләрен укый. 1970 нче еллар

«КАЛКЫЙМ ЙОЛДЫЗ БУЛЫП КҮКЛӘРДӘ...»

(Шагыйрь Зөлфәтнең матбугатта басылмаган шигыре)

Розалия Зәкиева

1992 елның җәендә, Сабантуйлар узганнан соң, Татарстан радиосы өчен шагыйрь Зөлфәтнең йолдызлар турындагы шигырьләреннән торган «Йолдызнамә» исемле шигъри-музыкаль композиция әзерләдем. Ул вакытта радиода җырчы Рафаэль абый Ильясов, шагыйрә Шәмсия Җиһангирова, режиссер Госман абый Әхмәтҗанов эшли иде. Алар миңа радио фондында булган бихисап музыкаль әсәр тыңларга мөмкинлек тудырды. Илһам абый Шакиров, Хәйдәр Бигичев, Вафирә Гыйззәтуллина, Зилә Сөнгатуллина, Зөһрә Сәхәбиева кебек затлы җырчыларыбыз башкаруындагы җырлар сайлап алдым. Йолдызлар турындагы шигырьләр әнә шул җырлар белән үрелеп барды. Ләкин «Йолдызнамә»не тәмамлар өчен, Зөлфәт абыйның китапларында сибелгән «йолдызлар» гына җитми кебек тоелды һәм мин, яңа шигырь эзләп, шагыйрь янына киттем.

Зөлфәт абый ул чакта «Чаян» журналында эшли иде. Мин аңа, яратып, «абзый»,

Шагыйрь Зөлфәт язма авторы Розалия Зәкиева белән. 1990 нчы еллар

дип эндәшә идем. Килдем. Бүлмәсенә кереп, гәдәттәгечә, бераз әрсезләнеп: «Сәлам, абзый, шедевр кирәк!» – дип, эшеннән бүлдердем. Абзый бервакытта да үтенечләремне кире бормый иде. Бу юлы да эшем уңды, йомышым үтәлде: бер тында яңа Шигырь туды! Зөлфәт абый, астына көнен-елын язып, шигырь язылган кәгазьне миңа сузды...

Озак та үтмәде, «Йолдызнамә» шигъри-музыкаль композициясе эфирга чыкты һәм атнаның иң яхшы тапшыруы дип табылды! Минем архивымда бу шигырь кадерле ядкәр булып инде 25 ел саклана!

Йолдыз, йолдызнамә... Абзый үзе дә бөтен татар сәнгате күгендә мәңге сүнмәс якты Йолдыз булып калыкты.



10 июнь 92

Зөлфәт

Сөю сүзем күктән иңәр сиңа...

Тик бер генә язмыш язсын Ходай –
Калкыйм йолдыз булып күкләрдә.
Кирәк икән әгәр синең өчен
Мин әзермен янып төшәргә.

Очыйм мең чаткыга таралып мин –
Чиксезлеккә китсен яктысы.
Тын йөрәгең дертләп куйсын кинәт,
Тисен аңа галәм чаткысы.

Сөю юлы – очкан йолдыз юлы.
Йолдыз очар юлны кем сызган?
Сөю сүзем күктән иңәр сиңа –
Күзләреңне алма йолдыздан.

10 июнь, 1992 ел ■

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

ГАЛИҖӘНАП ГАЛИМ

Әгәр исән булса, танылган тәрҗемәче, исламият һәм гарәп теле белгече, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы (2005), галим Әнвәр Хәйригә (Әнвәр Нәҗибулла улы Хәйруллинга) 2017 елның 2 декабрендә 70 яшь тулган булыр иде.

Бишенче сыйныф укучысы Әнвәр. Шәрбән сигезьеллык мәктәбе.
10 март, 1960 ел

Аксубай районының Шәрбән авылы тумасы, «Шәһри бану-Шәрбән кыйссасы» (1996), «Ислам дине бәйрәмнәре» (1996), «Ризаэддин Фәхреддин әсәрләрендә тәрбия-әхлак мәсьәләләре» (2004) һәм «Әхмәд ибне Фадланның 921-922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе» (2013) дигән китаплар авторы, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре (1991, 2008), Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1999), К.Насыйри һәм Җ.Вәлиди исемендәге премияләр (2004, 2008) иясе Ә.Хәйрине (1947-2014) хөрмәт белән искә алып, сәхифәбездә галимнең гаиләсе архивыннан алынган фотосурәтләрен тәкъдим итәбез.

Укытучысы һәм сыйныфташлары белән (алгы рәттә сулдан беренче – Әнвәр).
12 март, 1960 ел

Казан театр училищесында укыган вакытта Әнвәр «массовкалар»да еш катнаша. Рәсемдә (сулдан уңга): Әнвәр Хәйруллин, Равил Шәрәфиев, Илдар Хәйруллин.
1968 ел

Казан дәүләт университетында оешкан татар драма театры студиясенә (җитәкчесе – Гәүһәр Камалова) йөрүчеләр мөгаллимнәре белән. Рәсемдә: басып төшкәннәр арасында сулдан уңга бишенче кеше – Әнвәр Хәйруллин, уңнан беренче – шагыйрь Нур Әхмәдиев. Утырганнар арасында сулдан икенче Ибраһим Нуруллин, Флера Сафиуллина, Гәүһәр Камалова, Сәгадәт Ибраһимов, Алмазия Нуриева.
1968 ел

Әнвәр Хәйри остазы, гарәп теле укытучысы Лена Кәлимулла кызы Таҗиева белән. 13 март, 1998 ел. Мидхәт Шакирҗанов фотосы

Әнвәр Хәйри Биләрдәге «Сәләт» лагеренда чыгыш ясый. Июнь, 2004 ел



Өч галим: Әнвәр Хәйри, Җәүдәт Сөләйманов һәм Фаяз Хуҗин. 2006 ел

Галимнең әнисе Гыйльмиҗиһан апа

Әнвәр Хәйри хатыны Альмира ханым белән.
2007 ел

Дәү әти ике оныгы – Камил һәм Зөлфия белән

*Текстны **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

Сукыр Сибгат һәм аның хисапчы улы Миңнегали

Габдулла Галиев

Якташым, тарихчы-галим Раиф Мәрданов «Әгерҗе төбәге» дигән китабында бабам Сибгатулланы искә алып, аны, Кырынды (әүвәлге исеме Төрдәле) авылында сәүдәгәр булган, дип язган. Дөрестән дә, олы урамга ян белән салынган алтыпочмаклы агач йортның кече ягын кибет итеп тоткан бабам. «Сукыр Сибгат лавкасы»ннан чәй, шикәр, кызыл билле прәннек, өрек чикләвеге, сабын-мазар сатып алырга мөмкин булган. Калмык битле (кыпчак нәселеннән булуына бер ишарә), пеләш башлы, уртача буйлы, киң җилкәле, сөйкемле карт иде ул.

Бабам Сибгатның язмышы аяныч булган. Ул сабый чагында ук шул заманның коточкыч авыруы чәчәк (оспа) белән хасталана, терелүенә өмет тәмам өзелгән көннәрнең берсендә кинәт могҗиза була – бабам аякка баса. Әмма рәхимсез авыру үзенекен эшләп өлгергән була шул инде – бабам, күзләренә ак төшеп, сукырая. Ул, күзләрен бик тырышлык белән хәрәкәтләндереп, яктылыкны бераз гына чамалый торган сукыр иде. Кечкенә вакытымда аның тезләренә менеп утырыр идем дә, күзләренең нәкъ үзәген каплаган ак тышчага карап торыр идем. Бөтен җаным-тәнем белән шул шөкәтсез тышчаны кубарып атасым һәм бабамны барыбыз кебек бәхетле итәсем килә иде...

Бу урында Гафифә әбием турында берничә җөмлә язып үтим әле.

Гафифә әбием авылыбызга Олы Барҗыдан дүрт чакрым ераклыкта урнашкан элек Бигәш, соңрак Мушик дип аталган авылдан килен булып төшкән. Әбиемнең бер энесе Габдулла бик укымышлы кеше булган, авылларында мәзин булып торган. Ул Төрдәлегә кунакка еш килгән, әтием Галине бик яраткан. Әтием дә аны хөрмәт иткән. Мин дөньяга килгәч, аның истәлеге булыр, дип, әтием миңа Габдулла исеме куштырган.

Гафифә әбием Мушик авылында иң чибәр кызларның берсе була. Аның шулай кинәт кенә сукыр Сибгаткә кияүгә чыгуына күпләр гаҗәпләнә. Кара кыйгач кашлы, күмер кебек янып торган күзле, йөзеннән елмаю китми торган әбиемнең чибәрлеге олыгайгач та сакланды. Бервакыт әнием: «Каенанай, яшермичә генә әйт әле, ничек күрә торып сукыр каенатайга чыктың?» – дип сорады. Әнием аның иң авырткан җиренә кагылса да, җавабын көттермәде, шунда ук: «Дим белән чыктым, килен, димләү белән», – диде. Әбиемнең йөзе кинәт боегып киткәндәй булды, әмма шул мизгелдә үк кабат ктырды. «Мине сукыр егеткә бирәселәрен белгәч, мендәргә капланып еладым. Берничә көндә

сулган гөлгә охшап калдым. Энем Габдулла, Төрдәледән Сибгатне алып килеп безне күрештерде. Күрешеп сөйләшкәч, ошаттым. Чибәр булмаса да, акыллы булып чыкты Сибгатем, тамчы да үкенмим», – диде әбием.

Гафифә әбиемнең сөйләвенә караганда, сукыр бабама сәүдә итүләр һич тә җиңел булмаган. Бабам һәркөнне диярлек җилкәсенә аллы-артлы тубал асып, кулындагы таяк очы белән юлны капшап, йорттан-йортка кереп, йомырка җыеп йөргән, атна азагында, җыйган йомыркаларны олауга төяп, Алабуга каласына озаткан. Аннан исә аңа товар алып кайтканнар. Товар ташучы булып безгә (ягъни бабама) кардәш тиешле Садыйк абзыебыз Галимов йөргән. Аның тырышлыгы аркасында, сукыр Сибгат кибете товарга кытлык кичермәгән. Бабам, кибеткә килүчеләрнең акчалары өстеннән бармакларын йөртеп алганнан соң, ничә тиенлек икәнен җиңел генә әйтеп биргән, бик сирәк ялгышкан,

Габдулла Галиевнең әтисе Миңнегали Сибгатулла улы Сибгатуллин. 1941 ел

кәгазь акчалар булганда гына әбиемне чакырып ала торган булган. Әмма, әбиемнең сөйләвенчә, кайбер мәкерле бәндәләр бабамның сукыр булуыннан файда алып калырга тырышкан, бигрәк тә кешенекен чәлдерергә яратучы ага-энеле Әхмидишаныкылар бабама тынгы бирмәгән. Кибеткә таяк очына кадак кагып киләләр икән: берсе бабамның игътибарын читкә юнәлтеп сөйләштергән арада, икенчесе кибет киштәсендәге каплы чәйләрне, сабыннарны таяк очындагы кадакка эләктереп ала торган була. Кичләрен көнлек сатуына исәп-хисап ясап утырганда җитмәүчелек чыга башлагач, бабам бик кәефсезләнә. Уйлана торгач, шиге Әхмидишаныкыларга төшә, чөнки «растрата» дигәне кибеткә нәкъ Әхмәдишаныкылар килгән көнне була. Берничә көннән теге караклар тагын кибеткә килеп керә, бабам аларны тавышларыннан танып: «Гафифә! Гафифә, дим, яныма кер әле», – дип, әбиемне чакырып ала башлый...

Авылда «калхуз» оештыру башланган чак. Иртән үк кемнеңдер калын-тупас тавыш белән: «Җыенга! Хәзер үк җыенга барыгыз!» – дип тәрәзә кагып киткәнен яхшы хәтерлим. Әтием ул җыеннан күтәренке кәеф белән кайтты: колхозга керергә гариза биргән, иртәгә ике атыбызны да колхозга илтеп бирәчәк икән. Өйдәгеләр, күңелсезләнеп, тынып калды. Барысы да Сибгат бабама текәлде. Ул әтинең колхозга язылуын бер дә хупламады. «Бүген кермәсәк, иртәгә барыбер кертәчәкләр, безгә алданрак керү файдалы», – диде әти. Күрәсең, ул илдә бара торган күмәкләшү сәясәтен яхшы аңлагандыр.

Берникадәр вакыттан соң, авыл халкын тагын җыенга җыеп алдылар. Әти аннан

Булачак язучының әнисе Кәшифә Мөхәммәтзариф кызы оныклары белән. 1962 ел

күңелсезләнеп кайтты. Җыенда Сибгат бабамны авыл байлары белән бергә «кулак» дип игълан иткәннәр икән. Авыл халкы башта: «Сибгат абзый нишләп кулак булсын инде? Сукыр, гарип көенә авыл халкын шикәргә, чәйгә туендырып торды. Аның сабыннары белән юынып бетләмәдек», – дигәннәр. Җыенда тавыш, бәхәс китә. Районнан килгән вәкил, өстәл кагып халыкны тынычландырганнан соң, алдындагы папкасыннан кәгазь тартып чыгара да: «Җәмәгать, тынычланыгыз! Менә сез Хәбибулла улы Сибгатулланы бик тырышып яклыйсыз. Әмма ул кешегез Галимов Садыйкны, Хәтмуллин Гыйззәтулланы үзенең шәхси хуҗалыгында ялчылар итеп тоткан бит. Факытмы бу? Факыт! Ызначит ул – эксплататор, менә сезнең кебек гади халыкны изүче», – дигән. Аның чыгышыннан соң залдагы халык тынып калган. Әтиемнең әйтүенчә, тиздән безне раскулачивать итәчәкләр, йортыбызны, каралтыкурабызны, терлекләребезне тартып алачаклар икән. Әнием мышык-мышык борынын тарта башлады. Әбием: «И Ходаем, йортыбыздан урамга куып чыгарсалар, нишләрбез?» – дип елап җибәргәч, минем дә аңа кушылып елавым исемдә калган...

Шушы вакыйгадан соң озак та үтмәстән, Сибгат бабам вафат булды.

Миңа алты яшь тулып килгән көннәрнең берсендә әти эшеннән нигәдер бик борчылып кайтты. Түш кесәсеннән гәҗит алып, аны өстәлгә куйды да, кече якта кичке ашау әзерләп йөргән әнине янына чакырды. Әнием чыккач, гәҗитен кулына алып, укырга кереште. Минем колагыма: «Ленинградта Смольный дигән җирдә Кировны атып үтергәннәр», – дигән шомлы сүзләр кереп калды. Әнием бу хәбәрне кибеткә килгән кешеләрдән алданрак ишеткән булып чыкты. «Илебездә әллә нинди куркыныч хәлләр бара, шаукымы безнең якларга гына килеп җитә күрмәсен инде», – дип, бик борчылып, кече якка чыгып китте.

Озак көттермәде, ул шаукым безгә дә килеп ирешге. Беркөнне районнан килгән прокурор, колхоз конторасында эшләп утырган әтине күреп: «Бу кулак малаен кем рөхсәте белән эшләтәсез?» – дип, колхоз рәисе Ибраһим абзыйга җикеренгән.

Әйбәт кенә эшләп йөргәндә, 1935 елның көзендә әтине кинәт кулга алып, Әгерҗегә алып киттеләр. Миннән ничек яшерергә тырышсалар да, әти турындагы хәбәрне мин барыбер урамнан ишетеп кайттым. Әтине кызганучылар да, кулга алынуына шатланучылар да бар иде. «Галигә 58 нче статья чәпегәннәр, тиздән дөпелдәтәчәкләр», – дип, үзебезгә кардәш тиешле берәүнең урамда гайбәт сатып йөрүен ишетү бик авыр булды.

Йортыбызда күз яшьле, кайгылы көннәр башланды. Аллаһы Тәгаләдән күз яшьләребез белән ялваруыбыз кабул булгандырмы, әтинең язмышы уңай якка үзгәрә. Бу болай була: көннәрдән беркөнне әти утырган камерага өлкән яшьтәге бер кешене кертеп ябалар. Баштарак шактый көннәр бер-берсеннән шикләнеп уза, чөнки камераларга махсус провокаторлар кертә торган булалар. Берникадәр вакыттан соң, сынашу вакыты үткәч, алар, якынаеп, танышып китә. Әти кебек, ул да сәяси тоткын була.

Төрдәле мәчетендә – намаздан соң: сулдан дүртенче – Габдулла ага Галиев. 2015 ел

Шул тоткынның соравы буенча, әти аңа үзенең бөтен биографиясен, сукыр бабамның лавка дип аталган кибет тотканын, аннан кергән табышның гаиләләрен туйдырырга гына җиткәнен түкми-чәчми сөйләп бирә. Әти үзенең колхозчылар алдында, быел икмәкне сезгә узган елгыга караганда кимрәк өләшергә туры килмәгәе, дигән сүзләрен кабат исенә төшерә. «Ләкин мин бит бу сүзләрне коткы тарату нияте белән әйтмәдем. Икмәкнең тулай җыемын хисаплап чыгаргач кына әйттем, дөресе шулай», – ди әти, ялгышына үкенеп. «Әйе, бик начар эшләгәнсең. Югарылардан ышанычлырагы – хәзер Михаил Иванович Калинин. Әйдә, без аңа хат язып карыйк», – ди теге тоткын. Шулай итәләр дә...

Ике ай чамасы вакыт үткәч, төрмә начальнигы әтине үз бүлмәсенә чакырып ала. Бүлмә түрендәге өстәл янында чаларган чәчле, кара кысалы күзлек кигән ир кеше утыра. Үзен прокурор дип белдергәч, кулындагы сургучлы конвертны күрсәтеп: «Бу хатны Сез яздыгызмы?» – дип сорый. Хат язган теге тоткынны башка урынга этап белән озаткан булалар инде. Аның исемен әйтсә, хыянәт булачак дип, әти кинәт кыюланып: «Әйе, мин яздым», – дип җавап бирә. Прокурор шактый вакыт әтигә сынаулы караш ташлап торгач, сакчыга әтине камерасына алып китәргә куша.

Калинин имзасы белән килгән хатта: «Бу тоткын хаты өйрәнелде, коллегия аның гаебен тапмады, статьясы төзәтелде. Коллегия күчергән статья буенча авылында хөкем итегез», – дип язылган була.

Әтине авылыбызда хөкем иттеләр. Әти өстеннән язган кеше авылыбыздан чыгып качкан булып чыкты. Башка шаһитлар хөкем каршында буталышып бетеп, әти алдында гафу үтенә. Парторг Хөбби абыйның әтине яклап ясаган чыгышы бик урынлы була. Суд әтине аклый.

Әти, нигәдер, үз эшенә кире кайтмады, Көчек авылы сельпосына хисапчы булып урнашты, без гаиләбез белән шунда күченеп, ике ел шул авылда яшәдек.

РЕДАКЦИЯДӘН: *2018 елның 10 гыйнварында Әгерҗе районының Кырынды авылында яшәп иҗат итүче өлкән язучыбыз Габдулла Миңнегали улы Галиевкә 90 яшь тула. Могтәбәр каләмдәшебезне күркәм юбилее белән ихлас котлыйбыз һәм аңа саулык-сәламәтлек, иҗади уңышлар телибез!* ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

ХУШЛАШУ СҮЗЕ

(Нәсер)

Ләис Зөлкарнәй

Утыз яшендә тол калып,
биш баласын аякка бастыра
алган Заһидә әбием рухына

Әй, сөлге-сөлгекәй, гомер юлдашым минем, әйдә әле сөйләшик, тавыш-өнсез генә бер сөйләшик. Үпкәләмә инде миңа, Сабантуй колгасына яшь килен бүләге итеп сине элмәдем мин, бәйгедә җиңгән атларның ялларына да сине бәйләмәдем. Матуррак сөлгеләрем бар иде шул... Матурлык китә икән ул, сөлгеләр булып тарала икән.

Әй, сөлге-сөлгекәй, гомер юлларын бергә кичтек, шатлыкны да, авырлыкны да бергә кичердек. Сугыш елларында, балаларым ачтан үлмәсен, дип, бар булган мал-мөлкәтне ризыкка алыштырганда да мин сине бирмәдем, балаларым кебек кадерле булгансың, ахры... Әй, сөлге-сөлгекәй, ап-агым минем, сине гомер буе каралтмый сакладым мин. Баксам, син минем йөз аклыгымны саклагансың икән...

Әй, сөлге-сөлгекәй, инде менә саубуллашыр вакыт та җитә бугай. Чү, җилфердәмә, тавыш-өнсез генә саубуллашыйк. Кешеләргә йөз аклыгымны илт син, сөмсере

коелганнарның да йөзләрен яктырт. Сабантуй колгасына да, ат ялына да элмәдем – менә хәзер кешеләрнең күңеленә сине күбәләкләтеп бәйләп куям...

САНДЫККА – САГЫШКА САЛДЫГЫЗ...

Калды ич, калды ич Казан сөлгесе.

Җиз кыңгырау зеңгелдәгән туй атлары дугасында җилфер-җилфер килә кәләш сөлгесе. Сабан туена бирнә җыючылар куанычы – колганың иң очында – килен сөлгесе.

Җилкәсенә тәкә күтәргән батыр муенында очлары җиргә тигән яшь килен сөлгесе.

Калды ич, үткәннәрдә калды ич...

Казан сөлгесе!

Бәлки, син мәхәббәт җырыдыр? Үкенечле, ләкин үзең төсле ак, якты мәхәббәт җырыдыр?

Апасыннан матур сеңлесе...

Казан сөлгесе!

Сине муеныма салам. Өнсез калып, бик озак басып торам. Юк, мин Сабантуй батыры түгел, һәм син бүләккә алынмаган, яшь киленнеке дә түгел. Син – әбиемнеке. Ул күптән юк инде, хәтерләмим дә мин әбиемне. Ә менә син тукылган станны хәтерлим әле. Күрше Сөендек авылында, әниемнең апасы Тәзкирәттәйдә саклана иде ул. Озын төнле кышлар җиткәч, мин малайны, эрләнгән йон йомгаклары белән бергә чанага салып, кунакка озата торганнар иде.

Өстемдәге саламнарны кага-кага, мине өйгә кертәләр. Кече яктагы бозлы тәрәз каршында әби кебек бөкрәеп утырган стан, шыгырдап, сәлам биргән шикелле була. Озак еллар эшләүдән шомарып кучкылланган станны никтер карт кешегә охшата идем. Өстәл, урындыклар һәрвакыт өйдә, ә бу кыш җиткәч кенә сәндерәдән төшә, гүя кыш чыгарга кызына кунакка килә. Апа, күз бәйләнү белән, җиделе лампага ут элдерә (кышкы төннәрдә электр уты еш кына сүнә иде) һәм стан каршысына килеп утыра. Шулчагында, җылысы бөркелгән мичкә арканы терәп, тавыш-өнсез генә күзәт тә күзәт инде аларны. Стенада күләгәләре бергә кушыла да тибрәлә, калкына башлый. Шүрене уңга-сулга йөрткән куллар, әле күтәрелгән баш, бөкрәеп торган стан күләгәләре һәммәсе бербөтенгә әверелә дә, кулы белән миңа ишарәли-ишарәли, нидер сөйләгән карчык сурәтенә керә.

– Палас тукытырга килде, рәхмәт яугыры... Элгәре замана булса, чүпләм сөлге дә тукып бирер идем үзеңә...

...Атна-ун көннән кайтыр юлга чыгам. Арыш саламы түшәлгән чанага утырып, паласка кырын ятып кайтам. Атымның дугасына нигәдер чүпләм сөлге эләсем килә һәм, чанасын биреп, мине тау шудырган күрше авыл кызын нигәдер янәшәмә утыртып кайтасым килә. Казан сөлгесе! Калды ич, калды ич...

Синнән башка Сабантуй буламыни?! Һәм бездән – малайлардан башка да булмый ул. Әтиләргә ияреп, Сабан туена бирнә җыеп йөргәндә, аргы очтан бирге очка ишетелерлек итеп без генә кычкыра алабыз:

– Килен сөлгесе! Килен сөл-ге-се-е!..

Әфсен шикелле сүз ул. Әнә, Зәкиҗан бабайларның капкасы бүген елмаеп ачыла. Иң яшь килен – аларда. Мәйсәрә апа оялып кына капкадан чыкты да колганың иң очына озын-озын сөлгене күбәләкләтеп бәйләп куйды.

Ассалап тукылган озын Казан сөлгесе!

Без – малайлар – көрәштә җиңсәк тә, йә йомырка, йә прәннек инде. Мондый матур сөлге калмый иде безгә.

Калды ич, күңелләрдә калды ич...

Бүләкнең иң зурын Сабан туена бирнә җыйганда ук алганбыз лабаса: күңелләргә күбәләкләтеп бәйләп куйганнар.

Казан сөлгесе!

Сабантуйларга сирәк кайтыла. Кайтсам да, мәйдан үзәгендәге колга очында мин сине күрмәдем. Анда кызыл әләм җилферди иде.

Талчыккан батыр да шыбыр тиргә баткан йөзен сиңа сөртмәде, тәкәне җилкәсенә күтәреп мәйдан әйләнгәндә, син аның муенына уралып җилфердәмәдең, чөнки сине бирмәделәр аңа.

– Килен сөлгесе, килен сөл-ге-се-е!

Күңелемдә малай чагым кычкырып такмаклый. Күңелемдә капкалар елап ачыла...

Сабантуй бирнәсенә хәзер бирмиләр шул Казан сөлгесен. Бәлки, бу халкымның иң зур югалтуларыннан берседер.

Алдымда хат.

«Йолалар онытыла инде. Яшь киленнең байлыгы, эшкә осталыгы кибеттән алынган келәм, челтәр, кием-салым белән үлчәнә хәзер...

Әминә Сөнгатуллина.
Яшел Үзән районы, Татар Танае авылы».

Казан сөлгесе!

Малайлар, колгага үрмәләп, сине алып төшәләр иде.

Кызыл әләмне берәү дә менеп алмады. Җилфердәп, җәйне уздырды ул, кышка керде. Сабантуй колгасында, кояштан-җилдән уңып, аксыл төскә кергән әләм – авылның капитуляциясе...

Казан сөлгесе!

Бәлки, син язмыштыр...

Менә тагын бер хат.

«... Әни безнең кулак гаиләсендә килен булган. Шуның өчен гаепләнеп, 1930 елның февраль аенда өстендәге киеме, кулындагы алты айлык баласы белән Архангел өлкәсенең Вологда шәһәренә сөрелгән. Ул аннан 1935 елда ялгыз башы (баласы үлгән) ач-ялангач качып кайткан. Яшәренә – куышы, ашарына ризыгы булмаган, кулак хатыны дип, эш бирмәгәннәр. 1937 елда, шундый авырлыкта яшәгәндә, безнең әти – бик авыру кеше – аны хатынлыкка алган. Бик ярлы булган ул, өе җимерелеп беткән. Бәлки, бу сөлге әтинец бердәнбер байлыгы булгандыр. Мин белгәндә, әни бу сөлгене бик кадерләп тота иде. Кунакка килгән мулла-абыстайларга гына сөртенергә бирә иде. «Сөлгене сандык төбенә салмагыз, саргая...» – ди торган иде ул...

Зөлфирә Кунакова.
Оренбург өлкәсенең Сакмар районы, Үрге Чебенле авылы.

Калды ич, сандыкларда гына калды ич...

Казан сөлгесе!

Бәлки, син халкымның йөз аклыгыдыр...

Ак яулык бөркәнгән әбиләре, балаларын һәм оныкларын җыеп, сандыкларын ача. Күз нурларын кушып тукыган сөлгеләрен истәлеккә өләшә.

– Төсем итеп саклагыз, балакайлар, төсем итеп саклагыз Казан сөлгесен!

Казан сөлгесе!

Бәлки, көннәрдән беркөнне син җырда гына калырсың.

Апасыннан матур сеңлесе.

Калды ич, калды ич Казан сөлгесе.

Кайда син, матур сеңел?

Ашык әле, матурлыгыңны сөлгеләреңә чигеп калдырырга ашык әле. ■

Татар моңы әхрамы*

Зимфира Гыйльметдинова

Филармониянең сәнгать җитәкчесе И.Мәҗитов яңа концерт сезонын ача. 1988 ел

Узган елның 21 августында Татар дәүләт филармониясе оешуга 80 ел тулды. Мәдәният залларының гомере сезоннар белән саналу сәбәпле, 2017-2018 еллар тулаем юбилей сезоны кимәлендә узачак. Концертлар, тамашалар, интернет-проектлар, сәяхәтләр, очрашулар... Болар барысы да Россиядәге иң дәрәҗәле концерт оешмаларыннан булган Татар филармониясенең озын һәм бай эчтәлекле гомерен ачуга юнәлтеләчәк.

ТАРИХКА КҮЗ САЛСАК...

СССРда бер-бер артлы ачылган филармонияләр – совет чорының, бүгенгечә әйтсәк, җитди «проект»ларыннан. Казанга кадәр Ленинград, Мәскәү, Киев, Харьков, Түбән

*Язманы әзерләгәндә Георгий Канторның «Җиде дистә елга сузылган иҗат юлы» дигән мәкаләсе файдаланылды.

Гастрольгә чыгар алдыннан. Сулдан уңга: директор Михаил Боголюбов, (арты белән торган кеше билгесез), сүз остасы Нина Туманская, җырчы Зифа Басыйрова, сүз остасы Геннадий Гурфинкель, музыкант Фәйзи Биккинин, иллюзионист Хәй Мушинский. 60 нчы еллар башы

Новгород, Свердловск кебек шәһәрләрдә (барлыгы – 16) филармония ачылган була инде. Татарстан АССРның Халык Комиссарлары Советы карары белән 1937 елның 21 августында оештырылган Татар дәүләт филармониясе – унҗиденчесе.

Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, профессор **Георгий Михайлович Кантор** Татар филармониясенең 70 еллык юбилеена багышланган мәкаләсендә болай дип яза: *«СССРның күп шәһәрләре ул елларда концерт-эстрада бюролары төзү белән канәгатьләнәләр. Ул бюролар читтән килгән артистлар өчен прокат конторалары ролен үти. Ә Казан кебек зур сәнгати көче, профессиональ музыкантлары, башкаручылары булган шәһәрләр үзгәлеккә, «үзенекен» булдыруга йөз тота, концерт эшчәнлегенең сәяси вазгыятькә тәңгәл килерлек яңа формаларын эзли. Әле революциягә кадәр тәрбияләнгән тамашачыларның, традицияләрнең, тиешле биналарның булуы да Казанда филармония ачылуга этәргеч ясый».*

1917 елга кадәр дә Казан бай иҗади тормыш белән яши. Биредә борынгы опера театры, симфоник һәм камера концертлары оештыручы конторалар, музыка училищесы була. Тамашачыны тәрбияләүдә татар халык музыкасын башкаручы артистлар гаять зур роль уйный. Ул елларны шаулаткан исемнәрдән Камил Мотыйгый, Гали Зайпин, Илларион Козлов, Мәрьям Рахманкулова, Фәйзулла Туишев, Фәттах Латыйпов, Заһидулла Яруллиннарны атарга мөмкин.

Татар филармониясеннән соң, 1939 елда Татар опера һәм балет театры, 1945 елда Казан консерваториясе ачыла. Әлеге өч оешма тыгыз элемтәдә эшли һәм Татарстан башкаласы тиз арада югары професссиональ музыка үзәгенә әверелә.

Филармониянең беренче директоры итеп музыкага бернинди катышы булмаган партия функционеры **Л.Галиевне** билгелиләр. Ул үз янына яхшы музыкантлар туплый, нәтиҗәдә, филармониядә көчле иҗат коллективлары барлыкка килә. Иң элек 35 музы-

канттан торган симфоник оркестр оештырыла. Баш дирижер итеп М.Шеппер билгеләнә, 1938 елда аны И.Әүхәдиев алыштыра. Ильяс әфәнде җитәкчелек иткән елларда оркестр «Татар дәүләт симфоник оркестры» дип атала башлый. Ләкин оркестр филармониядә озак эшләми – 1939 елның июнендә яңа ачылган Опера һәм балет театрына күчерелә.

Филармониянең тулы канлы, ныклы тормыш белән яшәп китүенә комачаулаган сәбәпләр дә була түгел: концерт оешмасы әзерлекле кадрлар, башкаручылар, оештыру тәҗрибәсе җитешмәгән шартларда барлыкка килә. Өстән кушу буенча тиз арада хор капелласы җыела. Ләкин ул тиз арада тарала да. Аның урынына Татар җыр һәм бию ансамбле оештырыла. Ансамбль күз ачып йомганчы Татарстан Республикасының горурлыгына әйләнә. Бу коллектив филармониядә 50 елдан артык эшли, 1991 елда ул мөстәкыйль мәдәният оешмасы сыйфатында аерылып чыга.

● *Гармунчы Фәйзулла Туишев архивында урыс һәм латин хәрефләре белән язылган бихисап афишалар саклана. Алардан күренгәнчә, сәнгатькәр, татар көйләре белән бергә, «Фарсы маршы», «Травиата», «Кадриль» кебек дөньякүләм мәгълүм әсәрләргә дә фантазияләр башкарган.*

● *Җырчы Камил Мотыйгый татар җырларын рус подтекстовкасы (музыка тексты) белән җырлап танылган. Моның өчен аны еш кына тәнкыйть утына тотканнар.*

Беренче елларда ук ачылган Эстрада бүлеге 1990 нче еллар уртасына кадәр эшли. Россиянең башка филармонияләреннән аермалы буларак, Татар филармониясе алдында милли музыкаль структуралар булдыру бурычы да тора. Биредә С.Таһиров җитәкчелегендә татар фольклоры кабинеты һәм композитор А.Ключарев җитәкчелегендә Татар халык уен кораллары оркестры оештырыла.

Әлбәттә, филармониянең акрынлап-акрынлап ныгуында Казанның элеккеге музыкантлары, урыс һәм татар композиторлары, музыка мөгаллимнәре зур роль уйный. Иң дәрәҗәлеләре арасында скрипкачы һәм дирижер Ильяс Әүхәдиев, хормейстер һәм атаклы теоретик Алексей Бормусов, композитор һәм фольклорчы Антон Эйхенвальдлар бар.

Казан телевидениесендә Яңа ел бәйрәмен каршылау. 1950 ел

Сулдан уңга: Р.Курамшин, И.Шакиров, С.Гарифуллин Караганда (Казакъстан ССР) телевидениесендә. 1960-1970 нче еллар тирәсе

● *1916 елда Казан университетында уздырылган Шәрык кичәсендә, башка урыс һәм татар музыкантлары белән бергә, яшь Салих Сәйдәшев тә чыгыш ясаган – фортепианода «Тәфтиләү» көенә импровизация башкарган.*

БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫ

Сугыш вакытында филармония штатын тулаем тотарлык мөмкинлекләр булмый. Штатларның бермә-бер кыскаруы артистларның фронтка китүе белән дә аңлатыла. Әмма бу чорда куелган концертлар саны кимеми, ә арта гына, чөнки Казанга Мәскәү, Ленинград, Харьков, Воронеж, Киев шәһәрләреннән бик күп зыялылар эвакуацияләнә. Шунысы да игътибарга лаек: 1941-1945 елларда Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле тулаем сакланып кала һәм эшчәнлеген бер көнгә дә туктатмый. Фронт бригадаларына тупланган опера театры, радиокомитет, филармония артистлары яу кырына барып концертлар бирә.

Үзәк мәдәният хезмәткәрләре йортында узган концерттан соң. Мәскәү. 1970 нче еллар

ҮЗ ТҮБӘҢ КИРӘК!..

Татар филармониясенең иң зур җәфасы – озак еллар буе бинасызлыктан интегү була. Ачылышыннан алып 1950 нче еллар азагына кадәр ул хәзерге «Нурулла» мәчетендә урнашып тора (мәчет биналарына мәдәни оешмалар, мәктәпләр «кертелү» совет чынбарлыгы өчен гадәти күренеш).

● *Озак еллар «иске» Казан операсында дирижерлык иткән Антон Эйхенвальд филармониянең фольклор кабинетында эшләгән. Ул татар фольклоры белгече, этнограф булган, «Дала» исемле татар операсын язган. Татар һәм башкорт фольклоры турында китап чыгарганы өчен аңа «халык дошманы» ярлыгы тагылган.*

Островский урамындагы бинада да бүлекләр, җыр-бию ансамбле, репетиция класслары гаять тыгыз итеп урнаша.

Филармонияне Гоголь урамындагы беренче яхшы бинага 1970 нче еллар уртасында гына күчерәләр.

Ләкин тамаша залы, иркен репетиция һәм администрация бүлмәләре булган, зур шәһәр филармониясенә лаек бина 2000 елның ноябрендә генә бирелә. Павлюхин урамындагы бу йорт 1955 елда С.Киров исемендәге Синтетик каучук заводының мәдәният сарае буларак төзелә. Архитекторлары – П.А.Саначин һәм Г.И.Солдатов. Бина барокко, классицизм, совет йогынтысында бераз үзгәреш кичергән арт-деко элементларын берләштергән совет ампиры, икенче төрле әйткәндә – неоклассицизм стилендә эшләнгән.

Кызганыч, Татар филармониясе өчен бүген бу бина да кысан инде. Ике дистә елга якын алып барылган концерт эшчәнлеге, тамашачының төрле коллективларга,

Сулдан уңга утырганнар – С.Садыкова, М.Якупов, Ф.Насретдинов; басканнар – М.Галиев, З.Сәхәбиева, Ә.Кәримов. 1970-1980 нче еллар тирәсе

● *Сугыш вакытында Мәскәү һәм Ленинградның күренекле музыкантлары, музыка белгечләре, композиторлары М.Гнесин, Е.Бекман-Щербина, В.Конен, М.Юдин, А.Леман Казанга күченеп торган. Алар Казан консерваториясендә укытканнар, филармония концертларында катнашканнар, лекцияләр укыганнар.*

● *1946 елда филармония артистлары беренче тапкыр чит илгә чыккан. Татарстан артистларын Алмания, Болгария, Польша тамашачылары алкышлаган.*

дөньякүләм танылган иҗатчыларга игътибары Казанга зур, күләмле тамашалар куярлык, кимендә 2000 кеше сыйдырырлык концерт залы кирәклеген исбатлады.

КИЧӘДӘН – БҮГЕНГӘ...

Г.Кантор филармониягә багышланган язмасында берничә директорга аерым тукталып үтә.

Михаил Боголюбов чорында консерваториянең һәм опера театрының иң яхшы музыкантлары белән эшләүгә йөз тоткан лекторий төзелә.

Михаил Первин җитәкчелек иткәндә биредә Натан Рахлин җитәкчелегендәге ТАССРның Симфоник оркестры туплана.

Марат Таҗетдинов чорында (1973-1988 еллар) татар эстрадасы киң колач җәя. Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Зиннур Нурмөхәммәтов, Хәмдүнә Тимергалиева, Ренат Ибраһимов һәм башка бик күп җырчылар халык арасында танылу ала.

Әсхәт Сафин идарә иткән елларда (илнең гаять тынгысыз, тормышның тулаем

Ансамбль Сәмәрканд шәһәрендә. 1960-1970 нче еллар тирәсе

коммерциягә күчкән вакыты...) филармониянең Эстрада бүлеге таркала. Бу чор казанышларыннан Анатолий Шутиков җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы Халык уен кораллары оркестры һәм Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Фольклор музыкасы дәүләт ансамбле оешуны атарга мөмкин.

Татар филармониясенә 2003 елда директор булып килгән **Кадим Нуруллинны** зур музыкаль проектлар, фестивальләр тарафдары, дип атасаң, дөрес булыр: Натан Рахлинның 100 еллыгына багышланган халыкара музыка фестивале, татар җырын башкаручыларның Илһам Шакиров исемендәге Халыкара фестивале, озак еллар буе зур уңыш белән барган «Халык көйләре» Бөтенроссия конкурс-фестивале, «Филармониада», «Джазлы Казан», Рөстәм Яхин исемендәге классик музыка фестивале... Бу чаралар соңгы елларда Казан һәм Татарстан тамашачысына дөньякүләм танылган музыкантларны, вокалистларны, күренекле оркестрларны, ансамбльләрне, солистларны күрсәтте.

Россиянең иң мәртәбәле концерт оешмаларыннан саналган Татар дәүләт филармониясендә бүген дүрт зур коллектив эшли, болар: Россиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Анатолий Шутиков җитәкчелегендәге Халык уен кораллары оркестры; Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Фольклор музыкасы дәүләт ансамбле; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Анатолий Василевский җитәкчелегендәге Филармония джаз оркестры; Татарстанның атказанган артисты Владимир Васильев җитәкчелегендәге Музыкаль-әдәби лекторий.

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе бер концерт сезонында ярты миллионнан артык тамашачыга хезмәт күрсәтә. Коллективларның гастроль географиясе гаять киң: Татарстан авылларыннан алып океан артындагы кыйтгаларга кадәр... Һәм ул фәкать киңәя, ә мәгънәви җәһәттән – тирәнәя генә бара. ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

АЛИҺӘ

Әлфия Авзалованың тууына 85 ел

Күк капусын гомергә бер
Безгә дә Тәңре ачты, –
Иңдерде Актанышка ул
Иң моңлы сандугачны.

Сүнгән күңелгә сөюне
Ул гына сала икән.
Халыкны бер сандугач та
Юата ала икән!..

Рәшит Әхмәтҗан

Ләбиб Лерон

ЯШЬ ГОМЕР БЕР УЗГАЧ...

Мәшһүр якташым
Әлфия Авзаловага

Күңелдә бер җыру...
Исемдә шул һаман:
«Яшь гомер бер узгач,
Кайтмый ул яңадан...»

Яшьлектә бу җырны
Мин күпме тыңладым! –
Кушылып Җырчыга,
Үзем дә җырладым...

Җырладым үземчә –
Булдыра алганча,
Хәтердә җыр тәмам
Уелып калганчы...

«Юк, кайтмас яшь гомер,
Калды ул еракта...» –
Бүген дә шушы җыр
Яңгырый йөрәктә.

Бу җыру – үткәннән,
Яшьлектән истәлек:
Хәлләрем шундыйрак –
Тыялмыйм хисләрем...

Яшьлекне минем дә
Сагынган мәлләрем:
«Яшь гомер бер узгач...» –
Шундыйрак хәлләрем.

Шушы Җыр, шушы Моң
Хәтерем түрендә:
Җырчыга кушылып
Кабатлыйм бүген дә:

«Яшь гомер бер узгач,
Кайтмый ул яңадан...»
...Олыгаям, ахрысы, –
Яшь ага яңактан.

2006

Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәймиев белән. 2003 ел

«Сабый чагыннан ятим калып, тормыш төбеннән күтәрелгән, үз бәхетенә үз таланты белән юл ярган Әлфия Авзалова – Гөлсем Сөләйманова, Фәридә Кудашева, Рәшит Ваһапов, Илһам Шакировлар кебек данлыклы сәнгатькәрләр сафына баскан, татар җырын яңа эстетик югарылыкка күтәргән шәхесләрнең берсе...

Әлфия Авзалованың йөрәгеннән кайнап чыккан җыр сәнгате – милләтебез күңел хәзинәсенең, гасырлардан гасырларга күчеп килгән рухи байлыгының тугры дәвамы ул».

Минтимер Шәймиев

Моң агыла

«Әлфия Авзалованың татар милләте каршында йөзе ак, күңеле пакь. Әлфия – тумышы белән моң! Ул – милләт кызы».

Илһам Шакиров

Әлфия Авзалова нәфис сүз остасы Фәйзи Йосыпов янәшәсендә

Әлфия Авзалова сәхнәдәш дуслары белән

ӘЛФИЯ АПА

Ләбиб Лерон

Сәхнәдәшләр: Әлфия Авзалова һәм баянчы-композитор Зиннур Гыйбадуллин

Миңа моны әнием Шәргыя сөйләгән иде.

Алтмышынчы елларның уртасы булса кирәк. Көннәр җәйгә таба авышкан чак. Халыкта тиз популярлашып киткән җырчы Әлфия Авзалованың концерт бригадасы безнең авылга Актаныш райондагы Олы Имән авылы килеп төшә. Клубка якынрак булганга күрәдерме, артистларның берничәсен – иң күренеклеләрен – Әлфия апаны, баянчы-композитор Зиннур Гыйбадуллинны һәм нәфис сүз остасы, шагыйрә Гөлшат Зәйнашеваны безнең өйгә урнаштыралар. Ул дүртпочмаклы өйгә ничек сыйдылар икән, дип уйлап куям хәзер. Әйтергә онытып торам: бу өчәү янында Әлфия апаның кайсыдыр кызы да булган әле. Алар чәйләп, әниләр белән гәпләшеп утырган вакытта мин – дүрт-биш яшьлек малай безгә туган тиешле Илгиз белән шул тирәдә әвәрә килеп йөргәнмен, имеш. Әлфия апа, безгә ишарәләп, кызына: «Кызым, әнә сиңа кияүләр!» – дип әйтеп куйган икән дә, кызы (бәлки Гүзәл булгандыр) шундук, кистереп, болай дигән: «Мин авыл малайларына кияүгә чыкмыйм!»

Шул сүзләрне ишткәч, табын янындагылар барысы да дәррәү көлеп җибәргән, имеш...

Әлфия апаны беренче күрүем шулай булган, әмма, ни кызганыч, мин бу турыда берни дә хәтерләмим. Әлеге вакыйгадан соң шактый еллар узгач, әлбәттә, Әлфия апа белән якыннан таныштым. Сәхнәдә күп мәртәбә бергә чыгыш ясарга туры килде безгә. Аның белән төшкән фотоларыбыз да бар. Әлфия апа Авзалова, Илһам абый Шакиров кебек мәшһүрләребез белән бер заманда яшәү, алар белән аралашу, алар җырлаганны, сөйләгәнне тыңлау – үзе бер бәхет түгелмени?!.

Кем ул Әлфия Авзалова? Бу сорауга мин, гадәттә, болай дип җавап бирәм:

Бүтән бер сүз өсти алмыйм
Мин шушы язганыма:
Татар Моңы Алиһәсе –
Әлфия Авзалова!

Фотолар «Әлфия Авзалова» китабыннан (төзүчесе – Рабит Батулла, 2007) һәм Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт филармониясе архивыннан алынды. ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

ТИПТӘРЛӘР – Социаль төркем, катлау буларак XVII гасырдан ук билгеле. XVIII йөз ахыры-XIX йөз башындагы Россия законнары типтәрләрне аерым халык, хәтта милләт итеп караса да, чынлыкта без төркиләшкән чирмеш типтәрләрен, чуаш типтәрләрен, мордва типтәрләрен, ар һәм вотяк типтәрләрен дә беләбез. **Гайнетдин Әхмәров (1864-1911)** *мишәрәк типтәрләре* дигән атаманы да куллана. Типтәрләргә җир биләүдә һәм кайбер башка өлкәләрдә өстенлекләр бирелгән. Хәзерге Татарстанның көнчыгыш районнарында, мәсәлән, элекке Алабуга, Минзәлә, Бөгелмә өязләрендә типтәрләр аеруча күп булган. Әйтик, 1797 елгы кенәгә буенча, Алабуга өязендә – 652 типтәр һәм бобыль, Минзәлә өязендә – (көнбатыш өлешеннән кала) – 5597, Бөгелмә өязендә 4500 типтәр һәм бобыль исәпләнгән. Тарихи документлардан типтәрләрнең Иске һәм Яңа Карабаш, Бишмунча авылларында яшәве билгеле. Типтәрләр төрле авылларга күчеп килеп, авыл җәмәгатенә кушылган. Мәс., 1800 нче елларда Бикбулат карьясе (хәзерге Иске Минзәләбаш, Сарман районы) халкы ирле-хатынлы ике типтәрне үзләренә кабул иткән. Җир бүлгәндә аларга яхшырак урыннар «ярып» бирелгән, ә

Сугыш герое – типтәр Гаибов

Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

нәселләренең җирле хакимиятләр белән элемтәсе бер дә өзелмәгән, дип сөйлиләр.

Мишәрәкләр, башкорт фетнәләрендә катнашмаган өчен, башка типтәрләрдән йөз елга алдарак-атап әйткәндә, 1735 елның 11 февралендә башкортларга бәйлелектән азат ителгән һәм моңарчы үзләре килешү буенча биләгән җирләрнең мираси хуҗасы булып исәпләнә башлаган.

Тарихтан билгеле булганча, 1747 елда Башкортстан җирләрендә барысы 57500 типтәр яшәгән. «Башкортостан» энциклопедиясендә, башкорт арасында типтәрләр асабалардан, бобыльләрдән һәм ясаксыз җибәрелмешләрдән барлыкка килгән, дип күрсәтелә. Башкортларда типтәрләрне *әтәлбай*, *әтәрбай* дип тә атаганнар.

1926 елгы халык санын алу мәгълүматларына караганда, типтәрләрнең саны 27,4 мең булган, аннан соң халык санын алганда типтәрләр аерым төркем итеп каралмаган, алар татар, башкорт, мари, мордва булып язылган.

Типтәр атамасы *дәфтәр* сүзеннән килеп чыккан, чөнки типтәрләрне махсус дәфтәргә терки торган булганнар (дөресрәк итеп әйткәндә, дәфтәргә теркәлгән «чит халыкларны» типтәр дип атаганнар). *Типтәр ясагы* – дәфтәр-исемлек буенча түләнә торган ясак. Дәфтәргә теркәлмәгән марилар (чирмешләр) үзләрен *тептердыме* (дәфтәрсезләр) дип атый башлаган.

Типтәрләр хәрби хезмәттә

Ризаэддин Фәхреддин: *«Алтын Урда һәм Казан хөкүмәтләрендә дәфтәргә теркәлгән бер сыйныф халыкларының «типтәр» атамасы алуы мәгълүмдер»*, – дип яза. Бу атаманы «тибәрелү» сүзе белән бәйләүчеләр дә булды (мәс., башкорт галиме Ә.З.Әсфәндияров, мөфти Габделвахид Сөләйманов (1786-1862)). Ә бит югыйсә инде морза Тәфкилев (чукынганнан соң Александр Иванович Тәвкилев) үк типтәр атамасының «дәфтәр» сүзенә бәйле булуы турында язган булган *(Рифкать Әхмәтҗанов)*.■

Типтәрләр хәрби ант бирә

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

МИЛЛИ КИТАПХАНӘНЕҢ ТӨП БИНАСЫ (ТАРИХЫ, ТӨЗЕЛЕШЕ, ЭЧКЕ БИЗӘЛЕШЕ)[1]

Читтән карап бер соклансаң, эченә кергәч, икенче кат гаҗәпкә каласың. Менә шундый ул Лобачевский һәм Кремль урамнары кисешкән чаттагы гүзәл храм – Татарстанның Милли китапханә бинасы. Шулай соклану мәлендә Аргентина язучысы Хорхе Луис Борхесның искиткеч матур фикере искә төшә: «Һәркем җәннәтне үзенчә күзаллыйдыр, минем өчен җәннәт һәрвакыт китапханә булып тоела иде», – дигән ул.

*Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.

[1]В.И.Ленин исемендәге Республика Фәнни китапханәсенең татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлеге мөдире Ф.Гафурова төзегән язмалар файдаланылды.

Чынлап та шулай, арыслан тоткалы саллы ишекләрне ачып керүгә, сине тәрәзә өлгеләреннән төшкән аллы-гөлле нурлар арасында оҗмах кошлары каршылый. Стеналарда, түшәмнәрдә чәчәкләр тәлгәше, купшы бакчалар сурәте, әллә нинди серле бизәкләр, кабарынкы барельеф итеп эшләнгән илаһи затлар, амурлар, аннары купшы каминнар куелган заллар китә; тау куышы кебек мәгарә-зал серле-салкынча һавасы белән сине үзенә җәлеп итә. Кая карама – китаплар, китаплар, китаплар... Гасырлар катламы кебек киштә-киштә китаплар, компьютер экраннары, кайгыртучан китапханәчеләр.

Шулай итеп, без бу борынгы йортның эчке күркәмлеге, тарихы, элек заманнарда моны кем төзеткәне һәм монда кем яшәгәнлеге хакында кыскача сөйләп китәрбез.

Әлеге китапханә бинасы нигезендә 1865 елда зур йорт торган. Шул чорга хас булганча, һәртөрле хезмәтчеләре, ат абзары, кареталар сарае, мунчасы, түбә астында печән саклагычы, коесы һәм җиләк-җимеш бакчасы булган. Сәүдәгәр Яков Данилович Соколов биләгән бу йортның рәвеше хәзерге кебек үк, өчьяклы диварлы (ябылып бетмәгән каре) итеп салынган була. Агачтан да, урыны белән таштан да салынган бу йортта төзелеш, үзгәртеп кору бер дә тукталып тормый. Корылмалары төрле этажлы булган йортның икенче катын таштан өйгәннәр, агач өлешен таш белән алыштырганнар.

1869-1886 елларда бу йортка сәүдәгәр Козьма Иванович Романов хуҗа була. Товар саклар өчен, ул ишегалды уртасына озынлыкка – 15, киңлеккә 5 сажин булган ике катлы бина кордыра. Бераздан бу хуҗалыкны сәүдәгәр Яков Соколов сатып ала. 1891 елда ул бинага чуен колонналар белән балкон ясату ниятен белдереп, рөхсәт итүләрен сорап, шәһәр башлыкларына үтенеч юллый. 1904 елда бу биләмәне «шәһәрнең буыннан-буынга килгән абруйлы гражданины» Алексей Константинович Ушков сатып ала. Ул ике катлы йортны, флигелен, агачтан корылган хуҗалык биналарын сүттереп ташлатып, болар урынына таштан ике катлы яңа йорт салдыра. 1907 елгы төзелеш исәп-хисабы кенәгәсенә бу хакта белешмәләр теркәлеп калган.





Домъ З. Н. Ушковой, г. Казань. — Зало "EMPIRE"

Алексей Константинович Ушков – Константин Капитонович Ушковның, ягъни «П.К.Ушков и К°» ширкәте хуҗасы П.К.Ушков бертуганының улы. Ул 1881 елда туган, дип фаразлана. Казан университетының табигать белемнәре бүлегендә 1898-1902 елларда укып алган (Харьков университетына күчеп укыган кыска вакыты да шуңа керә). Әнисе вафат булганнан соң, әнисе ягыннан туганы, чәй сатучы миллионер Кузнецов Казан университеты профессоры М.И.Лопаткинны гувернёр итеп яллый, Архангельская урамында аның исеменә дача сатып ала. Ушков малайлары һәм Лопаткиннар гаиләсе шунда яши.

Константин уллары Григорий, Алексей, Михаил Ушковларның гувернёры булган М.И.Лопаткинның улы Ярослав бу йортның хуҗасы, гаиләсе хакында истәлекләрен язып калдыра. Казан университетын тәмамлаган Михаил Иванович Лопаткин (1854-1922) үзе дә кызыклы шәхес була. Ул танылган химия профессоры Зайцев кул астында эшли. Күпкырлы талантка ия шәхесне Казан философ, тарихчы, филолог, төбәкне өйрәнүче буларак та белә. Гомеренең соңгы елларында ул, «Казан музей хәбәрләре» журналы белән иҗади элемтәдә тора.

Ушковлар Вятка губернасының Алабуга өязенә кергән Бондюг авылыннан чыкканнар, зур химия заводлары тотканнар. Заводның беренче нигезен коручы Капитон Яковлевич – Алабуганың шәрәфле гражданины (Ушковлар Алабугага 1844 елда килеп төпләнәләр), мануфактура буенче киңәшче, 1 нче гильдия сәүдәгәр. К.Я.Ушков үлгәннән соң, заводлар белән идарә итү варисларына – ике бертуган Петр һәм Николай Капитоновичларга кала. Петр Ушков химия заводы эшенә бик ныклап керешә, Россиянең төрле төбәкләрендә булып, тәҗрибә туплый. Аннары Германиядә булып кайтканнан соң, 1883 елда «П.К.Ушков и К°» дигән ширкәт төзи, хәйриячелек белән шөгыльләнә: Алабуга өязендә рус һәм татар авылларында мәктәп-мәдрәсәләр, хастаханәләр салдыра, аеклар җәмгыяте оештыра.

Алексей Константинович Ушковның хатыны Зинаида Николаевна, шул чор кешесе истәлекләренә караганда, профессор Высоцкий кызы була. Бу йортны А.К.Ушков хатынына бүләк итә. Нәкъ менә аның бу йортка хуҗа булуын раслап, капка өстендәге «З.У.» дигән монограмма бүгенге көндә дә яхшы сакланган хәлдә күренеп тора. Хосусый милек-мөлкәткә ия булу хакындагы бәяләмә табелендә йортның икенче катында хуҗа ханымның квартирасы урнашканлыгы, ә аскы катта исә өч кат измә сылап салынган

дүрт таш лавка (кибет) һәм хезмәтчеләр фатиры булганлыгы теркәлгән. Зинаида Ушкова хакында мәгълүматлар бик аз сакланып калган. 1906 елда ул «Казан губернасы фельдшерлык мәктәбендә укучы ярлы балаларга ярдәм итү җәмгыяте»н җитәкли, хатын-кызлар арасында «Хәйриячелек итүче ярлылар комитеты»на әгъзалыкка кандидат була. Зинаида Ушкова йортында төрле чорларда В.Ф.Маркелов һәм В.А.Шароновның китап кибетләре, М.Ш.Генкинның музыка товарлары кибете урнаша. Ушковларның гаилә тормышы барып чыкмый. 1916 елда Зинаида Ушкова иреннән аерыла һәм йортын Казан губернасы земствосына сатып җибәрә. Бу йортта вак һөнәрчеләр җитештергән әйберләрне саклау урыны һәм земствоның төрле бүлекләре: авыл хуҗалыгы, страхование, пенсия, ветеринария, вак сәнәгать, һөнәри белем бирү бүлекләре урнаша. 1919 елда әлеге бина Казанның җәмәгать китапханәсенә бирелә. ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

«РЕВОЛЮЦИЯ ДАВЫЛЫ: РОССИЯ ТАРИХЫНДА 1917 ЕЛ»

Татарстан Республикасы Милли музеенда шул исемдәге күргәзмә эшли. Анда 1917 елга кадәрге губерна тормышы, халыкның самодержавиегә каршы февраль чыгышлары, Казанда Октябрь кораллы восстаниесе, Совет хакимияте һәм ТАССР оешу кебек зур вакыйгаларга бәйле экспозицияләр белән танышырга мөмкин. Күргәзмәдә сәяси партияләрнең листовкалары һәм агитация плакат-

Гаяз Исхакый һәм Садри Максудига багышланган экспозиция. Материаллар ТР Милли музеена Төркиядән кайтарылган

лары, губерна газеталары, республикабызның беренче картасы һәм байрагы, хәрби кораллар, шул исәптән, Казан дары заводында табылган инглиз гаубицасы бар. Милли музейга килүчеләр шушы елларның геройлары – Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Хөсәен Ямашев, Сәхибгәрәй Сәетгалиев, Әминә Мөхетдинова һәм башкаларның шәхси әйберләрен, документларын, фоторәсемнәрен аеруча зур кызыксыну белән карый.

Күргәзмәдә урын алган бер документның эчтәлеге белән сезне дә таныштырабыз.

Г.Исхакыйның шәхси әйберләре



«Сөембикә» журналы. Тышлыктагы шигарь: «Яшәсен хөр Русиядәге хөр татар хатын-кызлары». 1917. - №9

Безнең мирас №1 гыйнвар 2018

КАЗАН ИМАМ ВӘ МӨДӘРРИСЛӘРЕННӘН БӨТЕНРУСИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНА


قزان امام ومدرسلرندن بتون روسیه مسلمانلرینه

خطاب نامه

بسم الله الرحمن الرحیم

حرمتلو مسلمان قرده‌شلر!

اوشبو کونلرده مملکتمز روسیه‌ده بیك زور اوزگه‌رشلر بولدی. نیچه یوز یللردن بیرلی بزنی قصوب کیلگان ایسکی حکومت بتدی. آنڭ اورنینه خلق وکیللری صایلاغان، خلق‌دوستی بولغان موقت یاڭا حکومت اورنلاشدی. بتون خلقغه یاخشیلق‌غنه تلی‌طورغان بو یاڭا حکومتمز بزگه بیك کوب ایرکنلکلر بیره. شونڭ اوچون مملکتمزده بولغان بو اوزگه‌رش بارچه‌خلق‌غه زور شادلقدر. خصوصا بز روسیه مسلمانلری اوچون بیگره‌کده ئلوغ بخت وسعادتدر. چونکه بز مسلمانلر دورت یوز یلدن بیرلی ایسکی حکومت قول آستنده قصنقیلقده وطارلقده تورا ایدك. بزنڭ ایڭ عزیز دینمز وقدرلی تلمز چیت کورله وکیمستله ایدی.

بزگه کوب اورنلرده دینمزنی وتلمزنی اوقتورغه ایرك بیرلمی، مکتب، ومدرسه‌لرمز یوق بار صلتاولر ایله یابلوب، اوقتوچیلری حکمگه طارتلا ایدی. ایندی یاڭا حکومتمز بزگه ایرکنلك، عدللك وتیگزلك بیردی وشونڭ آرقاسنده، بوندن صوڭره بز مسلمانلرغه اوّلده‌گی قصنقیلقلر وطارلقلر بتدی. بونڭ اوچون الله تعالی گه شکرانه‌قیلورغه وبونڭ‌قدرن بلورگه تییشلیمز.

بونڭ اوچون یاڭا حکومتمزنڭ نغایووینه وطنچلقلرنڭ دائم بولووینه همه‌مز خدمت ایته‌رگه تییشلیمز.

حرمتلو مسلمان قرده‌شلر!

یاڭا حکومتمز طرفندن خلق‌فائده‌سینه اعلان‌قیلنغان عدالت وطوغریلقنی اوشانداق ایرکنلك وتیگزلکنی، خلق اوزی بوزماسون! تش وطرناقلاری برله ساقلارغه تروشسون!

مسلمان قرده‌شلر!

احتمال خلق آراسنده بو ایرکنلك وتیگزلك‌لرنڭ دنیاغه چغووینه چن کوڭلندن راضی بولماغان کشیلر بولور، آلار احتمال سزگه تورلی قوطقولر صالورلار. آندی سوزلرگه قولاق صالماڭز! طنچلقدن آیورلماڭز! هیچ کمنڭ حقینه تیمه‌ڭز! بلـکزکه: کشینڭ جانینه ومالینه ضرر کیترو الله حرام ایتکان یامان وئه‌شه‌کی اش بولغان کبی حاضرگی عدالتلی حکومتمزده آندی بوزق کشیلرگه، طنچلقنی وترتیبنی بوزوچیلرغه قاطی جزا بیره‌چکدر.

شونڭ اوچون بزگه بر اتفاقده بولوب طنچلقنی وترتیبنی صاقلاو تییشدر. اگر بوەر خیانتلی ایسکی حکومت طرفلی کشی بلونسه قاتی روشده قارشی طورڭز. حاضرگی حکومتکه اندای آدملرنی کورسه‌تڭز.

مسلمان قرده‌شلر!

موندن صوڭ مملکتمزنڭ اداره‌سی نیچك بولونی کیگه‌ش ایته‌ر اوچون تیز کونده اوچریدیتلنی صوبرانیه اسمنده بتون خلقدن صایلانغان زور جییلش بولاچق. هر قایوڭز شول بولاچق صایلاولرنی آلدن کیگه‌شوب حاضر بولوب طورڭز! اوزمزنڭ کیره‌کلرمزنی وحقلرمزنی ئه‌یته بلیك!

غافل بولماڭز مسلمانلر!!!

قزان شهرینڭ اماملری ومدرسلری.

قزانده „امید“ شرکتی مطبعه‌سی ۱۹۱۷ سنه

Хитабнамә. 1917 ел


Экстренное приложеніе
къ № 4.
3 марта 1917 г.

ИЗВѢСТІЯ
ПЕТРОГРАДСКАГО СОВѢТА
Рабочихъ и Солдатскихъ Депутатовъ.

ОТРЕЧЕНІЕ ОТЪ ПРЕСТОЛА.

Депутатъ Карауловъ явился въ Думу и сообщилъ, что государь Николай II отрекся отъ Престола въ пользу Михаила Александровича. Михаилъ Александровичъ въ свою очередь отрекся отъ Престола въ пользу народа.

Въ Думѣ происходятъ грандіознѣйшіе митинги и оваціи. Восторгъ не поддается описанію.

Тип. «Совѣта Рабоч. и Солдатск. Депутатовъ», Сабинкг. 6.

ХИТАБНАМӘ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим

Хөрмәтле мөселман кардәшләр!

Ошбу көннәрдә мәмләкәтемез Русиядә бик зур үзгәрешләр булды. Ничә йөз еллардан бирле безне кысып килгән иске хөкүмәт бетте. Аның урынына халык вәкилләре сайлаган, халык дусты булган мәүкыйт *(вакытлы)* яңа хөкүмәт урынлашты. Бөтен халыкка яхшылык кына тели торган яңа хөкүмәтемез безгә бик күп иркенлекләр бирә. Шуның өчен мәмләкәтемездә булган бу үзгәреш барча халыкка зур шатлыктыр. Хосусан без – Русия мөселманнары өчен бигрәк тә олуг бәхет вә сәгадәттер. Чөнки без мөселманнар дүрт йөз елдан бирле иске хөкүмәт кул астында кысынкылыкта вә тарлыкта тора идек. Безнең иң газиз динемез вә кадерле телемез чит күрелә вә кимсетелә иде.

Безгә күп урыннарда динемезне вә телемезне укытырга ирек бирелми, мәктәп вә мәдрәсәләремез юк-бар сылтаулар илә ябылып, укытучылары хөкемгә тартыла иде. Инде яңа хөкүмәтемез безгә иркенлек, гаделлек вә тигезлек бирде вә шуның аркасында, моннан соңра без мөселманнарга әүвәлдәге кысынкылыклар вә тарлыклар бетте. Буның өчен Аллаһы Тәгаләгә шөкрана кылырга вә буның кадерен белергә тиешлемез.

Буның өчен яңа хөкүмәтемезнең ныгуына вә тынычлыкларның даим булуына һәммәмез хидмәт итәргә тиешмез.

Хөрмәтле мөселман кардәшләр!

Яңа хөкүмәтемез тарафыннан халык файдасына игълан кылынган гадаләт *(гадел)* вә тугрылыкларны, иркенлек вә тигезлекне халык үзе бозмасын! Теш вә тырнаклары берлә сакларга тырышсын!

Мөселман кардәшләр!

Ихтимал, халык арасында бу иркенлек вә тигезлекләрнең дөньяга чыгуына чын күңеленнән разый булмаган кешеләр дә



Х.Ямашевның шәхси әйберләре

булыр, алар, ихтимал, сезгә төрле коткылар салырлар. Андый сүзләргә колак салмагыз! Тынычлыктан аерылмагыз! Һичкемнең хакына тимәгез! Беленез: кешенең җанына вә малына зарар китерү Аллаһ хәрәм иткән яман вә әшәке эш булган кеби, хәзерге гадәләтле хөкүмәтемездә андый бозык кешеләргә, тынычлыкны вә тәртипне бозучыларга каты җәза биреләчәктер.

Шуның өчен безгә бер иттифакта булып, тынычлыкны вә тәртипне саклау тиештер. Әгәр берәр хыянәтле иске хөкүмәт тарафлы кеше беленсә, каты рәвештә каршы торыгыз. Хәзерге хөкүмәткә андай адәмнәрне күрсәтеңез.

Мөселман кардәшләр!

Моннан соң, мәмләкәтемезнең идарәсе ничек булуны киңәш итәр өчен, тиз көндә Учредительное Собрание исемендә бөтен халыктан сайланган зур җыелыш булачак. Һәркаюгыз, шул булачак сайлауларга алдан киңәшеп, хәзер булып торыгыз! Үземезнең кирәкләремезне әйтә белик!

Гафил булмагыз, мөселманнар!

Казан шәһәренең имамнары вә мөдәррисләре, 1917 ел ■

«МӘРҖАНИ» ЧИШМӘСЕ

Узган елның декабрь аенда «ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин җитәкчелегендә Арча районының Ташкичү һәм Симетбаш авыллары арасында мәгърифәтче, дин белгече, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел тулу уңаеннан төзекләндерелгән «Мәрҗани» чишмәсен ачу тантанасы булды. Дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, язучылар, укытучылар катнашында узган әлеге тарихи вакыйгада әйтелгән кайбер фикерләрне сезнең игътибарга да тәкъдим итәбез.

Арча муниципаль район хакимияте башлыгы Илшат Нуриев: «ТАРИХНЫҢ ЭЗЕ ШӘХЕСЛӘР АДЫМЫ БЕЛӘН ҮЛЧӘНӘ»

«Бу – Арча районында «ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ егетләре һәм аның җитәкчесе Лотфулла Шәфигуллин тарафыннан төзекләндерелгән дүртенче чишмә. Аңа кадәр «Хотня», «Курсави» һәм «Ахун» чишмәләрен ачу тантанасы булган иде. Без тарихта эзлебез, дигән әйтем бар. Тарихның эзе менә шушы шәхесләрнең адымы белән үлчәнә. Без бүген үзебезнең җирлектә игелекле бер адымны билгеләп үтәбез».

«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры Лотфулла Шәфигуллин: «МӘРҖАНИ – БАТЫР КЕШЕ»

«Шиһабетдин Мәрҗани – бу җирләрдә йөргән, бу чишмәләрне күргән кеше. 17-20 яшьләрендә ул данлыклы көрәшче булган. Әтисеннән сорап, егетләр аны төрле авыл Сабантуйларына алып киткән. Ш.Мәрҗани үзе бер еккан көрәшче белән бүтән бил алышмаган. Мәрҗани – батыр кеше. Шундый батыр кеше генә тарихчы да, дин әһеле һәм татарның беренче кешесе дә була ала. Чишмә Мәрҗанигә багышлана, аның суы ул яшәгән чордан ук агып торган. Бу чишмә халыкны мәңге шулай куандырсын».

РФнең мәгариф отличнигы Рузалия Насыйбуллина: «ЧИШМӘ ОЛУГ ШӘХЕСЕБЕЗНЕҢ ИСТӘЛЕГЕ БУЛЫП ТОРСЫН ИДЕ»

«Биредә борынгы бабаларыбызның тибен җирләре – ат көтүлекләре булган. Атлар, чишмәгә килеп, аның суын эчеп сихәтләнгән. Икенчедән, бу чишмә олы юл буенда урнашкан. Шушыннан узучы мосафирлар да, чишмә янында атларын сугарып, су запасын алып киткән.

Тора-бара аңа игътибар кимегән, әмма чишмә чирәм-үләннәр арасыннан агышын югалтмаган. «Таттелком» АҖ егетләре, Аллаһның биргәненә шөкер, әлеге чишмәгә яңа сулыш бирде. Авылыбыз, бөтен халык исеменнән аларга олуг рәхмәтебезне белдерәбез. «Мәрҗани» чишмәсе, олуг шәхесебезнең истәлеге булып, биредән узучы юлчыларны һәрвакыт үзенә тартып торсын иде». ■

ГЫЙНВАР

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Күренекле драматург, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллин (1935-2012) спектакльләрендә яңгыраган җырлардан туплан-ган китап («Безгә бер җыр кирәк») дөнья күрде.

● 5 декабрьдә Актаныш районының сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернатында танылган драматург Данил Салиховка нисбәтле фәнни-гамәли конференция узды. Чарада әдипнең каләмдәшләре Г.Морат, Л.Лерон, Р.Зәйдулла, Р.Сәгъди, галимнәр Ә.Закирҗанов, О.Хисамов, «Гаилә һәм мәктәп» журналының баш мөхәррире Л.Нәсыйхова, Д.Салиховның кызы – мөгаллимә Гөлназ Сабирова, Минзәлә театры артистлары катнашты.

● 6 декабрьдә «Безнең мирас» журна-лы хезмәткәрләре Л.Лерон һәм Р.Сәгъди Башкортстанның Илеш районына эшлекле сәфәр кылды. Алар Ярмәкәй китапханәсендә мәктәп укучылары, китапханәчеләр, иҗат һәм сәнгать әһелләре белән очрашты. Очрашу барышында Ярмәкәйнең талантлы яшьләре Л.Леронның «Кычыткан чыпчыгы» пьесасы буенча куелган спектакльдән бер өзек уйнап күрсәтте.

● Шул ук көнне төштән соң «Безнең мирас» хезмәткәрләре Чакмагыш районы китапханәсендәге очрашуда да катнашты.

● 7 декабрьдә Казанда нәфис гимнастика бу-енча Россия шәһәрләренең традицион «Сөембикә кубогы» турниры үтте. Азнакай кызы, 4 яшьлек Әминә Кәримова (тренеры Виктория Булатова) 4 нче урынга лаек булды.

● 7 декабрьдә «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Л.Лерон һәм драматург Р.Сәгъди Башкортстанның Шаран районында булды. Районның Яшьләр үзәгендә төбәкчеләр, иҗат әһелләре катнашында узган чарада шушы төбәктә туган һәм бүгенге көндә шунда яшәүче күренекле җырчыбыз Фән Вәлиәхмәтов та катнашты. Шул ук көнне Туймазы районының Үзәк китапханәсендә һәм Октябрьск шәһәре янындагы Төрекмән авылының мәдәният йортында (шагыйрь Хәйретдин Мөҗәйнең (1901-1944) туган авылы) узган очрашуларда исә «Безнең мирас»лылар Татарстанда нәшер ителүче басмалар турында сөйләде, укучыларны, әдәбият сөючеләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирде.

● Буа театрының 100 еллык тарихын колачлаган китап (Рифат Каюмов. «Буа театры. 1917-2017») чыкты. Раил Садриев җитәкчелегендәге Буа дәүләт театры коллективы шушы көннәрдә башкалабыздагы «Пирамида» күңел ачу үзәгендә юбилей мөнәсәбәте илә зур чара үткәрде.

● 8 декабрьдә «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Л.Лерон һәм Р.Сәгъди Бөгелмә районының Карабаш авылында яшәүче фермер Фәрит Нәбиуллин белән очрашты.

● 11 декабрьдә Әтнәдә төбәкне өйрәнүче Илсур Шакировның «Меңнәр иле Олы Мәңгәр» исемле китабын тәкъдим итү кичәсе булып узды.

● 12 декабрьдә Балык Бистәсе районының Югары Тегермәнлек авылы мәктәбендә «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Л.Лерон һәм Р.Сәгъди белән очрашу үткәрелде.

● 13 декабрьдә «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Л.Лерон һәм басманың гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррире, драматург Р.Сәгъди Мари Республикасының Бәрәңге районында иҗади сәфәрдә булып, район хакимияте башлыгы Әлфит Ибраев белән очрашты. Шул ук көнне алар Бәрәңге районының Мазарбашы һәм Куян (җәлилче Гайнан Курмашның (1919-1944) туган авылы) авылларында булды.

● 15 декабрьдә Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «Җыен» фонды (директоры Ф.Рәфыйков) «Салих Сәйдәшев» китабын тәкъдим итте. ■

Мирасворд

Әбҗә-лилов, Мәхмүтов

Йорт иясе

Дәвер, заман

Җырчы Георгий …

Алтын Урда шәһәре

Кыр-гызстан каласы

Төньякта яшәүче төрки халык

Ерткыч җанвар

VII-XI йөзләрдә Азиядә яшәгән төрки телле кабилә

… Хангил-дин (тел белгече, педагог)

Нечкә билбау

Рәшит Ваһапов туган авыл

Гарәп хәрефе

Тәнкыйтьче, «Һади Такташ поэзиясе» монографи-ясе авторы

Скандина-вия мифоло-гиясендә баш Алла

Галимҗан Ибраһи-мов повесте

… Бәхтия-ров (журна-лист, мөгаллим)

Кайнатып киптерелгән ашлык онынан әзерләнгән ризык

Суфи шагыйрь, «Диване хикмәт» җыентыгы авторы

Борынгы семитлар-да баш Алла

Акъегет, Җәлил, Сираҗи

Кадыйр … (башкорт әдибе)

Хәрби дәрәҗә

Ярлы, фәкыйрь (иск.)

Өчпоч-маклы яулык (иск.)

Гарәп артикле

Татар ха-лык бию такмагы

Камал, Кари, Галиев

… Лорен

Боерык, фәрман

Алишер … (үзбәк шагыйре)

Балкан ярымутра-вындагы елга

Корьәндә бүлек

Римга нигез салучы-ларның берсе

Мирсәй …

Нота

Гарсиа … (испан шагыйре һәм дра-матургы)

«… кыз» әкияте

«Чук һәм …» (А.Гайдар)

Борынгы грек шагыйре

Агыйдел-нең сул кушыл-дыгы

Рәис Габдулла төзеде.

12 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Судлан уңга: Рәшит, авыз, сәкен, үләң, Геб, Харис, равелин, Әбрар, юламан, җияк, Атум, обер, драм, Намибия, дог, Фәйзи, Урарту, Ион, фреска, до, Фәтхи.
Өстән аска: дәф, «Авылдашлар», ата, өзәңге, мум, «Зифа», елдам, Диор, би, но, әвен, рагу, Расих, Әҗем, Кох, «Айбиби», Азади, Шәкүр, бояр, Кави, Танис, «Уяну».


Татар театры техникумы

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЕЛЪЯЗМАСЫ / ГЫЙНВАР

• 775 ел элек (1243)

Алтын Урда (Җучи олысы, Олуг Олыс) дәүләтенә нигез салына. Дәүләтнең бинаһая зур гаскәрендә өстенлекне орыш-яулар вакытында һаман арта барган төрки кавемнәр тәшкил иткән.

• 665 ел элек (1353)

Идел буендагы Сарай Бәркә каласында яшәгән Алтын Урда шагыйре Харәзми «Мәхәббәтнамә» поэмасын иҗат итә.

• 200 ел элек (1818)

Күренекле галим, тарихчы, фәлсәфәче, мәгърифәтче Шиһабетдин Баһаветдин улы Мәрҗани (1818-1889) дөньяга килә.

• 110 ел элек (1908)

10 гыйнварда иҗтимагый һәм әдәби «Шура» журналы (1908-1918) чыга башлый. Аның нашире күренекле шагыйрь, миллионер Закир Рәмиев (Дәрдемәнд) була. Баш мөхәррире – Ризаэддин Фәхреддин.

• 100 ел элек (1918)

21 гыйнварда «Олугъ Төркестан» газетасында Һади Такташның «Төркестан сахраларында» исемле шигыре дөнья күрә.

24 гыйнварда Уфа Ревкомы «Көрәш» исемендә газета чыгара башлый. «Көрәш» большевиклар һәм сул эсерлар фикеренә хезмәт итәргә вәгъдә бирә», – диелә аның беренче санында.

• 95 ел элек (1923)

1 гыйнварда Татар театры техникумы ачыла.

• 90 ел элек (1928)

1 гыйнварда күренекле артист, Хезмәт Батыры Мифтах Әпсәләмов (1890-1928) вафат була.

• 75 ел элек (1943)

Волхов фронтында «Фронт правдасы» исемле газета оештырыла. Редактор урынбасары – Габделхәй Хәбиб, хәрби хәбәрче – Әхмәт Фәйзи.

• 70 ел элек (1948)

«Совет әдәбияты» журналында Гомәр Бәшировның «Намус» романы басыла башлый.

*Текстны **Айдар Закиров** әзерләде.* ■

ЯНВАРЬ 2018

Останется в мире слово моё… Шигабутдин Марджани.

Историческое наследие: «Нурсултан». О.Иванова; «Кубакай – родина святых»; «Богатая история Кудашево: со времён великанов до «белых в лаптях». Ф.Газизова; «Давайте помолимся Аллаху...» М.Хулуси Акчура;

Татарский мир: «Знатный человек». Н.Акмал.

Тюркский мир: «Тенре, Дингир и Умай...» А.Галимзянов;. «Тёзка великого Тукая».

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Герой Катиль»; «Чтоб оступиться, хватит одного шага». Г.Мунасипов; «Первый поэт после Тукая...»; «Хочу сиять звездою на небе...» Р.Закиева.

В глубине памяти: «Его величество учёный»; «Слепой Сибгать и его сын бухгалтер Миннегали». Г.Галиев.

Художественное наследие: «Храм татарского «моң»а». З.Гильмутдинова; «Богиня»; «Альфия апа». Л.Лерон.

Слово – украшение языка: «Словарь национальных терминов». А.Тимергалин.

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан»; «Революционная буря: 1917 год в истории России»; «Родник «Марджани».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

JANUARY 2018

My words are leaving in the world… Shigabutdin Mardgani.

Historic heritage: «Nursultan» by O.Ivanova; «The Sants' motherland is Kubakay»; «My Kudashevo with its history: from batyrs' periods till «on the service white» by F.Gazizova; «We gave a prayer to Allah ...» by M. Khulusi Akchura;

Tatar world: «Well known man» by N.Aкmal.

Turkic world: «Tenre, Dingir and Umay...» by A.Galimzyanov;
«The nameske of the great Tukay».

Religious heritage: «The Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov.

Literary heritage: «The hero Katil»; «It's enough to make just a step for losing confidence » by G.Munasipov; «Our first poet after Tukay...»; «Let me shine like a star in the...» by R.Zakieva.

From the deepest storage of memory: «His Majesty scientist»; «The blind Sibgat and accountant Minnegali, his son» by G.Galiev.

Creative heritage: «The soul of Tatar soulful melody» by Z. Gilmutdinova; «The goddess of Tatar soulful melody»; «Alfiya apa» by L.Leron.

Word is a language's decoration: «Dictionary of national terms» by A.Timergalin.

On the guard of the memory: «National library of the Republic of Tatarstan»; «The storm of revolution: 1917 in the history of Russia»; «The well «Mardgani».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.



Рәссам Зөфәр Фатыйх улы Фәттахов 1955 елның 10 июнендә дөньяга килә.

1974 елда Лениногорск педагогия училищесын, 1982 елда Ленинград югары сәнгать училищесын тәмамлый.

Зөфәр Фәттахов – Россиянең һәм Татарстан Республикасының Рәссамнар берлекләре әгъзасы. 2002 елдан – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Чаллы каласында яшәп иҗат итә.

Зөфәр Фәттахов

«Мәрҗани мәчете». Киндер, майлы буяу. 2005 ел

«Алабуга. Март ае». Киндер, майлы буяу. 2003 ел

Каенавыл (Барда) кешеләре. 1937 еллар

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Сафакул татарлары. Гаяз Сәмигуллов
Көндәлектән хатирәләр. Мирхәйдәр Фәйзи
Яшик... Кадыйр Сибгатуллин
Ядәч һәм ядәчиләр. Ринат Фәхретдинов
«Озата барма, иркәм» җырының көен кем язган? Мөҗәһит Әхмәтҗанов
Авылдашларым (Бер фото тарихы). Мәсгут Имашев, Фәһимә Газизова
Мин белгән Хәсән Сарьян. Рифкать Әхмәтҗанов

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»* *журналына башкача язылу:
• *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
• *редакциядә*
• *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» *журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*